Безнең мирас

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

08
август 2020
ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР



Тимердән дуга бөгәләр

70 бит

Япон феномены

89 бит

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС

12 +

08
(320)
август 2020

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

4

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-92)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Григорий Родионов (Гәрәй Рәхим)
Данил Салихов
Индус Таһиров
Ирек Шәрипов
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Ләйлә Лерон
(843) 222-09-83 (17-93)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энҗе Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал
(на татарском и русском языках)

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Туфан Миңнуллин

ТАТАР ГАМЕ

4 Марсель Шәйдуллин: «Азнакай – бай тарихлы төбәк!»

ТАРИХИ МИРАС

12 Азнакай музее турында җиде факт
16 Киләчәкне тарихка нигезләнеп кору. *А.Борһанов*
22 Кантончы татарлар тарихы. *Г.Хисамиев*
30 Беренче татар фотографы. *Л.Тябина*
36 Багбостан. *М.Гарипов*
41 Исеме туган ягына кайтты. *Р.Шәрипова*
42 Казандагы беренче татар матбагалары. *Р.Мәрданов, И.Һадиев*
48 «Җөмһүрият» газетасы. *Л.Гобәйдуллин, Р.Шәрәфиева.*
52 Зариф Әмирханның кабер ташы. *А.Гайнетдинов*

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан, Азнакай муниципаль районы, Азнакай «Туган якны өйрәнү» музее архивыннан алынган рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

ДИНИ МИРАС

54 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

60 Әхмәд Гәрәй шигырьләре
62 Муса Җәлил китапханәсендә автографлы китаплар. *Н.Фәттахова, Л.Харасова*
66 Сиринне фаҗигагә этәргән әсәр. *Ә.Шәрипов*
68 Ана. *Сирин*
70 Тимердән дуга бөгәләр... *Т.Миңнуллин*
74 «Авылыңны чынлап яратсаң...». *Л.Лерон*
77 Әйбәт истәлек. Сибгат Хәким – «Казан утлары»на
78 «Сабыр канатларым сынды...». Мәхмүт Хәсәнов – Туфан Миңнуллинга
80 Әкиятче бабай. *М.Әхмәтҗанов*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

82 Нәкый Исәнбәт вафаты

ХӘТЕР САНДЫГЫ

84 Әхмәтҗан хәлфә. *Т.Биктимирова*
89 Япон феномены. *Ф.Нәфиев*
95 Үлемсез батальон солдаты. *И.Нигъмәти*
98 Истә, һаман да истә!

СӘНГАТИ МИРАС

100 Иҗат мөһере. *Р.Сәгъди*
108 Борынгы татар милли музыка уен кораллары. *Р.Гыйләҗев*
112 Татар дәүләт филармониясе 100 еллык ТАССР тарихында. *З.Гыйльметдинова*

ШАЯН МИРАС

114 Көлке куа килә...

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Август*



Заказ №А-1965. Тираж – 1728 данә. Формат 70x100 1/16
Басарга кул куелды: 30.07.2020. Чыгу көне: 05.08.2020.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән әзерләнде.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә – Туфан Миңнуллин фотосы. Фото әдип гаиләсе архивыннан алынды.

Гаилә балаларың бабаларының
кем икәнен белгәндә генә гаилә була.

Туфан Миңнуллин

Туфан Миңнуллин гаиләсе белән

Туфан Миңнуллин

(25.08.1935-2.05.2012)

***

Чын сәнгатьне ялганыннан аерасың килсә, аңа түләнгән акчага кара. Чын сәнгатькә һәрвакыт азрак түлиләр.

***

Сайлау вакытында скрипка уйнамыйлар, барабан кагалар.

***

Кануннар күбәйгән саен, тәртипсезлек арта бара.

***

Утка салсаң, карт агач та яшь агач кебек яна.

***

Өстәгеләр кушканга эшләнгән яхшылык – яхшылык түгел.

***

Күз яшен бушата торган савыт – бүтәннәр күңеле.

***

Ялгышлар күп, хакыйкать берәү генә.

***

Акчаның көче – еш тамуында.

***

Азга канәгать булган халык бөек эшләр эшли алмый.

***

Ахмакларның әмерен акыллылар үти башлаган илдә революцион вазгыять туа.

***

Хакимгә нәфрәт аңардан курыккан мизгелдән башлана.

***

Һәр империянең гомере кеше гомере кебек – кыска да була, озын да була, әмма барыбер үлә.

*Текстны журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №8 август 2020

Марсель Шәйдуллин «Азнакай – бай тарихлы төбәк!»

*(Азнакай муниципаль районы башлыгы **Марсель Зөфәр улы Шәйдуллин** белән «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире **Ләбиб Лерон** әңгәмәсе)*

– Марсель Зөфәрович, бар кеше дә җитәкче булып тумый. Менә Сез ничәмә ел инде җитәкче вазыйфасын башкарасыз. Азнакайлылар Сезне бик хөрмәт итә. Бу эшкә килгән елларны искә төшерик әле?

– Әлмәт районының Нәдер авылында гаиләдә бишенче бала булып дөньяга килгәнмен. Миңа бер яшь тулмас борын, Әлмәткә күченгәнбез. Әтием, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре Зөфәр Газиз улы, гомере буе Әлмәт төбәгендә җитәкче булып эшләде. Үз эшенең чын остасы иде ул. Исеме СССР күләмендә танылды. Хезмәт юлын ветеринар врач буларак башлап җибәрде, аннары «Зәй» миллионер колхозында – баш зоотехник, Әлмәт авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы булып эшләде. Данлыклы Токарликов исемендәге совхозда 17 ел дәвамында директор булып хезмәт итте. Заманында ТАССРда гына түгел, ә СССРда тиңе булмаган зур терлекчелек комплексы төзеде алар. 16 мең баш мөгезле эре терлекләре бар, һәр яктан да алдынгы хуҗалык иде. Ит, сөт, рапс җитештерү буенча илдә беренчелекне бирмәделәр. 1990 нчы еллар башында Әлмәт районына килгән беренче

Президентлар Борис Ельцин һәм Минтимер Шәймиев әтиемнең һәм керәшен авылы Кәләй халкының хезмәтен югары бәяләгән иде. Шөкер, әтиемнең исемен райондашлары онытмый. Аның турында «Счастливые версты Зуфара Шайдуллина» исемле китап чыгардылар, әтием истәлегенә багышлап, көрәш турниры оештыралар. Әйтергә кирәк, хәзер эшләүче күп кенә җитәкчеләрнең остазы, укытучысы һәм киңәшчесе иде ул.

Әнием Сәвия Габдрахман кызының да хезмәт эшчәнлеге Әлмәт районы белән бәйле. Ул Кәләй урта мәктәбендә уку бүлеге мөдире булып эшләде, 1982 елдан балалар бакчасын җитәкләде. Соңрак, яңадан мәктәпкә кайтып, озак еллар дәвамында химия-биология укытты, лаеклы ялга чыккач та, педагогик хезмәтеннән аерылмады. Ул, Аллаһка шөкер, әле дә исән-сау, 90 яшенә җитеп килә. Гомере буе тормышны, кешеләрне, хезмәтне яратты әнием. Өй түрендәге аллы-гөлле чәчәкләрне, бакчадагы яшелчәләрне үзе үстерә. Аның тәрәзә төбендәге гөлләренең матурлыгына хәйран калырлык.

Әтием алдынгы хуҗалык рәисе булса да, без үзебез, кул арбасы тартып, печән, утын әзерләдек, мал тоттык – сыер, сарыклар, куяннар асрадык. Әти 5 гектар чөгендер ала иде дә, җәен шуның чүбен утый идек. Бер гектарына бер капчык шикәр комы, печән бирәләр иде. Унар-унбишәр машина печән ташыдык. Кыскасы, үзебез шулай тырышып, эшләп үстек. «Мин директор малае!» дигән бернинди өстенлек тә юк иде. Киресенчә, күпкә тырышыбрак эшләргә, башкаларга үрнәк булырга туры килде.

Бала вакытта әти белән төн урталарына кадәр хуҗалык буйлап, комбайннар, фермаларны карап, проблемаларны хәл итеп йөри идек. Ул һәрнәрсәне теркәп, язып барды. Куен дәфтәре бар иде аның.

Әтием җитәкче булгач, күрәсең, минем дә җитәкче буласы килгәндер инде. Хезмәт юлымның башлангычы әтинеке кебек үк дияргә була. 1996 елда Казан дәүләт ветеринария академиясен кызыл дипломга тәмамладым. «Васильевская» агрофермасында – ветврач, аннары – Әлмәт районының баш зоотехнигы, «Чишмәле» совхозы директоры, Әлмәт районының авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы булып эшләдем. Бер ел Ютазыда хакимият башлыгы вазыйфасын башкардым, 2011 елдан – Азнакай районында...

– Соңгы елларда районның йөзе үзгәрде: яңа объектлар барлыкка килде, урамнар төзекләндерелде, парклар пәйда булды...

– Дөрес, һәр җитәкче халык өчен эшләргә тырыша. Элегрәк заманның башка таләпләре, үз казанышы, уңышлары булган. Соңгы елларда районда парклар һәм скверларның саны артты, ачык һавадагы бассейн, «Чатыртау» аренасы, мәдәният үзәге, музей төзелде, елга буйлары чистартылды, Актүбәдә мегаферма салынды, тагын бер мегаферма төзелеп килә. Аллаһка шөкер, районыбыз күп өлкәдә алдынгылар сафында. Азнакайга «Татнефть»нең, республикабызның һәм федераль программаларның ярдәме бик зур.

– Элек хакимият башлыкларының күбесе ит-сөт дип йөрде, халыкның мәдәни ягына, тарихына әлләни игътибар итмәде. Сездә берничә ел дәвамында туган җиргә якынаю, аны өйрәнү буенча зур эшләр башкарыла, конференцияләр уздырыла. Юкка чыккан авыллар буенча да беренче китап Азнакайда дөнья күрде, күренекле шагыйрь, кайчандыр үзе дә җитәкче булган Илдус абый Гыйләҗев һәм төбәк тарихын өйрәнүче, язучы Марсель Гарипов (Мирсәй Гариф) белән авыл, район тарихлары турында

китаплар чыгардыгыз. Әдәбият-сәнгать әһелләре белән дә гаять мөһим эш алып барасыз. Гомумән, үрнәк булырлык эшләрегез бик күп.

– Азнакай – бай тарихлы төбәк. Ничек шул байлыкка битараф буласың ди?! Беренче мәртәбә безнең якларны XVIII гасырда яшәгән галим-сәяхәтче Петр Симон Паллас үзенең китабында искә ала. Аның язмаларында бүген дә районыбызның горурлыгы булган Чатыртау сурәтләнә. Әлеге тау хәзер дә райондашларымның һәм бирегә килгән кунакларның яраткан урыны. Сез дә менми калмагыз! Машинаны калдырып, җәяү күтәрелегез! Шунда гына Азнакай табигатенең бөтен гүзәллеген күрергә мөмкин.

Төбәкне өйрәнүче Роберт Зарипов үзенең хезмәтләрендә XIV-XVI гасырларда Тымытык төбәгенә халыкның беренче буыны – күчмә нугайларның буш җирләргә килеп төпләнгәнлеге хакында яза. Шулай итеп, Ык елгасы буенда беренче авыллар барлыкка килгән. Тымытык авылына – 1690, Урсай авылына – 1698, Чалпыга 1703 елларда нигез салынган. Әлбәттә, бу җирләрдә әлеге даталарга кадәр үк борынгы бабаларыбыз дәүләт корган, мал тоткан, йорт-җир биләгән. Моны күп санлы археологик материаллар дәлилли. Аларның бер өлеше «Туган якны өйрәнү» музеенда, мәктәп музейларында урын алды.

«

Күренекле якташларыбыз белән чиксез горурланабыз! Артистлар Әзһәр Шакиров, Нәҗибә Ихсанова, язучы Марсель Галиев... Алар белән гел очрашып, аралашып торабыз. Шөкер, Азнакай ягы бөек шәхесләргә бай.

Районның тарихын җентекләп өйрәнәбез. Үзем дә бу эш белән күптәннән кызыксынам. Төбәк тарихына багышланган китапларны чыгаруда урынбасарым Нәҗҗәт Нәгыймов, археолог Альберт Борһанов, Ниһат Мозаффаров, Илдус Гыйләҗев һәм Марсель Гариповлар зур тырышлык куйды. Азнакай төбәген өйрәнүчеләр авылларыбыз турында унлап китап чыгарды.

Авыллар тарихын язганда аерым шәхесләрне генә түгел, ә анда яшәүче барлык ыруг-нәселләрне дә өйрәнергә тырышабыз. Бу китаплар киләчәк буын өчен зур тарихи мирас булып хезмәт итәр дип ышанам.

Азнакайга нигез салынуга – 250 һәм шәһәр хокукы бирелүгә 25 ел тулу уңае белән чыккан «Азнакай» китабы дүрт – татар, рус, төрек һәм инглиз телләрендә нәшер ителде. Якташларыбызның тормыш юлын, язмышын, ирешкән казанышларын чагылдырган «Язмышыбыз – Азнакай. Азнакаево – наша судьба» дип аталган энциклопедик белешмә дә дөнья күрде.

Күренекле якташларыбыз белән чиксез горурланабыз! Артистлар Әзһәр Шакиров, Нәҗибә Ихсанова, язучы Марсель Галиев... Алар белән гел очрашып, аралашып торабыз. Шөкер, Азнакай ягы бөек шәхесләргә бай. Һәркайсы зур эшләр башкарган шәхесләр. Алар үзләре дә Азнакай

дип яшиләр, туган җирләре белән горурланалар. Әле беркөнне генә Әзһәр абый Шакиров кайтып китте. Аның белән, өмә ясап, туган авылы Ташлыярның зиратын чистарттык, ата-бабалары рухына дога кылдык. Белгәнегезчә, Әзһәр абыйның туган авылы инде юкка чыккан. «Таттелеком» ярдәме белән анда истәлек билгесе куелды.

Азнакайда «Хәтер түрендәге авыллар» исемле китап дөнья күрде. Бу китап районыбызда югалган авылларны хәтердә тоту максаты, аларның исемнәрен тарихта калдыру теләге белән язылды. Анда халыкның тетрәндергеч истәлекләрен дә туплап бирдек. Нәсел оясын төзек тотарга,

нигез-тамырларын корытмаска, бүгенгенең кадерен белеп яшәргә кирәк дигән фикерне яшь буынга җиткерүне үз алдына куя бу басма. Халкы төрле сәбәпләр аркасында китәргә дучар ителгән 36 авыл тарихын үз эченә ала ул. Мондый һәлакәткә дучар булган авыллар бүтән булмасын иде. Тарихтан сабак алырга тырышыйк!

Китапның гамәли файдасы гаять зур булды. Юкка чыккан авыл урыннарында төрле чаралар оештыру, анда яшәп киткәннәр белән очрашу, ул җирләрдә кече Сабан туйлары уткәру, зиратларны чистарту, авыл урынына истәлек такта-стелалар урнаштыру районыбызда матур бер гадәткә

Марсель Галиев,
Татарстанның халык язучысы

Тау рухы

Чатыр тау, дисәм, күңелдә
Чөелә бер горурлык.
Ул горурлык гел дә шулай
Тау рухына торырлык.

Саумы, диеп каршылый ул,
Кочаклап ала җиле.
Тау гынамы – туган җирнең
Кыйбласы, шәмаиле!

Җир йөзендә күпме таулар
Күктән йолдызлар аулый.
Тышаулана яшеннәре,
Бөркетләр томшык чарлый.

Миңа калса, бар таулар да
Бер тамырдан – кардәштер.
Мәңге горур кыялар да,
Энекәш, дип, Чатыр тауга
Ерактан танып дәшер.

Бәллүр бозлы кыяларның
Бүтән ырым-уены.
Миңа газиз үз тавымның
Мәҗүси җил куены.

Менә ул – гомер Чатыры!
Күңелнең үз тәүбәсе;
Ятып ауна күкрәгенә –
Шулдыр бәхет түбәсе!

әверелде. 15ләп юкка чыккан авыл урынына истәлек билгесе куелды. Бу чаралар тагын шуның белән дә әһәмиятле: хәзер читтә яшәүче кешеләр үз ул-кызларына туган нигез урыннарын, әби-бабаларының каберләрен күрсәтә. Авыл булмаса да, андагы зират-каберлекләр саклана, мәрхүмнәр рухы исәннәрдән дога өмет итә бит!

Безнең районда юкка чыккан дип саналган авылларның яңадан тернәкләнеп киткәннәре дә бар. Мәсәлән, Кызыл Йолдыз, Тургай, Агымсу авыллары бүген яңарыш кичерә. «Актүбәнефть» һәм Раувел Ишкәев ярдәме белән, Александровка, Тургай авыллары торгызылды. Фаяз исемле бер якташыбыз Кызыл Йолдыз авылы урынында йорт салды.

Авылларда эшләгән элеккеге җитәкчеләрнең барысына да мемориаль такталар ачылды. Шәһәрдә табибларга, укытучыларга һәм нефтьчеләргә багышланган стелалар бар, әниләргә һәйкәл куелды. Ул шәһәрнең иң үзәгендә – Сөембикә урамында. «Чатыртау» җыены быел унынчы мәртәбә уздырылырга тиеш иде.

Азнакайда электән үк мәдәният бик көчле. Әле күптән түгел генә Азнакай халык театры, «Идел-Йорт» бәйгесендә катнашып, беренче урынны алды. Әлеге театр 1941 елда оешкан. Ул, авыр сугыш чорында да эшчәнлеген туктатмыйча, спектакльләр куюын дәвам иткән. Киләсе елга аның оешуына 80 ел тулачак.

Иҗади, талантлы балалар бездә бик күп. Аларга ярдәм итәргә, сәләтләрен күреп алып, үстерергә генә кирәк. Актүбәдә сәнгать мәктәбе эшләп килә. Анда 1 меңгә якын бала укый. Азнакайдагы мәктәптә 2 меңгә якын бала белем ала.

Россиянең һәм чит илләрнең татарлар яшәгән башка төбәкләре белән дә тыгыз элемтәбез бар. Санкт-Петербургның Красногвардейск районы, Беларусь татарлары, Кырымның Бакчасарай шәһәре, Башкортстанның Бакалы районы, Төркиянең Тарсус һәм Мерсин шәһәрләре белән, үзара килешү нигезендә, мәдәни аралашулар алып барабыз.

Читтә яшәүче милләттәшләребез безнең концертларыбызны сагынып көтеп алалар.

«Шәһәр һәм авыллар өчен тагын да тырышыбрак эшлисе килә»

Марсель Шәйдуллин

Бүгенге Азнакай күренешләре

Адәм балаларының язмышлары төрлечә була» дигән гыйбарәгә ничек ышанмыйсың: егерме йортлы кечкенә генә бер авылдан чыккан ике артист 40 ел буена Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында эшләсен әле. Боларның берсе – Нәҗибә ханым Ихсанова, икенчесе мин идем.

Челтерәп аккан чишмәләрне, әкрен генә аккан инешне, таллар һәм зирек агачларын күз алдыгызга китерегез. Тау битләрендә кызарып пешкән җиләкләр, исле гөлләр, мәтрүшкәләр – кыскасы, санап бетергесез төрле-төрле чәчәкләр. Өйдән ишегалдына чыккач та, синең җаныңны шушы матурлык биләп ала. Бер сүз белән әйткәндә, үзенә күрә бер оҗмах инде. Урманында, җаның ни тели – бар да бар: чикләвек, миләш, шомырт, карлыган, кура җиләге, сирәк кенә булса да, чиясенә кадәр табарга була. Иң кадерлесе – ул җирләрне машина, трактор таптамаган, анда зур көтүләр кермәгән, табигать, ничек бар – шулай сакланган. Су буйларында «Йомры күл», «Тирән күл» дигән чокырлар бар, тирәнлеге – ике-өч, киңлеге – өч-дүрт метр. Шул суларда кушбаш балыклары йөзеп йөри, нинди зурлыкта икәнен бөтен матурлыгы белән күреп була. Шуларга сокланып, кызыгып, ничек кенә тотарга икән, дип уйлап, көннең узып киткәнен сизми дә каласың.

Мин үземнең авылдашларымны менә шул чиста суларда йөзгән балыкларга охшатам. Чыннан да, авыл кешесенең чисталыгы, намуслы булуы әллә кайдан күренеп тора.

Әзһәр Шакиров, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең халык артисты

– Электән үк редакцияләрдә эшләүче кеше буларак әйтәм: кайсы районда укучылар күбрәк, шунда мәдәният тә көчле. Мәдәни тормышы гөрләп тора икән, бу районның хуҗалыгы да республикада иң алдынгы. Азнакай районы да әнә шундыйлардан... Биредә яшәүче халык, килгән кунаклар да, Марсель Зөфәровичны Казанга җитәкче итеп алмасалар ярар иде, ул безгә бик кирәк, дип әйтә. Бу халыкның Сезне яратуы, Сезгә булган ышанычы турында сөйли. Мондый ихтирам теләсә кайсы җитәкчегә эләкми.

– Әлбәттә, халык яраткач, рәхмәтләрен әйткәч, эшләве дә рәхәт. Шәһәр һәм авыллар өчен тагын да тырышыбрак эшлисе килә.

– Киләчәктә Азнакай җирлеген ничек күз алдына китерәсез?

– Яшьләр, зур шәһәрләрдән туеп, районга кайта башлады. Бу бик яхшы күренеш. Әмма Азнакайның үзендә йорт салу өчен җир кишәрлекләре бик аз. Буш урын кебек күренсә дә, аның астыннан газ яки нефть үткәргече уза. Шуңа да авыл җирлекләрен үстерүгә йөз тотабыз. Тиздән мега-ферма төзелешен тәмамлыйсы, Башкортстанның Бакалы районына бара торган юлны салып бетерәсе бар. Май заводында зур реконструкция бара, ул җитештерү күләмен бермә-бер арттырачак. Яңа сәнәгать оешмалары ачып, өстәмә эш урыннары булдырасы иде. Төп игътибарны кече һәм урта эшмәкәрлеккә юнәлтәбез. Хәзер нефтькә генә таянып булмый, төрле юнәлешне үстерү актуаль. Заманча технологияләр авыл хуҗалыгына да бик кирәк. Кызганыч, бу тармакта эшләргә теләүчеләр елдан-ел кими. Аяк киемнәре, текстиль җитештерү буенча сөйләшүләр алып барабыз. Шәһәрне төзекләндерү буенча да башкарасы эшләр күп. Безгә бай тарихлы төбәктә тырышып эшлисе генә кала.

– Сезгә уңышлар телим! ■

Флера Гыйззәтуллина

ҖИР ӘЙЛӘНӘ АЗНАКАЙГА ТАБА

(Поэмадан өзек)

Тыныч кына яшәп буламыни
Башкалада башны торасалып?!
Без тумыштан моңлы, шаулы халык,
Азнакайлы, Чатыртаулы халык.
Без таулардан карап чамалыйбыз
Җирнең кайсы якка әйләнгәнен...
Котлый Казан, котлый Татарстан
Азнакайның уңыш бәйрәмнәрен.
Якташларым, рәхмәт, көч таптыгыз
Җәйге корылыкны арканларга.
«Азнакай», – дип, ничек кояш батты,
«Азнакай», – дип, атты ал таңнар да.
Җанга якын шушы матур сүзне
Риза бит без һәркөн кабатларга.
Азнакайга таба әйләнә җир
Мәртәбәле, җырлы канатларда.
Ихласлыктан кояш кебек балкып
Уй-хисләрен тартып чамасына.
Эшләп мәйдан тоткан авыл халкы
Агыла янә Казан каласына.
Өя, әнә, базар лавкасына
Каклы казын, балын, бавырсагын.
Күкрәк белән томаларга җитеп
Замананың шушы авыр чагын,
Ярминкәләр кайный Казаннарда.
– Менә бусы татлы, менә бусы,
Бәхтең булсын, хәләл ризык, әнә,
Көз артыннан килә елның кышы.
«Азнакай», – дип, анда ут биетеп,
Килеп тора алга кайнар ашлар.
– Уңышлыкка сезнең юк тиңдәшләр,
Күз тимәсен сезгә, аһ, җанашлар.
Без таулардан карап чамалыйбыз
Җирнең кайсы якка әйләнгәнен...
Котлый Казан, котлый Татарстан
Азнакайның уңыш бәйрәмнәрен.

Азнакай музее турында җиде факт

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Азнакай муниципаль районы башлыгы Марсель Шәйдуллин яңа ачылган музей белән таныша. 2016 елның 13 августы

• АЗНАКАЙ «ТУГАН ЯКНЫ ӨЙРӘНҮ МУЗЕЕ» 1992 ЕЛНЫҢ 14 ИЮЛЕНДӘ ОЕШТЫРЫЛА. ӘММА, ҮЗ БИНАСЫ БУЛМАУ СӘБӘПЛЕ, ШӘҺӘР МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫНА УРНАША ҺӘМ ТӨБӘК ТАРИХЫ БЕЛӘН КЫЗЫКСЫНУЧЫЛАРНЫ 1999 ЕЛНЫҢ 18 МАЕНДА ГЫНА КАБУЛ ИТӘ БАШЛЫЙ. МУЗЕЙГА НИГЕЗ САЛУЧЫ ҺӘМ АНЫҢ БЕРЕНЧЕ ДИРЕКТОРЫ – КУЛЬТУРОЛОГИЯ ФӘННӘРЕ КАНДИДАТЫ ГӨЛСЕМ КӘРАМ КЫЗЫ ХИСАМИЕВА.

• Азнакай районы оешуга 85 ел тулу, «Азнакайнефть»нең 60 еллыгы уңаеннан, **2016 елның 13 августында «Туган якны өйрәнү музее» үзенчәлекле архитектура стиле белән агачтан төзелгән өр-яңа бинада ачылды.** Әлеге чарада ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, «Татнефть»нең генераль директоры Наил Маганов һәм башка мәртәбәле кунаклар катнашты. Тантаналы бәйрәм вакытында Азнакай төбәгенә нигез салынуы, җирле крестьяннарның Е.Пугачев баш күтәрүендә катнашуы, һөнәрчелек һәм җирле осталар турында тамаша-шоу күрсәтелүен күпләр хәтерлидер әле.

«Безнең мирас» журналының мөхәррире Ленар Гобәйдуллин, музей директоры Ирина Халикова, журналның баш мөхәррире Ләбиб Лерон һәм археолог Альберт Борһанов. 2020 ел

• Музей биш залдан тора. Беренчесе төбәкнең табигате һәм археологиясе турында. Биредә палеонтологик коллекциядән алып урман һәм урман-дала зонасында яшәүче төрле кыргый җәнлекләрнең карачкыларын, хәтта «Кызыл китап»ка кертелгән байбакны да күрергә мөмкин. Шулай ук Е.Казаков, П.Старостин һәм А.Борһанов җитәкчелегендәге экспедицияләрдә табылган бай археологик мирас та махсус экспозицияләрдә урын алган. **Музей витринасында райондагы иң борынгы экспонат – сармат кылычын да күрергә була.** Чалпы авылы янында табылган әлеге ядкяр б.э.к. III-II гасырларга нисбәтле. Биредә туристларның иң яраткан урыны – Чатыртау тарихы турында кызыклы гына риваятьләр белән танышырга мөмкин.

• ХӘЗЕРГЕ КӨНДӘ МУЗЕЙДА 7 МЕҢНӘН АРТЫК ЭКСПОНАТ САКЛАНА ҺӘМ БУ САН ЕЛДАН-ЕЛ АРТА БАРА.

• Икенче зал районның этнографиясе, мәгарифе, сәүдә һәм сәнәгать тарихы турында сөйли. **Музейда мәгърифәтче, дин галиме Ризаэддин Фәхреддингә багышланган махсус мемориаль бүлмә дә бар икән.** 1889-1891 елларда ул хәзерге Азнакай районына караган Илбәк авылында имам һәм мөдәррис вазыйфаларын башкарган. Кызы Әсма Шәрәф истәлекләренә караганда, әтисе бу авылга килеп урнашканда анда бернинди мәдрәсә дә булмаган. Шул сәбәпле, Ризаэддин хәзрәт үзенә йорт тергезүгә үк мәдрәсә дә салдыра башлаган. Мәдрәсә төзелеп беткәч тә, ул ир балаларга белем биргән, хатын-кызларны да укыту хәстәренә керешкән. 1891 елда Илбәк авылының имамы Ризаэддин хәзрәт ахунлык дәрәҗәсен ала. Бирелә торганда ул «Интизар» исемле китап яза. Озак та үтми, Ризаэддин Фәхреддин Уфага күчеп китә һәм Диния нәзарәтендә казый хезмәтенә керешә.

• Өченче зал исә районның 1930-1960 нчы еллардагы тормышын, Бөек Ватан сугышы чорын чагылдыра. Азнакай районыннан 16565 кеше фронтка китсә, шуларның 7998е яу кырында ятып кала. Фәйзулла Әгълетдинов, Әкърам Вәлиев, Петр Манаков, Иван Никитиннарга тиңдәшсез батырлыклары өчен Советлар Союзы Герое исеме бирелгән. **Шул ук залда танылган каләм әһелләре Мәхмүт Хәсәнов, Марсель Галиев, Флера Гыйззәтуллина, Нур Әхмәдиевнең тормыш юллары һәм иҗаты турында аерым күргәзмәләр бар.**

• ДҮРТЕНЧЕ ЗАЛДА АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕНЕҢ ТАРИХЫ, МӘДӘНИЯТЕ ҺӘМ СПОРТ ТОРМЫШЫ, АЛДЫНГЫЛАРЫ ТУРЫНДА БАЙ МӘГЪЛҮМАТ АЛСАК, БИШЕНЧЕ ЗАЛ ТУЛЫСЫ БЕЛӘН НЕФТЬЧЕ АЗНАКАЙЛЫЛАРНЫҢ ТЫРЫШ ХЕЗМӘТЕ ХАКЫНДА СӨЙЛИ. БИРЕДӘ НЕФТЬ ЧЫГАРУ СКВАЖИНАЛАРЫНЫҢ, НЕФТЬ-ГАЗ ҮТКӘРГЕЧ ҺӘМ САКЛАУ КОРЫЛМАЛАРЫНЫҢ МАКЕТЛАРЫ БАЛАЛАР ӨЧЕН ГЕНӘ ТҮГЕЛ, НЕФТЬ ЧЫКМЫЙ ТОРГАН ЧИТ РАЙОННАРДАН КИЛГӘН ӨЛКӘННӘРГӘ ДӘ КЫЗЫКЛЫ. ■

Киләчәкне тарихка нигезләнеп кору

Альберт Борһанов

Икътисад һәм мәдәният ягыннан караганда, Азнакай районы – Татарстанның иң әһәмиятле төбәкләреннән берсе. Монда нефть чыгарыла, сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы үсеш кичерә. Шулай ук ул үзенең гүзәл табигате, Ык буенда урнашуы һәм республикабызның иң биек ноктасы – атаклы Чатыртауга ия булуы белән дә кызыклы. Азнакай бай тарихи-мәдәни мирасын саклый һәм кадерли белә, мондагы авыллар – чал дәверләрнең изге һәм якты амәнәте.

2011 елда районны яшь, гайрәтле, максатчан, шул ук вакытта гади, халыкчан, ачык Марсель Зөфәр улы Шәйдуллин җитәкли башлагач, болай да күз өстендәге каш булган төбәк тагын да ямьләнә, ныгый, үсә төште.

Мин Татарстанның күп якларында йөрим. Һәркайда да дусларым, танышларым шактый. Азнакайга килгәндә дә таныш-белешләрдән хәл-әхвәл, төбәк хәлләре турында сорашам, район башлыгына мөнәсәбәтләрен ачыклап карыйм. Гадәттә, түрә-карадан тиз туючан мондагы халык, әмма Марсель Зөфәр улы хакында, ун елга якын җитәкче булып торуына карамастан, фәкать матур, җылы сүзләр генә әйтә. «Бездән алып китә генә күрмәсеннәр!» – дип теләк тели азнакайлылар.

Югыйсә барысы да бик җиңел аңлатыла икән: кеше үзе дә яхшы эшли, башкалардан да шуны таләп итә; үзе дә кешеләргә ышана, кешеләр дә аңа ышаналар. Халыкның бер гозере дә игътибардан читтә калмый.

Районадагы эпиграфик мирасны өйрәнү

1846 елның 25 гыйнварында вафат булган Сәхибҗамал Гомәр кызына куелган кабер ташы

Бүгенге көндә районда бихисап сәнәгать, социаль-мәдәни һәм торак биналары төзекләндерелә, яңа юллар салына, парклар, зиратлар карала... Инде ил-иләт бергә җыелып уздырган бәйрәмнәр турында әйтәсе дә юк! Яңа ел, Сабан туйлары, төрки халыкларның «Чатыртау» фестивале, Ык буе җирлеге тарихына багышланган дөньякүләм яисә илкүләм конференцияләр, якташлар җыеннары... Болар барысы да гаять югары дәрәҗәдә уза, Азнакай халкын берләштереп кенә калмыйча, аны башка милләтләр белән дә багланышлар булдырырга этәрә. Азнакай бүген Башкортстаннан, Төркиядән, Беларусьтан һәм үзгә кыйтгалардан килеп, кунак булып киткән мосафирларның теленнән төшми.

Районда мәдәниятне, мәгарифне, сәламәтлек саклау һәм спортны үстерүгә дә күп көч куела. Яңа мәктәпләр, балалар бакчалары, китапханәләр, спорт комплекслары һәм мәдәният йортлары төзелә, искеләре төзекләндерелә.

2015 елда «Туган якны өйрәнү музее»ның яңа агач бинасы корылып җитте. Азнакай шәһәрендә – яңа мәчет, Актүбә бистәсендә яңа чиркәү салынды. «Азнакай» республика шифаханәсе (директоры һәм баш табибы – Р.И.Дәүләтшин) гөрләп эшли, «Маяк» газетасы (баш мөхәррире – Ф.Ф.Шәйхуллов) һәм «АТР» телекомпаниясе район тормышын даими яктыртып бара. Азнакай район китапханәсендә очрашулар, презентацияләр уздырыла. Ветераннар, хатын-кызлар, яшьләр оешмалары район үсешенә өлеш кертә.

Монда төбәкне һәм авылларны, атаклы якташларны, шул исәптән сугыш каһарманнарын, тыл ветераннарын, аларның гомер мизгелләрен өйрәнү эше дә киң җәелгән. Роберт Зарипов, Самат Мирсәетов, Марсель Гарипов, Нәҗәт Нәгыймов, Мирфаяз Солтанов, Гөлсем Хисамиева, Рүзилә Шәйхуллова, Эльвира Ихсанова, Гүзәл Якупова, Фәйрүзә Сабирова, Ирина Халикова, Данияр Мохитов, Гөлфия Мостафина, Ләйсән Габдуллина, Лилия Гәрәева, Анатолий Байков, Мөнирә Габделвәлиева, Энҗе Зәкиева, Эльза Мифтахова, Галина Лобанова кебек фидакярләр архив һәм музей материалларын барлау, тарихны һәм төбәкне өйрәнүгә багышланган китаплар әзерләү, мәкаләләр язу буенча зур эшләр башкара.

Район башлыгы М.З.Шәйдуллинның һәрьяклы ярдәме белән, аның урынбасары Н.М.Нәгыймов һәм төбәкне өйрәнүче М.М.Гарипов җитәкчелегендә, район хакимияте каршында фәнни-методик төркем эшләп килә. Ул системалы рәвештә борынгы мирасны кайтару – туган җирнең тарихын өйрәнү белән шөгыльләнә. Әлеге төркем ярдәмендә «Азнакай – Азнакаево. Очерки о людях и истории» (Казан, 2013), «Язмышыбыз – Азнакай. Азнакаево – наша судьба» (Казан, 2014), «Азнакай. Хәтер түрендәге авыллар. Тепло покинутых деревень» (Казан, 2016), «Сукаеш шәхесләре. Личности Сукаяшево» (Казан, 2016), «Бай тарихлы Урманай» (Казан, 2018) кебек китаплар дөнья күрде. Әле тагын ике китапны басмага әзерлиләр. Район башлыгы М.З.Шәйдуллин тырышлыгы белән, Азнакайның үзендә, авылларда, хәтта Казанда да әлеге хезмәтләрнең презентацияләре зурлап үткәрелә. Бу эштә аларга Бөтендөнья татар конгрессы, Татарстан Республикасының Төбәкне өйрәнүчеләр җәмгыяте ярдәм итә. Мәсәлән, 2019 елда башкалабызда уздырылган шундый чараларның берсендә 40лап китап һәм Азнакайда оештырылган фәнни-гамәли конференцияләр материалларыннан (алар, нигездә, Татарстанның һәм Башкортстанның Ык буе районнарын өйрәнүгә багышланган) төзелгән күмәк җыентыклар тәкъдим ителде.

Шунысын искәртү зарур: 2009-2019 нчы елларда А.Ә.Борһанов җитәкчелегендә үткәрелгән тарихи-археологик тикшеренүләр һәм җирле тарихчылар, эзтабарларның хезмәте нигезендә, Татарстанның көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш районнарында 20дән артык фәнни-гамәли конференция уздырылды, аларда Татарстаннан, Башкортстаннан, Оренбург өлкәсеннән һәм Россиянең башка төбәкләреннән, кайбер чит илләрдән байтак белгечләр катнашты, уртак эшчәнлекнең нәтиҗәсе буларак, фәнни монографияләр, җыентыклар нәшер ителде. Ык буе авыллары Сабан туе кысаларында «Ык елгасы буенда кеше һәм табигать. Тарих һәм хәзерге чор» дип исемләнгән дүрт конференция үткәрелде, район башлыгы М.З.Шәйдуллин фатихасы белән, Азнакайда «Көнчыгыш Татарстанда кеше һәм табигать. Азнакай районы: тарих һәм мәдәният проблемалары» (2014)

Урсай авылының мәктәп музеендагы Алтын Урда чоры ядкярләре

> «Борынгы зиратларда (XV-XVI гасырлар) шушы көннәргә кадәр төрки каһанлыкларга (VI-VII гасырлар) хас булган тамгалы кабер ташлары саклана. Димәк, борынгы төрки традицияләр монда шактый озак җуелмый «яшәгән».

һәм «Көнчыгыш Татарстанда кеше һәм табигать. Юкка чыккан һәм тарихи авыллар: өйрәнү, саклау һәм торгызу» (2017) кебек конференцияләр уздырылды. Азнакай районы җитәкчелегенең тарихка һәм наширлек эшенә игътибары җирле халыкның үз тамырлары, үткәннәре, нәсел-шәҗәрәсе белән кызыксынуына да этәргеч булды.

Бу елның августында, Татарстан АССР оешуга – 100 һәм Бөек Ватан сугышында җиңүгә 75 ел тулу уңаеннан, Азнакайда «Ык елгасы буенда кеше һәм табигатьнең тарихи үсеше. Азнакай районының һәм Көнчыгыш Татарстанның ТАССР икътисады һәм татар халкы үсешенә керткән өлеше» дип аталган тагын бер конференция үткәрү, материалларын аерым җыентык итеп бастыру ниятләнелә.

***

Азнакай районы һәм, гомумән, Ык буйлары археология, эпиграфика, мәдәният һәм архитектура җәһәтеннән моңарчы бик аз өйрәнелеп килде. Узган гасырның 1950 нче елларында А.П.Шәкүровның һәм 1970 нче елларында Е.П.Казаковның тикшеренүләреннән кала, бу якка фәнни-эзләнү максатыннан аяк басучы булмады. Азнакай һәм башка районнарның Ыкка терәлеп торган өлешендә генә археологик эшләр башкарылды, бронза чоры (б.э.к. II меңьеллык уртасы), Алтын Урда чоры (XIII-XIV гасырлар) һәйкәлләре табылды. «Археологические памятники Татарской АССР» (Казань, 1987) китабында Азнакай районының 7 археология һәйкәле турында язылган. Болар – Сарлы, Константиновка, Сасыкүл, Сөендек, Күктәкә, Тымытык һәм Урсай авыллары янында табылган бронза чоры һәйкәлләре. Урта гасырларга караган бер генә татар-мөселман эпиграфик табылдыгы да телгә алынмаган.

«Археологические памятники Восточного Закамья» (Казань, 1989) белешмәсендә *бронза һәм Алтын Урда чорларына* караган 36 археологик һәйкәл турында өстән-өстән генә әйтелеп узылган. Монда беренче тапкыр Иске Урсай зиратының урта гасыр кабер ташлары күрсәтелгән.

2011 елда җиң сызганып эшкә алынганчы, без төрле чыганаклар аша Азнакай җирендә 40лап чор һәм дәвер һәйкәлләре булырга тиешлеген белә идек инде. Әмма аларның күбесе җир һәм төзелеш эшләре нәтиҗәсендә юкка чыкканын һәм Ык суы белән юылганын да чамалый идек. Искәртик: борынгы зиратларда (XV-XVI гасырлар) шушы көннәргә кадәр төрки каһанлыкларга (VI-VII гасырлар) хас булган тамгалы кабер ташлары саклана. Димәк, борынгы төрки традицияләр монда шактый озак җуелмый «яшәгән». Тикшеренүләр бу якларда, күчмә ырулар белән бергә, игенчеләр, сәүдәгәрләр һәм һөнәрчеләрнең дә утрак тормыш алып барганлыгын күрсәтте. Кайбер кабер ташларында һәм язма истәлекләрдә аерым

Археолог Альберт Борһанов төзегән җыентыклар

авылларның кайчан һәм ничек барлыкка килүе турында мәгълүмат табарга мөмкин. Азнакай районында һәм Көнбатыш Башкортстан белән чиктәш төбәкләрдә авыл саен ике-өч, хәтта дүртәр зират барлыгын исәпкә алсаң, биредә халыкның һәрвакыт күпләп яшәгәненә инанасың. Димәк, бу тарафның урыс дәүләтенә кушылганчы (ягъни нугай чорында) ташландык җирләр булуы (моңарчы шундый фараз яши иде) дөреслеккә туры килми.

***

Безнең мәгълүматлар буенча, Азнакай районында бүген Урта гасырга һәм Яңа чорга караган 50дән артык археологик объект, 180ләп кабер ташы булган 30дан артык зират бар. Археологик объектлар арасында – 27 тукталу урыны, 10 курган каберлеге, 10нан артык сала урыны... Аларның төгәл санына чыгарга мөмкин түгел. Ләкин, хакыйкатькә якынаер өчен, тикшеренүләрне дәвам итәргә кирәк.

Азнакай районындагы һәм Татарстанның көнчыгышындагы иң борынгы һәйкәлләр таш гасырга карый. Бүген Урсай авылы музеенда мамонт, мөгезборын һәм башка җанварларның сөякләре, казык тешләре, шулай ук таштан ясалган эш кораллары саклана. Митрәй, Әсәй, Тымытык һәм Сарлы авылларында, Ык һәм аның кушылдыгы Эстәрле ярларында табылган *неолит чоры* һәйкәлләре җирле халыкның сунарчылык һәм җиләк-җимеш, гөмбә җыючылыктан җир эшкәртү һәм мал асрауга күчү вакытының күркәм үрнәкләре булып тора. Алар эрләү, туку, савыт-саба һәм эш кораллары җитештерү белән шөгыльләнгән. Урсай авылы янында табылган бизәкле савытлар (неолит һәм энеолит чоры) Ык, Зәй һәм Агыйдел буйларында болан, аю, кабан дуңгызы, байбак кебек җан ияләренең яшәве турында сөйли.

Безнең эрага кадәр III меңьеллыкта Татарстанның көнчыгыш районнарында бакырдан, бронзадан эшләнгән кораллар киң кулланылыш таба. Бу вакытны *бронза чоры* дип атыйлар. Азнакай районында әлеге заманга караган 34 объект бар, алар Татар Шуганы, Урсай, Түбән Эстәрле, Чәкән, Урманай һәм Сөендек авыллары тирәсендә урнашкан.

Тимер һәм *Идел Болгарстаны чорлары* һәйкәлләре Азнакай районында аз өйрәнелгән әле. Ләкин алар, тәгаен, булырга тиеш. Чөнки күрше районнарда андый табылдыклар бар.

Алтын Урда чоры мәдәниятенең Азнакай җирлегендәге эзе турында без 2011 һәм 2013 елларда уздырылган тикшеренү эшләренә нигезләнеп сөйли алабыз. Урта гасырга караган археологик объектларның саны 11гә җитә. Сүз, беренче чиратта, Иске Урсай һәйкәлләре (XIV-XVI гасырлар) турында бара. Табылдыклар монда чүлмәк ясау һәм металлургия производствосы булуы турында сөйли. 2013 елда без таш-кирпеч корылмаларга, әвәләп ясалган бизәкле савыт-сабага, тимер эшләнмәләргә (чуен казан калдыгы, ат авызлыгы, пычак, урак һ.б.), муенсаларга юлыктык. Табылган сөякләр җирле халыкның ат, мөгезле эре һәм вак терлек асравы, шулай ук кыргый җанварлар аулавы, балык тотуы турында мәгълүмат бирә.

Язма чыганаклар (урыс елъязмалары һәм татар шәҗәрәләре) XV-XVII гасырларда Кама арьягының Казан ханлыгына керүен, ә көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш җирләрнең Нугай Урдасына каравын икърар итәргә нигез булып тора.

Әлегә Азнакай төбәгенең XV-XVIII гасыр һәйкәлләре бик аз өйрәнелгән, шуңа күрә биредә яшәгән татар-мөселман халкының матди мәдәнияте турында тәфсилләп сөйләү мөмкин түгел.

Бу якларның табигатен һәм тарихын өйрәнүчеләр өчен Чатыртау тирәсендәге объектлар аеруча кызыклы. Урта диңгез буе һәм Кубань якларыннан XVI-XVIII гасырларда бирегә күчеп килгән нугай татарлары бу географик объектны үзләренең Кырымдагы Чатыртау (Чатыр-даг) хөрмәтенә шулай атаган дип санала. Тау битендә үз вакытында Емельян Пугачевның бер алае да ыстан корып торган, имеш...

Ык буе җирлегенең, аерым алганда, Азнакай районының табигате дә, тарихы да гаҗәеп бай. Алда безне яңа экспедицияләр, яңа ачышлар, кызыклы конференцияләр һәм татар дөньясының күркәм бишеге – Идел-Урал төбәгенә багышланган бик күп фундаменталь хезмәтләр көтә дип ышанып калабыз. ■

Азнакайга багышланган китаплар күргәзмәсе

Кантончы татарлар тарихы

Галим Хисамиев*

Кантончы мөселман балаларын чукындыру турындагы документлар. XIX гасырның беренче яртысы

Россиядә кантончылык

Россиядә кантончы атамасы 1805 елда барлыкка килә. Кантон – французча «округ» дигәнне аңлата. Кантончылар – түбән хәрби чиннарның, гади генә әйткәндә, солдатларның тумыштан хәрби ведомствога караган, үсеп җиткәч хәрби хезмәткә алынырга тиешле балигъ булмаган ир балалары.

Россиядә мондый структураның нигезләре Петр I заманында ук салына башлый. Патша фәрманы буенча 1721 елда гарнизоннарда (округтагы полкларда) 50 урынлы солдат балаларын укырга-язарга һәм һөнәргә өйрәтү мәктәпләре булдырыла. 1732 елда укучы балаларның саны 4 меңгә җиткерелә. Мәктәпкә 7 яшьтән алып 15 яшькәчә балалар алына башлый. 1758 елдан барлык солдатларның ир балалары Хәрби ведомствога беркетелә. XVIII гасыр азагындагы сугышларда бик күп бала ятим калу сәбәпле, 1798 елда Санкт-Петербургта хәрби ятимнәр йорты оештырыла. Шуңа бәйле рәвештә, гарнизон каршындагы мәктәпләрне «Хәрби ятимнәр мәктәбе» дип йөртә башлыйлар. Бу мәктәпләрдәге балалар саны 16400гә җиткән. 1805 елда, Николай I идарә иткән чорда, округтагы полклар шушында яшәүчеләр хисабына тулыландырып торылганга, «Хәрби ятимнәр мәктәбе» «Кантончылар мәктәбе» дип үзгәртелә, ә анда

*** Галим Хисамиев** – Казан дәүләт медицина университеты доценты, инженер-химик, техник фәннәр кандидаты. Туган төбәге һәм чукындыру сәясәте тарихын, ислам белән православие мөнәсәбәтләрен өйрәнә.

тәрбияләнүчеләрне «кантончылар» дип йөртә башлыйлар. 1824 елда әлеге мәктәпләр Хәрби тораклар департаменты (Департамент военных поселений) башлыгы, артиллерия генералы граф А.А.Аракчеев карамагына күчкән. 1826 елдан Кантончылар мәктәбе, хәрби частьләрдәгечә, батальоннарга, эскадрон, дивизион, ярым батальоннарга һәм роталарга бүленгән. Кантончылар мәктәбе Россиянең 52 шәһәрендә булдырылып, алар 6 укыту бригадасына берләштерелгән. Бригада башында генерал торган. Кантончылар мәктәпләрендә ел саен дистәләрчә мең ир бала тәрбияләнгән. 1857 елга аларның саны 37 меңгә җитә. Мәктәпләрдә, кантончыларның күпләп үлүе сәбәпле, составны даими тоту өчен, һәр полк каршында резерв батальон булдырылган. Үлгән кантончы урынына резерв батальоннан башка кантончы алына килгән.

Рекрутлыкка алынгач, крестьян Хәрби ведомство милке булып саналган. Хезмәт иткән вакытта солдат өйләнә алган. Шул сәбәпле, хәрби частьләр каршында солдат бистәләре дә барлыкка килә торган булган. Солдатларның ир балалары тумыштан Хәрби ведомствога буйсынган, ягъни солдат булып туган. Кече яшьтән аны хәрби хезмәткә әзерләгәннәр. Шулай итеп, солдат балалары да армиянең киләчәк кадрларына әверелгәннәр. 18 яшьтән солдатка алынганга, дәүләт аларны шушы яшькә кадәр ашатып, тәрбияләп торган. Хәрби хезмәткә алынган солдатның хатыны да крепостнойлыктан азат ителгән.

Кантончы 10-14 яшенә кадәр гаиләсендә тәрбияләнгән. Урта (7-12) яшьләрдәге кантончыга азык-төлек бирелгән. Яше җиткәч, ул, кантончы буларак, казна хисабына яшәгән. Олырак (12-18 яшьлек) кантончы, азык-төлектән тыш, акча (3 сум) алган, хәрби һәм башка һөнәрләргә, грамотага өйрәтелгән. Кием-салымны, аяк киемен үзе тегәргә тиеш булган.

Аңа 12 яшь тулгач, ата-анасы яки туганнары ир баланы өяз үзәгендәге Инвалидлык канцеляриясенә алып барырга тиеш булган. Аннан, кантончыларны төркемнәргә туплап, җәяүләп Казанга озатканнар. Юлда аларны, гадәттә, арестантлар төркеменә кушып йөрткәннәр, ә кичләрен бөтенесен бергә острогларга (төрмәләргә) бикләп куя торган булганнар. Балалар каторжаннар белән бергә төн кунганнар. Сасы тир һәм нәҗес исе иснәп, чылбыр, ыңгырашу тавышларына җәфаланып, өстәвенә, такта ятакларга яткан бала-чага йоклый алмый интеккән, курыккан. Аларның азык-төлеген, акчаларын каторжаннар урлап яки талап алганнар. Бирмәгән очракта кыйнаганнар. Алҗып-талчыгып, Казан каласына җиткәч, аларны алып баручы унтер-офицер кантончыларны мәктәп башлыгына тапшырган.

Кантончылар мәктәбенә беркетелгән ир балалар арасында солдаткалардан, тол хатыннардан законсыз туган ир балалар саны шактый булган. Соңрак кантончылар мәктәбенә чегән, поляк, раскольник һәм яһүдиләрнең балаларын да ала башлаганнар. Алар составына яшь сукбайлар, җинаятьчеләр, тәрбиясез калган балалар (беспризорниклар) да кертелгән.

Казан өязе кантончылары

Кантончыларның бер өлешен Казан тирәсендәге чиркәүле, нигездә, рус авылларына таратканнар. 1825 елда Казан шәһәрендә Хәрби кантончыларны урнаштыру комитеты оештырылган. Бу Комитет, янгыннан соң калган Казан Кремле эчендәге ярым җимерек арсенал һәм кою (литейня) биналарын төзекләндереп, кантончыларны шунда урнаштыру тәкъдиме белән чыкса да, эшкә 1827 елда гына тотынганнар һәм ул ун ел диярлек дәвам иткән. Бу вакыт эчендә кантончылар элеккеге күчермә (пересыльная) төрмәдә урнашканнар. Адмиралтейство канторасының бер өлеше (Покровская, хәзерге К.Маркс урамында) кантончылар лазареты буларак кулланылган.

1836 елның августында император Николай I кантончылар батальоны өчен Казан Кремлендә корыла торган биналарны карап киткән, эшне тизләтүне таләп иткән. Төзелеше ун елга сузылган комплекс 1837 елда гына кулланышка тапшырылган. Аның составында фельдшерлар бүлмәсе белән лазаретлар, лаборатория, аптека, хезмәткәрләр өчен хастаханә ятаклары да каралган булган. Кантончылар комплексы хәзерге «Пушечный двор» һәм Кол Шәриф мәчете урнашкан җирләрне, «Хәзинә» галереясы һәм «Казан Эрмитаж үзәге» урнашкан биналарны үз эченә алган. Кантончылар шушы биналарда 1838 елдан гына яши башлый, соңрак аның нигезендә Юнкерлар училищесы булдырыла.

Иң башта кантончылар гарнизон мәктәпләрендә (Суворов училищесы сыман) хезмәт иткән. Анда алар грамотага, ә сәләтлеләре артиллерия, инженерлык, ораторлык, хәрби медицина, топография, музыка буенча әзерләнгән. Алардан махсус белем таләп ителгән гаскәриләр әзерләгәннәр. Кул эшенә оста булганнары исә столярлык, тимерче, итекче кебек һөнәрләрне үзләштергән. 15 яшь тулганнан соң, сәләтле балалар тагын 3 ел укыган, ә калганнарын хәрби хезмәткә җибәргәннәр. Кантончылык хәрби стажга саналмаган.

Мөселман һәм яһүд кантончыларны чукындыру

Хезмәткә алынгач, кантончыларны көчләп чукындыра да торган булганнар. Чукынмаганнарны ач тотканнар, йоклатмаганнар, кыйнаганнар, суга чумдырганнар, салкын урамда тотканнар... Кыскасы, яхшы итеп «үгетләгәннәр». Чукынган кантончыга 25 сум акча, төрле өстенлекләр бирелгән. Шулай да алар биш ел буена вазыйфа алырга хокуксыз булып калган.

Чукынган балаларга рус исем һәм фамилияләрен биргәннәр. Императорның ай саен кантончыларның христиан динен кабул итү санын тикшереп торуы турында язмалар бар. Аңа биргән рапортларда ил башлыгы «очень мало», «весьма неуспешно», «недоволен малым успехом обращения в православие» дигән имзалар калдырган. Бу өлкәдә тырышкан командирларны ул мактаган, орденнар белән бүләкләгән, хезмәте буенча югары күтәргән.

Чукынганнан соң, кантончыларны башка милләт кешеләре арасына билгеләгәннәр. Яңадан үз диненә кайткан очракта төрмәгә япканнар. Христиан динен кабул иткән кантончы бары тик христиан динендәге хатын-кызга гына өйләнә алган. Табигый, аның балалары да рус телле һәм христиан булган. Хәрби хезмәттән соң, «Николай солдатлары» туган җирләренә кайта алган. Бу вакытта инде аларга 43-45 яшь булган. Аларга тормышны өр-яңадан башларга туры килгән: ата-аналары үлгән, туган-тумачасы аны инде оныткан, үзе дә туган телен белми диярлек... Шул рәвешле, аларның күбесе, туган җиренә әйләнеп кайтмыйча, хезмәт иткән җирендә торып калган...

Балалар үзләре теләп чукынганмы?

Безнең якларда XIX гасыр башында кантончыларны чукындыруда Казан хәрби ятимнәр бүлеге (Военно-сиротское отделение) күзәтүчеләре (смотритель) подполковник Деревянко, капитан Петров, Эчке Вятка гарнизон батальоны командиры, подполковник Ростовщиков, Казан дары заводы командиры генерал-майор Тебеньков, Казан гарнизоны коменданты генерал-майор һәм кавалер Осип Соколовский, Казан кантончылар батальоны командиры подполковник Криднер шактый көч куйганнар. Аларның беренчеләре Соколовскийга балаларның «үзләренең чукынырга теләве» турында рапорт биргән. Ул, үз чиратында, шуңа таянып, Казан һәм Зөя епископы Владимирга, соңрак епископ Филаретка балалар чукындырылырга тиешле чиркәүне,

чиркәү әһелләрен билгеләүне, «эшнең» тәмамлануын хәбәр итүне сорап мөрәҗәгать иткән. Мәсәлән, мөрәҗәгатьләр мондый рәвештә язылганнар:

«Ваше Преосвященство, Амвросій, Милостивый Архипастырь!

Смотритель здешняго военно-Сиротского Отделенія Г.Подполковникъ Деревянка, рапортомъ сего числа донесъ мне, что квартирующій Казанскаго уезда сельца Шигалеево воспитанникъ Магометанскаго Закона ***Кафетулла Ишмухаметовъ 12-летній, имеетъ желаніе принять веру Греко-Россійскаго Исповеданія.*** *– Посему обращаясь о семъ къ Вашему Преосвященству покорнейше прошу, приказать кому следуетъ предписать села Шихазды Священнику съ темъ, чтобы о нареченномъ Христіанскомъ имяни и воспріемнике его – Ишмухаметова дано было мне знать; и о последующемъ по сему предмету ожидая Уведомленія. – с истиннымъ почтеніемъ и совершанного преданностію имею честь быть Вашего Преосвященства Милостиваго Архипастыря покорнейшій Слуга Соколовскій. №272, июня 6 дня 1824 года»* [ТР МА, 4 нче фонд, 56 нчы тасв., 11 нче эш].

Тагын бер шуңа охшаш документ:

«Ваше Преосвященство, Милостивый Архипастырь!

Вверенные мне батальоновъ кантонисты Магометанскаго Закона ***Сабитъ 13-летній и Гайса Фаткулловъ 11-летній изъявили желаніе принять веру греко-россійскаго исповеданія.*** *Доводя о семъ до сведенія Вашего Высокопреосвященства, честь имею всепокорнейше просить предписать Крестовоздвиженской церкви священнику Симеону Смирнову о просвященіи святымъ крещеніемъ кантонистовъ с темъ, чтобы онъ, о нареченныхъ имъ христіанскихъ именахъ и воспріемникахъ их меня уведомилъ. Съ глубочайшимъ Высокопочитаніемъ и беспредельно преданностью быть честь имею Вашего Преосвященства Милостиваго Архипастыря покорнейшій Слуга Евгеній Комлевскій. №1783, сентября 25 дня 1829 года, г. Казань»* [ТР МА, 4 нче фонд, 61 нче тасв., 34 нче эш].

Менә шулай итеп, христианлыктан ваз кичмәсен, кичкән очракта җаваплылыкка тарту өчен, Сенат Указы (24.12.1750 ел) нигезендә, чукындыру язма рәвештә теркәлеп барылган. Кыскасы, дәүләтнең чукындыру машинасы тәртипкә салынган һәм өзлексез эшләп торган…

11-12 яшьлек балалар үзләре теләп чукындылармы икән? Бу – бәхәсле мәсьәлә. Әмма мондый мөрәҗәгатьләр хуплап кабул ителгән, аңа епископ имза салган һәм үтәү өчен Казан дини консисториясенә юллаган. Ул вакытларда әле Казан губернасында кантончыларны җыеп тәрбияли торган бердәм бина яки комплекс булмау сәбәпле, аларны руслар яшәгән төрле авылларга урнаштырганнар. Шуңа күрә Консисториядән чиркәү әһеленә баланы чукындыру турындагы Указ тапшырылган. Журналдан күренгәнчә, утырышларда архиепископ Филарет, архимандрит Феофан, игумен Петр (Кизический монастырь), протоиерейлар – Борис Поликарпов, Флегонт Талантов (Благовест кафедраль соборыннан), Гурий Листочкин, Филипп Раев, сәркатип Андрей Сызранский, канцеляристлар – Воронов, Саблуков, копия ясаучылар – Разумовский, Иван Чернов катнашкан. Консисториядән бирелгән Указга таянып, чиркәү руханилары балаларны чукындырган, аларга русча исем кушкан, рус әтисе (восприемник) исеме буенча аңа фамилия бирелгән. Рухани «башкарган гамәле» турында Консисториягә рапорт белән хәбәр иткән. Соңгысы Казан губерна палатасына чукындырылган бала турында мәгълүмат җиткергән. Кантончыларны чукындыруга Казан һәм Чистай шәһәрләрендәге (Чистай олы атакае – благочинный, Спас соборы иерее Петр Зефиров), Казан тирәсендәге авыллардагы чиркәү, Казан губерна төрмәсендәге Троица чиркәве (Василий Телеманов) руханилары

җәлеп ителгән. Татарстан Милли архивында Казан кантончылары батальонының законлы укытучысы, Николо-Ляпухов чиркәве рухание Александр Нелидовның Казан һәм Зөя архиепископы Филаретка язган рапорты (2.01.1835) саклангaн. Анда: *«Консистория тарафыннан миңа җибәрелгән указ (№4801, 17.10.1833) буенча түбәндәгеләрне хәбәр итәм: 1835 елда минем тарафтан* ***34 яһүди кантончы чукындырылды.*** *Аларның 4есе (Лейбах Абрамзон, Хонорь Линчик, Ицко Наум, Эмям Беловидский) 1834 елда чукындырылмыйча калган иде. Кантончыларны чукындыру вакытын, бирелгән исемнәрен, рус әтиләре күрсәтелгән исемлекне һәм подполковник Криднер таләп иткән барлык мәгълүматны Сезгә җибәрәм. 3 кантончы (Берко Радицкий, Цаль Фигибер, Шлиом Енщик) начальство тарафыннан чукындыруга китерелмәде. Китерелүгә, мин аларны чукындырачакмын!»* – дип язылган. Рапорт өстенә архиепископ (3.1.1836) «1836 елда чукындырырга» дигән карар салдырган [ТР МА, 4 нче фонд, 68 нче тасв., 1 нче эш].

Шуңа охшаш тагын бер документ саклана: *«Милостивый Архипастырь! Исправляющий должность смотрителя Казанского военносиротского отделения капитан Петров рапортом донес мне, что воспитанники гарнизонного ведомства магометанского закона, квартирующиеся сдешнего уезда в селе Пермяках* ***Зюкей Зюкеев, 11 лет****, и в селе Шигалеево* ***Насибулла Рахметуллин, 10 лет****, имеют желание принять веры греко-российской исповедания. Почему обращаемся предписать окрестить о первом села Пермяков, а другого – села Шихазды. 31 марта 1824 г.».*

Бу боерыкның үтәлүе турында хисап та бирелгән. Анда: *«1) Воспитанник Казанского военносиротского отделения магометанского закона Зюкей Зюкеев, 11 лет, квартирующийся в селе Пермяках, окрещен по собственному желанию 7 апреля 1824 года священником села Высокой горы Никита Сератьев, дьякон Петр Андреевым; наречен именем Николай, восприемник – Казанского военносиротского отделения учит. помощник Изот Русанов. 2) Воспитанник Казанского военносиротского отделения магометанского закона Насибулла Рахметуллин, 10 лет, квартирующийся в приходе Шигали, крещен 14 мая 1824 года. Наречен Александром, восприемник – помещик Тептярского казачьего полка есаул Петр Федоров-Глухов. Священник села Шихазды Никола Матвеев»,* – дип язылган [ТР МА, 4 нче фонд, 56 нчы тасв., 16 нчы эш].

Татарстан Милли архивының Казан рухани консисториясенә караган 4 нче фондында тагын берничә «эш» саклана. Кантончыларның кайларда урнашуы, яшь балаларның кайда һәм кем катнашында чукындырылуы турында кыскача гына мәгълүмат бирү урынлы булыр дип уйлыйм.

Казан гарнизон полкы командиры полковник Быстрыкин тәкъдиме белән, рядовой **Хәйбулла Фәизов**, Консистория Указы (№2605, 10.04.1828) буенча, Казан кафедраль Благовест соборының ключары, протоиерей Флегонт Талантов тарафыннан чукындырылган (13.05.1928). Аңа Николай исеме бирелгән.

Кунтечи авылында фатирга кертелгән 11 яшьлек кантончы **Хәйбулла Ибәтев**, Казан рухани консисториясе Указы (№4029, 29.05.1824) буенча, Никольское (элеккеге Карай авылы) авылында рухани Иоанн Сергеев тарафыннан чукындырылган (2.06.1824). Аңа Федор исеме бирелгән, рус әтисе – коммерция советнигы Петр Никитич Миллер.

Казан өязенең Ключи авылында фатирга кертелгән 8 яшьлек кантончы **Исинка Туганаев**, Консистория Указы (№4077, 27.06.1824) буенча, Казан өязе Иваново чиркәве рухание Иван Васильев тарафыннан чукындырылган (24.09.1824). Аңа Александр исеме бирелгән, рус әтисе – хәрби ятимнәр бүлеге укытучысы Михаил Васильев-Юрков.

Никольское авылында фатирга кертелгән 14 яшьлек кантончы **Әхмәди Бәхтияров**, Консистория Указы (№6068, 27.08.1824) буенча, Никольское (элеккеге Карай авылы)

авылында рухани Иоанн Сергеев тарафыннан чукындырылган (18.08.1824). Аңа Михаил исеме бирелгән, рус әтисе – подполковник Владимир Иванов-Юшков.

Осиново авылына җибәрелгән 9 яшьлек **Бихта Луконкин**, Казан рухани консисториясе указы буенча, Казан өязе Иваново авылы чиркәве рухание Иван Васильев тарафыннан чукындырылган (27.04.1824). Аңа Симеон исеме бирелгән, рус әтисе – хәрби ятимнәр бүлеге укытучысының ярдәмчесе Андрей Васильев.

Богородское авылында фатирга кертелгән 9 яшьлек **Әхмәт Шмаев**, Консистория Указы (7.04.1824) буенча, шушы авылның рухание Сергей Кедров тарафыннан чукындырылган (27.04.1824). Аңа Георгий исеме бирелгән, рус әтисе – укытучы Михаил Белов.

10 яшьлек **Пайбахта Ачеев**, Консистория Указы (№7426, 25.10.1826) буенча, Казан шәһәре Владимир соборы протоиерее Филипп Раев тарафыннан чукындырылган (9.12.1826). Аңа Даниил исеме бирелгән, рус әтисе – Казан сәүдәгәре Яков Семенов-Агапов булган.

Казан дары заводының мәрхүм солдаты **Зәбир Абдулов**ның 6 яшьлек улы Ибраһим Зәбиров, Консистория Указы буенча, Казан Грузин Алласы чиркәве рухание Алексей Потоцкий тарафыннан чукындырылган (5.04.1829). Аңа Ефемий исеме бирелгән, рус әтисе – титуляр советник Александр Григорьев-Дротаевский, әнисе – титуляр советник Марья Антонова-Ратманова [4-61-25].

Воскресенское авылына җибәрелгән 10 яшьлек **Шәмсетдин Халитов**, Консистория Указы (№1482, 5.03.1825) буенча, Воскресенское чиркәве рухание Иван Осипов тарафыннан чукындырылган (15.03.1825). Аңа Александр исеме бирелгән, рус әтисе – Казан сәүдәгәре Иван Александров-Блюденов.

Казан кантончылар батальоныннан 13 яшьлек **Мөхәрләм Габдрахманов**, Консистория Указы (№4801, 11.10.1833) буенча, Казан шәһәре Николо-Ляпухов чиркәве рухание Александр Немцов тарафыннан чукындырылган (13.10.1833). Аңа Гавриил исеме бирелгән, рус әтисе – Казан комиссариат эшләренең 10 класслы сәркатибе Василий Андреев-Скобельцин, әнисе – 10 класслы орденоносец-гауза аудитор Герасим Семенов-Сухотинның хатыны София Николаева.

Казанда фатирга кертелгән кантончылар – 13 яшьлек **Сабит Бакеев** һәм 11 яшьлек **Гайсә Фәтхулловлар**, Консистория Указы буенча, Крестовоздвижение чиркәве рухание Симеон Смирнов тарафыннан чукындырылырга тиеш булганнар. Рухани вафат булу сәбәпле, бу эш башка кешегә йөкләнгән. Консистория утырышында (25.05.1835) әлеге «эш», башкарылган, дип, архивка тапшырылган.

Казан дары заводындагы 18 яшьлек кантончы **Хәмит Сәгыйтов**, Консистория Указы (№4466, 6.04.1837) буенча, Ягодная бистәсендәге Смоленск-Дмитриев чиркәве рухание Стефан Александров – Троянский тарафыннан чукындырылган (2.05.1837). Аңа Николай исеме бирелгән, рус әтисе – лейб-гвардияле 3 нче гренадер артиллерия бригадасы подпоручигы Николай Васильев-Вепрейский, әнисе – Казан шәһәренең мактаулы гражданины Петр Котеловның хатыны Елена Яковлева.

Пановка авылына җибәрелгән 12 яшьлек **Гайсәметдин Габдерәшитов**, Консистория Указы (№1796, 15.04.1836) буенча, Пановка чиркәве рухание благочинный Стефан Вишневский тарафыннан 1836 елның 14 июнендә чукындырылган. Аңа Тихон исеме бирелгән. Рус әтисе – кенәз Тенишевләрнең йорт хезмәткәре Лев Иванов, әнисе – шул авыл алпавытының крестьяны Федосей Савельевның хатыны Марья Прокофьева. Гайсәметдиннең иштәшләре – яһүд балалары Ильяш Котлофкер (17 яшь), Абрам Шевц (16 яшь), Юдель Левинсон (14 яшь), Шлойма Яловецкий (14 яшь), Аврум Кундель (14 яшь), Ицек Цыприк (13 яшь) – 16 нчы июньдә, Хаскель Гершкович (16 яшь), Богородское приходына караган Көек авылыннан Фроим Шхиляр (13 яшь) 2 майда чукындырылган.

***

Күрәсең, кайбер кантончылар Казан губернасында түгел, ә Санкт-Петербургта чукындырылганнар. Чөнки Консистория Указы буенча чукындырылырга тиешле балалар турында руханилар: «Команда белән Санкт-Петербургка җибәрелү сәбәпле, Указны гамәлгә ашыра алмадым», – дип рапорт язганнар. Мәсәлән, солдат улы – 12 яшьлек **Ишмук (Ишмөхәммәд) Усманов** (№5226, 21.07.1824), Казандагы Владимир казармасында урнаштырылган 17 яшьлек кантончы **Ибраһим Сөләйманов**, Консистория Указы (№1569, 10.03.1825) буенча, Казан Владимир соборы протоиерее Филипп Раев тарафыннан чукындырылырга тиеш булган. Протоиерей Раевның рапортларыннан күренгәнчә, Усманов та, Сөләйманов та командалар белән Санкт-Петербургка озатылганнар. Шулай итеп, алар Россия империясенең башкаласында чукындырылганнар булып чыга.

Кантончылыктан качарга омтылу

Дәүләт солдатның гаиләсенә паек һәм акча бирә башлауга карамастан, газиз балаларны кантончылар мәктәбенә тапшырмас өчен, төрле хәйләләр уйлап тапканнар. Бу эштә чукындыру галәмәте дә барлыгын яхшы белгән, патша армиясендә озак еллар хезмәт итеп каезланган, кан койган татарлар әлеге гамәлдә аеруча актив булган.

Шуларның берсе – ир бала тууны яшерү яки аның яшен киметеп күрсәтү. Чыннан да, төрле еллардагы халык санын алу (ревизия) материалларында ир-атның яше ике графада – әйтү һәм тышкы кыяфәте буенча күрсәтелгән. Мәсәлән, документта бала яңа туган дип язылган, ә тышкы кыяфәте буенча аңа 2-10 яшь дип теркәлгән. Мондый күренеш барлык ир-атка да кагыла. Хатын-кызларның яше бер графада гына күрсәтелгән. Тагын бер кызыклы күренеш: чагыштырып карасаң, ир-атның һәрвакыт хатыныннан 5-10 елга яшьрәк, ә тышкы кыяфәте буенча яшьтәшләр икәнлеге ачыклана.

Кайбер очракта солдаткалар, эче беленә башлагач яки тулгак җитәр алдыннан, башка авылга барып бала тапкан, тудырган газизен асрамага алган бала яки «подкидыш» дип күрсәткән.

Янә бер очрак – ревизия вакытында ир балаларны яшергәннәр. Шуларның бер дәлиле булып, Милли архивта безнең нәселгә кагылышлы квитанция (№ 441498, 1859 ел, 22 апрель) саклана. Ул Сәхабетдин бабамның бабасы Гайсәретдиннең (Габделгайсар) туганнан-туган энесе Моталлапка кагыла. 1858 елгы халык санын алу вакытында Биктимер бабайның беренче баласы – 25 ел хезмәт итеп кайткан отставкадагы солдат Бикмөхәммәднең Моталлап исемле кантончы улы күрсәтелми. Бу хәл ярты елдан соң ачыклана. Моның өчен Моталлап бабайга көмеш акча белән 90 тиен (ул вакытта сыер 3 сум тора) штраф салынган.

Бу урында соңрак Моталлап бабайның энесе Мөрәс бабайның хәрби хезмәткә алынуын, Кырым сугышында катнашып, авылга кайтып, яраларыннан вафат булуын, ә аның улы – мулла Нургаяз бабайның, 1937 елда кулга алынып, 1938 елның 22 августында ТАССР Югары судының Махсус комиссиясе тарафыннан «колхозлаштыруга каршы эшчәнлек, сугыш башлану турында коткы тараткан» (58.10 маддә) өчен 10 елга ирегеннән һәм тагын 5 елга хокукларыннан мәхрүм ителүен, Себергә сөрелүен һәм шунда вафат булуын күрсәтеп китү дә урынлыдыр.


КВИТАНЦІЯ №441498
КАЗНАЧЕЙСТВО
1859 года.
безъ платежа за бумагу
№ Ст.
По Указу ЕГО ИМПЕРАТОРСКАГО ВЕЛИЧЕСТВА дана сія квитанція, въ томъ, что сего числа принято въ ... Казначейство

Кантончылыктан качарга маташкан Моталлап бабайның 90 тиен штраф түләве турындагы квитанция

Икенче бер документ та авылдашларыбызга кагыла. Рапорт (1853 ел, 6 июнь) Чистай өязенең 2 нче стан Приставына юнәлтелгән. Документта: *«25 майда Кыр Шонталасы авылында даими яшәүче, отставкадагы солдат Габделхәким Сәфәров һәм аның законлы хатыны Мария Якубовскаяның Хәрби ведомствога караган ир балалары туды. Аңа Кыр Шонталасы авылының указлы мулласы Бикмөхәммәт Вәлитов Габдулвәли дигән исем бирде»*, – дип хәбәр итәлә.

Кантончылар «әйбер, җисем» булудан туктый

Кантончылар структурасы 1805 елдан 1856 елга кадәр гамәлдә булган. Император Александр IIнең тәхеткә утыру уңаеннан 1856 елның 26 августында чыгарган Манифестында солдат балаларының Хәрби ведомстводан бәйсезлеге игълан ителә. Шулай итеп, бу балалар «әйбер, җисем» булудан туктый. ТР Милли архивында Чистай өязенең Кыр Шонталасы авылы кантончыларын Хәрби ведомстводан чыгару турындагы документ саклана. Менә ул бәхетле балаларның исемлеге:

Әбдерәшит Габдрахмановның законсыз туган улы Сәхретдин (9,5 яшь). Хәрби ведомствога 1851 елда беркетелгән; әнисе – Монасыпова Бәдигөлҗамал (40 яшь), сеңлесе – Мәрхүбҗамал (7 яшь).

Отставкадагы солдат (боцманат – диңгез флоты унтер-офицеры) Каюм Хәмитовның уллары (1825 елда беркетелгәннәр): Камалетдин (8 яшь), Җәләлетдин (4 яшь); әниләре – Вафия Насыйрова (30 яшь), сеңелләре – Бибимаһруй (6 ай).

Вафат булган отставкадагы солдат Бикмөхәммәд Биктимеровның улы Моталлап (16 яшь) 1851 елда беркетелгән; әнисе – Гафифә Хәлилова (35 яшь).

Вафат булган отставкадагы солдат Габделхәким Сәфәровның улы Габдулвәли (5 яшь) 1855 елда беркетелгән.

Документка волость старшинасы Исмәгыйль Тимербулатов, олыс башлыгы Егор Федоров, Кыр Шонталасы авылы писаре Назыйр Бикбовлар кул куйган.

Александр II Манифестыннан соң, Кантончылар мәктәпләре дә әкрен генә бетерелә. 1858 елдан алар – башлангыч хәрби мәктәпләргә, ә 1868 елдан исә хәрби гимназияләргә әверелә. Аларда писарьлар, музыкантлар, җырчылар әзерләнә башлый. Бу уку оешмаларына инде укучылар үзләренең яки ата-аналарының теләкләре белән кабул ителгән, хәрби хезмәткә дә өстенлек бирелмәгән. Алда искә алыначак егетләр, күрәсең, шушы мәктәпне тәмамлаганнардыр. Алар – 21 нче Муром полкы музыканты **Морадым Мөэминев** (Кыр Шонталасына 1874 елның 2 августында кайта); 8 нче Эстляндия полкы барабанчысы **Шәйхетдин Мөхетдинов** (авылга 1883 елның 6 сентябрендә кайта); 1891 елда кабат Кызылъяр олысы хөкемдары итеп сайланган унтер-офицер, соңрак Казан шәһәренең 2 нче частендагы полиция унтер-офицеры **Ситдыйк Нәзиров**, 2 нче артиллерия бригадасы артиллеристы **Шәрәфетдин Мөксинов** (1867-1883 нче елларда хезмәт итә). Аңлашылганча, болар барысы да бер авыл – Кыр Шонталасы егетләре.

***

Кантончылар Россия империясе катнашында узган күпсанлы сугышларда кан коя, дәүләт бәйсезлеген саклый. Алар чукынырга, ә бер ишләре үз кавемен, туган телен онытырга мәҗбүр ителгән. Ә кайберләре, кантончылыкка катышмас өчен, төрле хәйлә корырга омтылган. Шулай итеп, алар мөселманлыкны – ислам динен, ә иң мөһиме – газиз балаларын афәт-җәфалардан саклап калырга тырышкан. Бу балаларның язмышын өйрәнү дәвам итә. Киләчәктә тагын да кызыклырак фактлар ачылыр дип өметләнеп калыйк. ■

Безнең мирас №8 август 2020

Беренче татар фотографы

Лена Тябина



Кыйвам Зөлфокаровның уллары Салих һәм Хәсән. Казан, 1910 нчы еллар

Габдулла Тукай әдәби музеена килүчеләргә, шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗатыннан кала, Ф.Әмирхан, Г.Камал, С.Сүнчәләй, С.Рәмиев, Г.Коләхмәтов, К.Мотыйгый, М.Бигиев, Г.Кариев, Ә.Хәсәни һәм З.Хәсәниләр турында да саллы мәгълүмат бирелә. Әдип Зариф Бәшири, нәширләр Иван Харитонов һәм Гыйльметдин Шәрәф, цензор, галим, тәрҗемәче Николай Ашмарин турында сөйли торган экспонатлар аз булса да, аларның Тукай иҗаты һәм тормышындагы роле, гомер юллары турында экскурсоводлар тирән мәгълүмат бирә ала. Шундый шәхесләрнең тагын берсе – каллиграф, педагог һәм фотограф **Кыйвам карый (Кыйваметдин) Камаледдин улы Зөлфокаров** (1870-1921).

Безнең көннәрдә Кыйвамкарый Зөлфокаров исеме халыкка кайтарылды. Филология фәннәре докторы, профессор Марсель Әхмәтҗанов бу юнәлештә зур эш башкарды. Ул – К.Зөлфокаров тормышын һәм эшчәнлеген тирәнтен өйрәнүчеләрнең беренчесе. М. Әхмәтҗанов аны татарлар арасында беренче фотограф буларак билгеләп үтә: *«К.Зөлфокаровның, фотограф буларак, революциягә кадәр танылган булуын белүчеләр әлегә бармы икән? Аның балаларында ул төшергән негатив пластинкалар әле дә саклана. Бу – кешенең безнең культура өчен иң игелекле хезмәте. Тукай үлгәннән соң, Казан арты авылларына чыгып, бөек шагыйрь шәхесе белән бәйле истәлекле урыннарны рәсемгә төшереп алуы булган. Шуның хезмәте аша инде менә ничә еллар татар укучылары Кушлавычның, Өчиленең һәм Кырлайның Тукай дәверендәге күренешләрен күз алдына китерәләр».*

Арча районының
Кушлавыч авылы күренеше

К.Зөлфокаровның тормышы һәм эшчәнлеге турындагы мәгълүматлар И.Рәми, Р.Даутов, Р.Абзалина, Н.Исмәгыйлев, Н.Гәрәева, Р.Шәмсутов, Л.Латыйпова хезмәтләрендә дә бирелә.

XX гасыр башы гарәп-татар каллиграфиясенең күренекле остасы Кыйвамкарый Зөлфокаровка багышланган беренче басмага тукталмый мөмкин түгел. Рус телендә 2011 елда «Издательство Еникеевой» нәшриятында басылган «К.Зульфакари. Тюркская касыда «Мавлид ан-Наби» китабында К.Зөлфокаров һәм аның мирасы хакында сүз башы, «Мәүлүдән-Нәби» китабының рус теленә тәрҗемәсе, 1912 елда аның тарафыннан әзерләнеп һәм каллиграфик бизәлеп басылган җыентыкның факсимиле басмасы, искәрмәләр урын алган. Шулай ук аның кушымтасында К.Зөлфокаровның фотопортреты, гаиләсе белән төшкән фотосурәтләре, Г.Тукай белән бәйле урыннарның фотосурәтләре, аның китаплары, дәреслекләре һәм матур язу дәфтәрләренең тышлыклары да бирелгән. Китап К.Зөлфокаровның оныкчыгы Рөстәм Латыйповның матди ярдәме белән әзерләнгән.

Г.Тукайның бу шәхескә таныш булу-булмавы, аларның очрашуы турында чыганаклар юк. Ләкин шагыйрьнең әсәрләрендә К.Зөлфокаров исеме берничә тапкыр искә алына. Шулай ук Г.Тукайның «Мәҗмугаи әсәрләр»е басылу тарихын өйрәнгәндә дә әлеге шәхес белән бәйле мәгълүматларга тап булабыз.

Г.Тукай К.Зөлфокаровның эшчәнлеге турында Казанга килгәнче үк хәбәрдар була. Җаек шәһәрендә чыга торган «Фикер» газетасының 1906 елгы 3 һәм 21 июль (24, 27) саннарында шагыйрьнең «Алай-болай» дип аталган фельетоны басыла. Мәкаләнең 24 нче сандагы дәвамында «Бик усал» дигән имза-псевдоним куелган, 27 нчедәгесе имзасыз бирелгән. Тукай, матбугат дөньясында барган бәхәсләрне сурәтләү аша, шул чорның күп кенә проблемаларын ача: дин әһелләренең чын йөзе, хөр фикерле һәм реакцион карашлы татар газеталарының бер-берсенә каршы торуы, дин, шәригать һәм милләт турындагы уй-фикерләрнең вакытлы матбугатта чагылышы… Фельетонда нәшир һәм мөхәррир Әхмәтҗан Сәйдәшев, Беренче Дәүләт Думасы депутаты Сабир Хәсәнов, әдип Садыйк Иманколый кебек конкрет шәхесләр искә алына. Тукай, исемен атамаса да, Кыйвамкарый Зөлфокаров турында да үз фикерен әйтеп үтә: «Эш «дәһри вә динсез» дип кычкырышырга калса, без Садыйк мулла әл-Иманколыйны сүтәбез дә, урынына Кязиб мулла әл-Имансызыйны утыртабыз да куябыз; бу бигайниһи «Лап-лап-лап»тагы Золмәтетдин әл-Ноксаный шикелле була да кала». Биредә берничә искәрмә биреп үтү урынлы булыр. «Лап-

лап-лап» – «Бәянел-хак» газетасы. Золмәтетдин – диннең явызлыгы. Әл-Ноксаный – кимчелекле. «Золмәтетдин әл-Ноксаный» дип язганда Тукай Кыйвам карый Зөлфокаровны «чеметкән». Фельетон тәүге тапкыр беренче дүрт томлыкның 3 нче томына кертелгән. Бу басмада Кыйвам карый Зөлфокаров турында бернинди дә искәрмә юк. Бары тик 1985-1986 елгы биш томлыкта гына Тукайның нәкъ К.Зөлфокаровны күздә тотуы турында мәгълүмат бирелә.

«Зөлфокаров Казанның 17 нче мәхәллә мәчетендә мәзин булып торган, «Коръән»не төрле мәкамнәр белән укый белгән. Замандашлары аның кубызда һәм курайда яхшы уйнавын, берничә тапкыр хаҗга баруын искә ала.

Дүрт елдан соң, Казанга килгәч, Г.Тукай тагын бер әсәрендә К.Зөлфокаров образына мөрәҗәгать итә. Бу – шагыйрь тарафыннан 1910 елда язылган «Керешү хотбәсе» исемле фельетон-пародия. Ул «Ялт-йолт» журналының 1910 елгы 5 нче санында (15 май) «Яңа хотбә» исеме астында «Имам хатиб» имзасы белән басылган. «Ахыры бар» дип куелган булса да, мәкаләнең ахыры барлыгы билгеле түгел. Бу памфлет мәчетләрдә укыла торган хотбәләргә (вәгазь) пародия рәвешендә язылган. «Яшен ташлары»нда (1 кисәк), кайбер үзгәртүләр кертеп, «Керешү хотбәсе» исеме белән урнаштырылган. Шулай ук «Яңалиф» басмасының 3 нче томына (1931) да кертелгән.

К.Зөлфокаров гаиләсе белән. Сулдан уңга: хатыны Фәизә, кызы Мәймүнә, үги кызы Мәрьям, улы Хәсән, Кыйвам карый үзе һәм улы Салих. Казан, 1910 нчы еллар

«Керешү хотбәсе» («Керешү сүзе») эчтәлеге, юнәлеше һәм әдәби алымнары белән «Алай-болай» фельетонына аваздаш. Икесендә дә Тукай сатирасы утына 20 нче йөз башындагы татар мохите алына. Шул ук шәхесләр, шул ук проблемалар. «Керешү хотбәсе»ен: «Кешене таш һәм туфрактан яраткан, аны баш, борын һәм колак белән зиннәтләгән затка мактау», – дип башлый шагыйрь. Алга таба ул шайтан башкарган гамәлләргә күчә, аларны атап үтә, аңа ләгънәт укый. Шайтанның күпсанлы гамәлләре арасында тагын берсен атый: *«Гавам Зөлтатари дигән маймылга төрле мәкамнәр (Коръән укый торган көйләр) өйрәтте»*. Г.Тукай фельетонда «Ялт-йолт»ның 1910 елның 15 апрель санында басылган игъланнан файдаланган, күрәсең. Игъланның тексты мондый: *«Фәкать 15 ел эчендә*

К.Зөлфокаров ясаган шәмаил

яшь татар балаларын мәүлүд укырга һәм үземчә маймылланырга өйрәтеп йиткерәм. Баласын укыткан кешеләргә бер шешә маэ зәмзәмел шәриф тә буш биреләдер. Әл-кари Гаваметдин Зөлкафари». 1956 елгы дүрт томлыкта *«Мәймүнәл-гавамәз-зөлтатария – Казандагы Кыйвам Зөлфокари исемле надан бер кари, Коръәнне төрле көйләргә салып укыган кеше. Надан булганга күрә, Тукай аның исемен «гами, надан» мәгънәсендә йөри торган «гавам» сүзе белән алыштырган, башкаларга ияреп (маймулланып), төрле көйләр көйләгәнгә күрә, «мәймүн» дип атаган»,* – дигән искәрмә бирелә. 1985-1986 елгы биш томлыкта да шул мәгълүмат кабатлана.

«Алай-болай» фельетоны һәм «Керешү хотбәсе» памфлеты 2015 елгы академик басмага да кертелгән. Кыйвам карый Зөлфокаров турында «Керешү хотбәсе» белән бәйле рәвештә менә мондый искәрмә бирелә: «Казанда яшәгән, Коръәнне яттан төрле мәкам белән укыган, педагог, хаттат».

Тукай берничә тапкыр сатира утына алган, «Коръән» укуыннан көлеп, иронияле сүзләр кыстырып, мәкаләләрендә «Золмәтетдин әл-Ноксаный» «Зөлтатари» дип атаган Кыйвам карый Зөлфокаров кем булган соң?

Бу шәхес турында соңгы елларда басылган төрле чыганаклардан менә ниләр беләбез. Кыйвам Камаледдин улы Зөлфокаров – каллиграф, педагог, дин эшлеклесе, дәреслекләр авторы, һәвәскәр фотограф. 1870 елда Төгәлбай авылында (хәзерге Әлки районы) туган, Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем алган. Төрле һөнәрләр белүе, музыкага һәвәслеге белән аерылып торган. Аның каләме белән ташбасма китапларның текстлары язылып бастырыла. К.Зөлфәкаров заманында каллиграф-рәссам буларак та танылa. Ул – каллиграфик рәвештә язылган һәм бизәлгән «Үтәк шәҗәрәсе», «Мәүлүд китабы», «Әмали гакыйдәсе», «Хөсни хат» китапларының һәм шәмаилләрнең авторы.

Матур язу дәфтәре. Авторы – К.Зөлфокаров

Кыйвамкарый Зөлфокаровның басмалары арасында иң кызыклысы – хаттат үзе әзерләгән, 1912 елда Казанда В.В.Вараксин типографиясендә Хөсәенов варислары тарафыннан бастырылган «Касыйдәи мәүледен-Нәби салаллаһу галәйһи вәсәллам» китабы. Үз вакытында популяр булган китапның төзүчесе дә, бизәүчесе дә – К.Зөлфокаров. 2013 елда дөнья күргән «Татар китабы. Татарская книга» каталог-альбомына Зөлфокаровның «Мәүлүд ән-Нәби» китабы да кертелгән. XX гасырның беренче чирегендә бу китап казан татарлары арасында популяр була. Безнең көннәрдә дә Мәүлед бәйрәмендә текстлар шушы җыентыктан укыла.

К.Зөлфокаров Казанның 17 нче мәхәллә мәчетендә мәзин булып торган, «Коръән»не төрле мәкамнәр белән укый белгән. Замандашлары аның кубызда һәм курайда яхшы уйнавын, берничә тапкыр хаҗга баруын искә ала. XIX гасырның соңгы чирегендә, «Касыймия» мәдрәсәсендә эшләү чорында, Зөлфокаров Галимҗан Баруди йогынтысында була, үз заманының иң алдынгы һәм актив кешеләре белән аралаша. Татарлар арасында беренче фотографлардан булуы аның яңалыкка тартылуы турында сөйли.

Зөлфокаров төшергән берничә фотосурәт Габдулла Тукайга бәйле. Шагыйрьнең үлеменнән соң, ул, өлкән улы Салих белән, Кушлавыч, Кырлай һәм Өчилегә барып, Тукайның балачагы белән бәйле урыннарны фотога төшерә. Әлеге фотосурәтләр 1914 елда басылган «Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре»ндә дөнья күрә. Китапта барысы 9 фотосурәт бирелгән. Өчесе – Г.Тукайның 1908, 1911 (Әстерхан) һәм 1913 (Клячкин хастаханәсе) елларда төрле фотографлар тарафыннан алынган фотосурәтләре. Алтысы – Зөлфокаров төшергән фотосурәтләр. Аларда – Г.Тукай туган Кушлавыч авылы; Кушлавычта Г.Тукай туган йорт; Кырлай авылындагы Фәтхерахман хәзрәт йорты (биредә Г.Тукай абыстайдан дәресләр ала); Өчиле авылындагы Зиннәтулла хәзрәт йорты (Г.Тукайның әнисе Бибимәмдүдә һәм, әнисе үлгәч, бәләкәй Габдулла да бу йортта торган; 1912 елда Өчилегә кайткач та, Тукай биредә булган); Кырлай авылында Г.Тукай укыган ир балалар мәктәбенең ике фотосурәте (берсендә мәктәп Кырлай мәчете фонында төшерелгән).

Зиннәтулла хәзрәт йорты фоторәсемендә алгы планда өч кеше: Г.Тукайның әнисенең энесе (Тукайның абзасы) – Кәшфелкәбир Әмиров, аның кызы Нурания һәм фотографның улы Салих төшкән. К.Зөлфокаровның улы Салих (1900-1981), озын гомер кичереп, Шевченко шәһәрендә вафат була.

Кушлавычта Г.Тукай туган йорт фотосурәтендә дә шагыйрьнең замандашын күрәбез. 1913 елда, фотога төшерер өчен, бу йортның шул вакыттагы хуҗасын, махсус киендереп, кулына көрәк тоттырып йорт каршына бастыралар. Тукай туган йорт бушап калгач, анда Тукаевларга якын туган тиешле 11 балалы ишле гаилә кереп урнашкан икән. Фотосурәт тарихы турында ул гаиләнең нәсел дәвамчысы Ләлә Яруллина «Түгәрәк уен» журналында «Нәсел башыбыз – Кушлавычта» дигән хатирәләре белән уртаклаша.

К.Зөлфокаров төшергән әлеге фотосурәтләрнең күчермәләре Г.Тукай әдәби музеендагы экспозицияләрдә һәм шагыйрьнең тормыш юлын яктырткан электрон җайланмаларда урын алды. Алар бөек шагыйрьгә бәйле күп басмаларга, шул исәптән юбилей альбомнарына да кертелгән.

К.Зөлфокаров мирасын ТР Милли музее һәм ТР Милли китапханәсе фондларында да очратырга мөмкин. Милли музейда К.Зөлфокаров эшләгән шәмаилләрнең берсе саклана. Ул «Коръәннең шифа аятьләре» дип атала. Шәмаилдә алты аять язылган. Милли китапханә фондында исә К.Зөлфокаровның алда искә алынган «Касыйдәи мәүледен-Нәби салаллаһу галәйһи вәсәллам» китабы урын алган. ■

Әдәбият

Әхмәтҗанов М. Археографик экспедицияләр һәм Габдулла Тукай хатирәләрдә. – Казан: Множительный центр Института истории АН РТ, 2015. – 131 б.

Зульфакари Кывам-карый. Тюркская касыда «Мавлид ан-Наби» / составитель Р.И.Еникеева. – Казань: Издательство Еникеевой, 2011. – 168 с.

Татар китабы. Татарская книга: альбом / төз.-авт.: Р.Ф.Мәрданов, И.Г.Һадиев. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2013. – 504 б.

Яруллина Л. Нәсел башыбыз – Кушлавычта // Түгәрәк уен. – 2015 – №3 – 32-33 б.

Зиннәтулла Әмиров йорты. Арча районының Өчиле авылы

Безнең мирас №8 август 2020

Күренекле шәхесләребез

Багбостан

Татарның туташ-ханым-аналар язмышлары –
Сүз һәм күз яшьләре җитмәс сагышлары....

Мирсәй Гариф

Багбостан исемен заман сүзлекләреннән эзләмәгез, чөнки иң югары даирәләрдән якташыбызга җибәрелгән исем-ат – фарсы теленнән алынган, ягъни «җимеш», яисә «яшелчә бакчасы» мәгънәсендә. Исеме җисеменә туры килә, дигәндәй, аның тормыш тарихына кереп китсәң, зур һәм затлы бакчаларда йөреп, адашып чыкмастай хәлгә төшәрлек. Багбостан Мөэминованың гомер бакчасында татлы һәм ачы җимешләр бик күп булган. Чорына карап, әлбәттә, ачыраклары шактый, чөнки яшәгән елларының күп өлеше тоталитар режим вакытына туры килә.

Мәндәйдән Оренбургка

Вилдан белән Гафифә Минзәлә өязенең Мәндәй авылында гаилә корып, балалар үстереп, тырыш хезмәт куеп, гади генә крестьян тормышыннан тәм табып яшәгәндә, әтиләре чирләп дөньядан китә. Биш кыз бала әниләре карамагында кала. 1884 елда туган төпчеге Багбостанга өч кенә яшь була. Ничек тормыш көтәргә?.. Кыз балага хәтта җир өлеше дә бирми патша хөкүмәте. Авылда таянырлык кешеләре дә юк. Гафифә әнкәйләре, бөтен батырлыгын җыеп, балаларын ияртеп, губерна башкаласы Оренбургка китәргә була. Анда ерак кардәшләре дә, баргач та торып китәрлек кәрвансарайлары да бар икән, дип сөйлиләр сәүдәгәрләр. Өйдәге барлык кирәк-яракларны, чүпрәк-чапракларны бәләкәй арбага салалар да юлга кузгалалар. Әниләре һәм зуррак кызлары «уфалла арбасы»н тарта, ә әйберләр өстендә өч яшьлек Багбостан утыра. Аңа дөнья күреп баруы кызык, ә әнисе шәйли: көненә кырык чакрым узсалар, ун көндә башкалага барып җитәчәкләр. Их, алты кешенең тамагын туйдырасы да бар бит... Авылдан алган ризыклар бер-ике көндә бетә. Тамак хакына

авылларда йә бәрәңге чүбе утыйлар, олыраклар печән чаба, кыскасы нинди эш туры килсә – шуны башкаралар.

Ниһаять, бер ай дигәндә, Оренбургка барып җитәләр. Монда да колач җәеп көтмәгәннәр икән аларны. Әниләре кул астына керерлек тырыш кызларын асраулыкка бирергә мәҗбүр була, ә төпчеге Багбостанны үзе тәрбияли. Гафифә, кайда эш бар – шунда бара. Тора-бара фатир табып, үз почмагын булдыра. Аның хыялы – балаларын белемле итү, бигрәк тә төпчеге укырга хирыс. Әнисе аны гарәпчә язарга өйрәтә. Асраудагы кызларын да гыйлем өстәргә өнди, ә Багбостанны Фатыйма Әдһәмованың яңа ысул белән укыта торган башлангыч кызлар мәктәбенә урнаштыра. Кызы, бик тырышып, гыйлем үзләштерә, ә әнисе балаларына әхлакый тәрбия бирү белән шөгыльләнә. Шулай айлар-еллар үтә тора, уку тәмамлану чорында мөслимә шәкерт Багбостан, башлангыч сыйныф балаларына дәресләр биреп, мөгаллимәлек сәләтен күрсәтә. Унөч яшьлек кыз балага белемен тагын да камилләштерү мөмкинлеге туа: Оренбургта, химаяче Рәмиевләр ярдәмендә, яңа мәктәп оештырыла.

1897 елда ачылган әлеге мәктәп губернада кызлар укый торган беренче җәдидчә урта белем учагы була. Монда Бакчасарайда, Истанбулда, Каһирәдә укып кайткан бик тә гыйлемле мөгаллимнәр укыта. Алар, тора-бара, иске гарәпчәдән һәм төрекчәдән татарча язуга күчәләр. Багбостан бик зирәк була, зур тырышлык белән бу мәктәптәге дөньяви фәннәрне дә үзләштерә. Ул тарих, җагърафия, фәлсәфә, сәясәт, сәнгать дәресләрен бигрәк тә ярата, математика, физика, химияне дә читтә калдырмый.

Мөгаллимә юлы

Гомумән, Багбостан җәдид мәктәбендә укуыннан канәгать. Әле бит шәһәрдә югары уку йортлары исәбендә йөрүче «Хөсәения» мәдрәсәсе дә бар. Анда да татар зыялыларының чыгышларын тыңлаштыра: башкаладан мәшһүр Рәмиевләр һәм Хөсәеновлар, Җаектан (Уральскидан) Яушев, гыйлем иясе Зәйнулла ишан Рәсүлев, Стәрлетамактан Мөхәммәтсәлим Өметбаев кебек шәхесләр килә. Гомумән, ул вакытта Оренбург каласы мөселманнарның бер илаһияти, мәгърифәти һәм мәдәни үзәгенә әверелә. Шундый шартларда укуын тәмамлаган Багбостан мәгърифәтчелек юлын сайлый. Ул 1905 елда, тормыш иптәше Гобәйдулла Рәдүди белән, үз өйләрендә кызлар мәктәбе оештыра. (Ире, «Хөсәения» мәдрәсәсенең гали сыйныфларын тәмамлап, бишенче мәхәлләдәге Заһидулла мәктәбендә мөгаллимлек итә. Талантлы шагыйрь әле дәреслекләр дә әзерли.)

1906 елда Оренбургка Уфадагы Диния нәзарәтендә казый булган, күпне күргән, күпне белгән Ризаэддин Фәхреддин килә. Ул, Шакир һәм Закир Рәмиевләр тәкъдиме белән, «Вакыт» газетасына мөхәррирлек итә башлый. Буш вакыт табып, «Хөсәения» мәдрәсәсендә дә укыта, кызлар мәктәбенә дә чакыралар. Риза казый бер очрашунда, гаять мәгълүматлы һәм укымышлы, горур һәм чая Багбостанга сүз катып:

– Бик тә гыйлемле һәм тәрбияле мөгаллимә, диләр үзеңне. Кәгазьләреңдә Минзәлә өязенең Мәндәй авылында, Мәллә елгасы буенда туып үскән, дип язылган кеби. Минем дә гомеремнең бер өлеше Мәллә елгасы буенда узды, – ди.

– Рәхмәт, Риза казый, без бит Сезнең «Тәрбияле бала» һәм «Тәрбияле ана» китапларын укып үстек, шуңадыр инде... Ә Сезнең Илбәк авылыннан Уфага казыйлыкка сайланганыгызны укыганым бар. Без мәктәптә ике дистәдән артык китапларыгызны һәм гәҗитләрдәге бихисап язмаларыгызны кулланабыз, шөкерана!

– Ә Илбәктә без, кыз балалар укытырга да ниятләп, мәдрәсә ачкан идек. Сез анда башлап укымадыгызмы?

– Юк, хәзрәт, миңа өч яшь чакта, әти үлгәч, әнкәй безне, укыту нияте белән, монда алып килде. Шуңа мин Сезнең Оренбургта һәм Казанда басылган китапларыгыз белән таныш. Ә Илбәкне һәм Мәндәйне әниемнең сөйләве буенча гына беләм. Әле харитәдән карадым, аралары бары 13 чакрым гына икән.

– Чыннан да, бик тә мәгълүматлы якташым икәнсез. Эшләрегез дә изге. Безгә «Вакыт» гәҗитенә дә язгалып торыгыз. Очрашу форсатыннан, Сезгә – шәхсән өченче ел чыккан, кызым Зәйнәп өчен язган «Мәшһүр хатыннар» китабым. Үзегезгә дә алар рәтенә керергә насыйп булсын. Менә, мәктәбегезгә былтыр чыккан җиде китабымны рәхим итеп алыгыз.

– Олуг рәхмәтебез Сезгә, Риза остазыбыз! Язылган китапларыгыз киләчәктә дә Аллаһ кодрәте белән басылып торсын.

– Багбостан ханым, бу сүзләребез белән үткәннәрне искә төшердек әле: Илбәктә язылган бер «Интизар» *(«Зарыгу». – **М.Г.**)* китабымны гына цензура үткәрмәде. Шундый хатирәләр...

Багбостанга исә Риза казый белән очрашу дәрт-дәрман өсти һәм ул ире белән мәктәпләрен рәсмиләштерергә ниятли. Оренбургта бер дистә мәктәп-мәдрәсә бар. Шуларның икесе генә кызлар өчен. Беренчесе – Ф.Әдһәмованыкы, ул инде эшли, ә икенчесе Багбостанныкы булачак, Аллаһ бирсә.

Ниһаять, алар 1907-1908 уку елында хөкүмәттән бу урта мәктәпне ачарга рөхсәт алалар һәм аның өчен ике катлы йорттан бүлмәләр дә бирәләр (Трофимов тыкрыгы, 9). Мөэминованы мөдирә һәм мөгаллимә итеп куялар. 1908 елны хәләле Г.Рәдүдинең «Табигатькә сәяхәт яки Тарихы табигыйә» дәреслеге дөнья күрә.

Багбостан бар белемен яшь буынга бирә, чөнки татар кызлары укырга омтыла. Ире Гобәйдулла аңа дәфтәрләр тикшерергә ярдәм итә. Ул арада, кулына яңадан каләм алып, икенче китабын яза: «Тәсһиле җагърафия» *(тәсһиле – уңайлаштырылган. – **М.Г.**)* дәреслеге. Анысы 1911 елда басыла. Аларның изге эшкә чумып, балаларга белем биреп, бәхетле тормышта яшәгән чорлары була бу.

Танылган мөгаллимнәрдән буларак, Санкт-Петербургта мөселман балаларын укыткан Шәриф Камалны хезмәттәшлеккә җәлеп итә. Тәҗрибәләрен уртаклашып, Риза казый җитәкләгән «Вакыт» гәҗитендә һәм «Шура» журналында мәкаләләр бастыралар.

Ләкин дөньяда шатлык белән кайгы янәшә йөри шул. Ш.Сәгыйди язганча: «Гобәйдулланы укыту юлында ялгыз иткән чын хезмәтләре күкрәк авыруына китерде. Авызыннан каннар акты, һаман дәрес бирде. Берничә еллардан бирле җәфалаган күкрәк хәстәлегеннән сәламәтләнә алмаенча, 1912 елның 28 ноябрендә дөнья белән аерылышты». Г.Рәдүдигә бу вакытта нибары 27 яшь кенә була. Туберкулез татарның асыл улларын шулай кыерлап бара, дүрт ай ярымнан Габдулла Тукайны да мәңгелеккә алып китә бу аяусыз чир.

Оренбург җәмәгатьчелеге, Гобәйдулла Рәдүдине югалтуны авыр кичереп, аның хәләле Багбостанның кайгысын уртаклашып, матбугатта язып чыга. Әй, ул сүзләр, ничек кенә әйтелсәләр дә, ачы кайгыны баса алалармыни... Их, күңелне юатырга, нәселне дәвам итәргә уллары да юк, ичмасам! *(Ике нарасыйлары сабый чакта ук вафат була, соңрак Багбостан асрауга ике кыз бала ала. – **М.Г.**)*. Ә Багбостанга яшәргә, бергә башлаган кызлар мәктәбенең эшен ничек кенә булса да дәвам итәргә кирәк. Һәм, күз яшьләрен киптереп, балалар янына мәктәпкә килә.

Багбостан ханым мәктәбендә укучы кызлар

Истанбулда

Бөтен сәләтен биреп, халәтен багышлап, мөселман хатын-кызларын укыту белән шөгыльләнә Багбостан. Шәһәрдә кызларга тегү-чигү түгәрәкләре дә оештыра. Үзлегеннән һаман белемен камилләштереп, 1913 елда югары дәрәҗәдәге мөгаллимәлек хокукы ала. Татар дөньясында мәгърифәтче буларак таныла башлый.

Мәктәптә белем бирү белән генә чикләнми, булачак мөгаллимәләр әзерләүгә дә керешә Багбостан. Ә бу юнәлеш мөдирәгә тәҗрибә үзләштерү кирәклеген күрсәтә. 1914 елда ул, кызлар укыту тәҗрибәсен уртаклашу нияте белән, Төркиягә бара. Монда укымышлы татарларның элек-электән кадерен беләләр. Илбашы Әнвәр паша Багбостан Мөэминованы башта министрлар белән очраштыра. Аннан соң Багбостан Төркия парламентында төрек телендә чыгыш ясый. Элек хатын-кызларны исәпкә алмаган җыелышны үҗәт мөгаллимә үзенең доклады белән хәйран калдыра. Аның чыгышы төрекчә «Фикер» гәҗитендә басыла.

Туксан биш ел узгач, бу юлны үземә дә узарга насыйп булды. Тарихи темага язучы буларак, Бөек милләт Мәҗлесендә чыгыш ясап, Истанбул университетында лекция укыдым. Мәдәният министры кабул иткәч, гомумән, төрекләрнең татарларга карата җылы, ихтирамлы мөнәсәбәтен тойгач, Гаяз Исхакый, Садри Максуди һәм замандашларыбыз – Надир Дәүләт, Раушания Алтай, Чулпан Четин-Закированың нигә Төркиядә хезмәт куйганлыкларына төшендем.

Багбостанны Истанбулда эшләп килүче кызлар мәктәбе кызыксындыра, монда хәтта татар бүлеге дә бар, чөнки башкалада милләттәшләрнең саны шактый. Шулар арасыннан Чистай кызы – Тукайның мәхәббәте Зәйтүнә Мәүлүдова белән танышып, дуслашып китәләр. Зәйтүнә, Тукай вафат булгач, Зәйнулла ишан улы Кадыйр Рәсүловка кияүгә чыгып, хаҗ сәфәреннән кайтканда, Истанбулда тоткарланып кала. Беренче Бөтендөнья сугышы башлангач, Төркия белән Россия икесе ике хәрби блокта кала. Багбостан да шул чакка туры килеп, шактый вакытын Төркиядә үткәрергә мәҗбүр була. Зәйтүнә белән бергә дәрелмөгаллиматкә *(кызлар югары мәктәбенә)* кереп укырга хыяллланалар. Истанбулдагы алдынгы мәктәпләрдә булып, андагы уку программаларын, дәрес ысулларын өйрәнүдә Йосыф Акчура да теләктәшлек күрсәтә. Ә төп ярдәмчеләре – татар кызы Фәридә Тек була. Бу бик гыйлемле ханым биредәге татар хәрәкәтен җитәкли. Алар Габдрахман паша йортында торалар, янәшәдә, Истанбул уртасында, бакчалары бар.

Багбостан белән Зәйтүнә еш кына, серләшеп-сөйләшеп, шәһәргә чыгып йөриләр. Уртак сүзләре – һаман да йөрәк түрендәге сөйгәннәре Тукай белән Рәдуди.

– Фәридә «Тәфтиләү»не уйнап-җырлап җибәрсә, җанымны кая куярга белмим, – ди Зәйтүнә.

Аңа Багбостан да кушыла:

– И, якташым, ул җырны ишетсәм, минем дә күзләрем яшь белән тула…

Дөньяда кайдадыр сугыш барса да, монда тынлык. Күңелләрдә генәниндидер курку-шом: туган илләренә ничек кайтып җитәрләр?!. Зәйтүнә, балага узу сәбәпле, биредә озаккарак тоткарлана. Ул 1915 елның 16 сентябрендә Атилла Расихны (булачак язучы) дөньяга китерә, ә Багбостан алданрак кайтып китә.

Бүгенге көнгә әйләнеп кайтып, искәртеп үтим. 2009 елда Истанбулда иҗади сәфәрдә булып, Зәйтүнә һәм Багбостан белемен камилләштергән Фәридә Тек мәктәбен үземә дә эзләп табарга насыйп булды. Хәзер анда музей һәм фәнни үзәк. Ниһаять, шунда Фәридә Тек фотосурәтен дә төшереп алдым.

1915 елда Оренбургка кайту белән, Багбостан Мөэминова «Сөембикә» журналының ике санында (23 һәм 24) җиде бит күләмендәге «Сәяхәт хатирәләре»н бастыра. Аңа кадәр журналда (2 һәм 4 нче саннар) мөгаллимәнең беренче хезмәте – «Гаилә хәлләре» дөнья күргән була.

«Дөньяда кайдадыр сугыш барса да, монда тынлык. Күңелләрдә генә ниндидер курку-шом: туган илләренә ничек кайтып җитәрләр?!.

Төркиягә сәфәре Багбостан тормышында кыенлыклар да тудыра. Шуңа да карамастан, ул бөтен барлыгы белән мәкаләләр язу, тәҗрибәсен анализлау эшенә чума. Шул арада 1916 елда Саракташ районының Кабан авылында мөгаллимәләр курсын ачып, аның мөдире һәм укытучысы булып та ала. Әлеге курсларга 250 тирәсе тыңлаучы җыелган: Урта Азиядән, Кырымнан, Себердән, хәтта Кытай һәм Манчжуриядән дә килгәннәр. Ул чорда белемгә омтылыш гаять көчле булган.

Багбостан мәктәбенең хәле турында җәмәгатьчелек матбугатта үзенең туры сүзен әйтеп килә. Аерым алганда, «Сөембикә» журналында кызлар мәктәбенә уңай бәя биргән язма чыга. Мөэминованың мәкаләләре дә 1916 елда даими басылып килә: «Ир белән хатынның гаиләдә мөштәрәк *(уртак. – **М.Г.**)* вазыйфалары» (№10, 11), «Вазыйфалар» (№12), «Баланы тәрбияле итү» (№15, 16).

Ниһаять, 1917 елда Вилаять (өлкә) мөселман эшләре комиссариаты, Багбостанның эшләренә бәя биреп, «Ун еллык гыйльми хезмәт» китабында мәктәптән «ун ел эчендә 149 мөгаллимә чыккан», дип яза. Большевиклар шул елдан башлап әлеге уку йортын «Русско-татарская школа имени Ильича» дип атасалар да, халык аны, элеккечә, «Багбостания мәктәбе» дип йөртә һәм ул тарихка да шул исем белән кереп кала.

1918 елда Төркиядә хәрби түнтәреш. Әнвәр паша, илдән качып китеп, басмачыларга кушыла һәм 1922 елда кызылармиячеләр белән бәрелештә һәлак була. НКВД шымчылары паша кабул иткән мөгаллимәне күзәтү астында тоталар. Мәктәп өстендә дә болытлар куера башлый. Югыйсә Багбостанның казанышлары зур – 1925 елга хәтле мәктәпне барлыгы 1212 кыз тәмамлаган, шуларның 347се укытучы булып эшләп киткән.

1925 елны бу татар мәктәбе дә ябылгач, Багбостан Мөэминова Уфага китә. Кырык бер яшьлек ханымга әле алда 38 еллык гомер насыйп була. Аның егерме елын, тоталитар системаның җәберләүләренә түзеп, Себердә сөргендә үткәрә ул. Якташыбызның шул чордагы тормышын яктырту өчен, тагын архивларда эзләнергә кирәк…

Марсель Гарипов ■

Исеме туган ягына кайтты

2017 елның 25 маенда Мәндәй авылында татар дөньясында танылган мәгърифәтче Багбостан Вилдан кызы Мөэминовага истәлек тактасын ачу тантанасы булды.

Истәлек тактасын ачуда муниципаль район башлыгы урынбасары Нәҗҗәт Нәгыймов, Оренбургтан туган якны өйрәнүчеләр Марат Солтангузин һәм Гобәйдулла Рәдүдинең өченче буын туганы Хазирә Габделманова, Казаннан һәм Мәскәүдән тарихчы-галимнәр катнашты.

> «Туган якны өйрәнүче Марат Солтангузин: «Багбостан ханым аркылы күп шәхесләр авылыбызга аяк баскан, без аңа бик рәхмәтлебез. Ул туган якларны күптән килеп күрәсем килә иде».

«Йөз ел элек авылдашыгыз безнең Саракташ районындагы Кабан авылын татар дөньясына танытып киткән булса, безгә дә аның туган авылына килү бәхете насыйп булды. Багбостан ханым аркылы күп шәхесләр авылыбызга аяк баскан, без аңа бик рәхмәтлебез. Ул туган якларны күптән килеп күрәсем килә иде», – диде Марат әфәнде.

Марат Солтангузин архив һәм китапханәләрдә эзләнеп, Багбостан Мөэминова турында шактый материал туплаган. Алга таба Хазирә Габделманова, язучы һәм тарихчы якташыбыз Марсель Гарипов белән бергәләп, китап язарга килешкәннәр.

Мәндәй авылында кунаклар, зиратта булып, борынгы кабер ташлары белән кызыксындылар, Багбостан ханымның әтисе рухына багышлап дога кылдылар.

Истәлек тактасы авыл уртасындагы мәһабәт мәдәният йортына урнаштырылды.

Резеда Шәрипова ■

Татар китабы

Казандагы беренче татар матбагалары

(XIX гасырның беренче яртысы)

Раиф Мәрданов, Ирек Һадиев

Китапчылык үсеше тарихы басмаханәләр барлыкка килүдән һәм аларның эшчәнлегеннән аерылгысыз. Татар халкының алдынгы фикерле уллары чирек гасыр дәвамында патша хөкүмәтенә бик күп үтенечләр белән мөрәҗәгать иткәч һәм башка халык вәкилләре бу гамәлне куәтләгәч кенә, XIX гасыр башында Казанда Коръән һәм башка ислам дине китаплары бастыру өчен матбага ачарга рөхсәт бирелгән.

«Азия» типографиясе

Казан шәһәрендә гарәп хәрефләре белән татар һәм мөселман китаплары бастыра торган беренче «Азия» типографиясе 1800 елда оештырылган. Типографияне ачу өчен 1800 елның 25 маенда император Павел Iдән рөхсәт алынган һәм шул елның 13 сентябрендә ул Сенат Указы белән законлаштырылган. Типографиядә 1800 елның көзендә беренче басма текстлар чыга башлаган, ә беренче татар китаплары 1801 елда дөнья күргән. Бу матбага Казан гимназиясе карамагында булган.

«Азия» типографиясе өчен җиһазларны патша армиясендә хезмәт иткән татар кешесе, чыгышы белән Вятка губернасының Малмыж өязеннән (хәзерге Татарстанның Балтач районыннан) булган Габделгазиз Бурашев Казан гимназиясенә Петербургтан алып кайтып тапшырган. Бурашев патшага 1796 елда ук хосусый татар типографиясе ачарга рөхсәт сорап мөрәҗәгать иткән булган. Петербургта Фәннәр академиясе типографиясенең «Азия» филиалы 1785 елда Иоһанн Карл Шнор карамагына арендага алынган. Анда гарәп хәрефләре белән төрле телләрдә, шул исәптән татарча китаплар бастырылган. Казанга, матбага җиһазлары белән бергә, Шнор типографиясенең исеме дә ияреп кайткан һәм ул «Азия» басмаханәсе дип йөртелгән.

Габделгазиз Бурашев Казанда ачылган беренче татар типографиясен оештыруда иң зур активлык күрсәткән, ул басмаханәнең беренче арендаторы һәм нашире булган. Типографиянең 1801 елдагы беренче басмалары – «Әттәһәҗи» татар әлифбасы һәм «Һәфтияк китабы». Бу типографиядә 1801-1805 еллар эчендә 7 төрле китап 17 мәртәбә бастырып чыгарылган. Болар: «Әлифба», «Коръән», «Һәфтияк», «Сөбател-гаҗизин», «Пиргули китабы», «Устуани китабы», «Фәүзен-нәҗат». Әлеге китаплар барысы да татар мәктәп-мәдрәсәләрендә дәреслек сыйфатында кулланылганнар. Шул вакыттан башлап Казанда даими рәвештә күпләп басы-

> «
> **Апанаев, татар китаплары бастыру эшендә туктаусыз киртәләргә, килешү шартларының ифрат авырлыгына түзә алмыйча, 1809 елда типографияне арендалаудан баш тартырга мәҗбүр булган.**



Беренче татар китабы Әстерханда басылган. Петр I «Манифест»ы. 1722 ел

лып килгән «Коръән» мөселман дөньясында киң таралып, Казан басмасы буларак танылган.

Беренче татар типографиясе оештырылгач, Петербургтан Казанга китап осталары Гали Рәхмәтуллин һәм Хәмзә Мамышев кайткан. Алар икесе дә 1791 елда хәрби хезмәттә вакытларында И.Шнор типографиясенә хәреф җыючы итеп җибәрелгән булганнар. Г.Рәхмәтуллин 1834 елга кадәр Казан типографияләрендә эшләгән һәм гарәп хәрефләре белән басылган китапларны җыючы оста буларак танылган. Ә Х.Мамышев 1829 елга кадәр Казандагы беренче типографиядә хезмәт куйган һәм, моннан тыш, 1805-1811 елларда татар теле укытучысы булып та эшләгән.

Казан гимназиясе идарәсе 1803 елда, Бурашев өстеннән шикаять язып, типографияне яптыру турында сүз кузгаткан һәм аны рәсми рәвештә басмаханә арендалаудан читләштергәннәр. Шулай да 1805 елга кадәр аның җитәкчелегендә китаплар чыгып килгән. Типография 1806-1809 елларда Казан сәүдәгәре Йосыф Апанаев карамагында эшләгән. Ул елларда да, нигездә, алда исемнәре күрсәтелгән китапларны бастыру дәвам иткән. Яңа басмалардан «Сәйфелмөлек» кыйссасы һәм «Мөхәммәдия» әсәре чыгарылган.

Апанаев, татар китаплары бастыру эшендә туктаусыз киртәләргә, килешү шартларының ифрат авырлыгына түзә алмыйча, 1809 елда типографияне арендалаудан баш тартырга мәҗбүр булган. Сенат Указы буенча типографияне арендалау өчен елына 500 сум гына түләү каралса да, 4 елга якын арендалап торган өчен ул 5879 сум 59 тиен акча түләгән.

Патша хөкүмәте һәм чиновниклары тарафыннан татар китабын бастыру чыгымнары бик нык арттырылган. Мәсәлән, 1809 елда рус телендәге китапларны бастыру өчен бер табакка – 17 сум, гарәп хәрефләрендәге христиан миссионерлык китапларының бер табагына – 25 сум, ә татар мөселман китапларының бер табагы өчен 65 сум түләү таләп ителгән. Шул сәбәпле типографияне арендага алырга теләүчеләр бүтән табылмаган һәм аның матди ягын кайгырту гимназия өстенә калган. Китаплар бастыру шактый кимегән, 1810-1829 еллар арасында һәр елда уртача 3-4 исемдәге китап кына дөнья күргән. Кайбер елларда исә (мәсәлән, 1811, 1813, 1815 һ.б.) бер басма да чыгарылмаган.

Әбрар Кәримуллин мәгълүматлары буенча, Казандагы беренче типографиядә 1801-1829 еллар эчендә 93 басма дөнья күргән һәм аларның гомуми тиражы 280

١٢

قدرت

ير اتدى قادر الله كايناتى ؛
اوخلق ايتدى بو جمله ممكناتى ؛
ديلرسه كر ايدر موتاى احيا ؛
ديلرسه هم ايدردى روى موتا ؛
يورورسويلر قمو احجار و اشجار ؛
ديلرسه حضرت خلاق جبار ؛
يرى كوكى ديلارسه يوغ ايدر حق ؛
كير و ايجاده قادر اولدور انجق ؛
ير ادور نيچه يوز بنك بويله كوكلر
او خلق ايلر نيچه بنك بويله يرلار
يو قوشا قرشو ايلر ماءى اجرا ؛
اقر كن اسم ايدر ديرسه مولا ؛
قولن بر ساعت ايچره اى بر ادر ؛
ارادة ايتسه شرقدين غربه ايلتر ؛
دخى شول قوله كم فرمانى اولور ؛
يدنجى قت كوكه وارور و كلور ؛

بو

١٣

بو جمله يرى كوكى ايدر التون ؛
اراده ايلسه خلاق بيچون ؛
قديمدر و ابد دور قدرت حق ؛
تفرق ايلمز ذاتدن محقق ؛

كلام

متكلم دورور سويلر او ستار ؛
بلاحرف ولاصوت دور اى يار ؛
بزم كبى دل ايله سويلمز حق ؛
منزهدور بولاردن ذات مطلق ؛
كمنه واسطه سز سويلر الله ؛
نته كم سويلدى موسيه اول شاه ؛
دخى معراج كيچه سى مصطفايه ؛
بلا كيف سويليوبدور مجتبايه ؛
كمنه انبيادن ايتدى علام ؛
كلامن واسطيله وحى الهام ؛
خبر انلارن جبريل ايله كلدى ؛
نبى ننك اكثرينه بويله اولدى ؛

«Пиргули китабы». Казан, 1802 ел

мең данәгә җиткән. Әлеге типография төрки халыклар арасында, төрекләрдән кала, гарәп хәрефләре белән китап баскан беренче матбага булган. Анда, дини әсәрләр басылу белән бергә. дөньяви китаплар да нәшер ителгән, бу киләчәктә Казанда татар китабы басу эшенең киңәюенә этәргән.

Әлеге типографиянең прогрессив эшчәнлеге үз вакытында ук күренекле галимнәр тарафыннан танылган. Академиклар – Б.Дорн, Х.Френ, К.Фукс, А.Казимбәк һ.б. Казандагы беренче типографиянең эшен югары бәяләгәннәр. Профессор Николай Федорович Катанов: *«Казан татарларының һәм Россиянең Европа өлешендә яшәүче башка вак милләтләрнең мәгарифе күтәрелү турыдан-туры Казандагы беренче «Азия» типографиясе эшчәнлегеннән башлана»*, – дип язган.

Казан гимназиясе каршында ачылып, казна хисабына эшләүче беренче татар басмаханәсе 1829 елда Казан университеты типографиясенә кушылган. Ә университет типографиясе исә 1809 елның 20 гыйнварында ачылган була. Бу матбаганың шул ук елда дөнья күргән беренче басмасы – университетның татар теле укытучысы Ибраһим Хәлфиннең әлифбаны һәм кыскача грамматиканы эченә алган китабы («Шаһиншаһның Казан гимназиясендә лисане төрки вә хатты гарәби үгрәтелә торган әлифба илә кечекчә нәхү вә сарыфыдыр»). Хәлфиннең икенче китабы – «Әхвали Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» хезмәте – 1822 елда чыккан. Татар текстологиясендәге беренче әсәр буларак, бу хезмәтнең фәнни әһәмияте гаять зур.

1829 елда «Азия» типографиясе белән кушылгач, университет типографиясе Казанда татар китабы басучы бердәнбер матбага булып кала һәм Россиядә гарәп

шрифтлары белән китаплар чыгара торган иң алдынгы басмаханәгә әверелә. Монда башка Шәрык халыклары телләрендә дә бик күп китаплар дөнья күргән. 1831 елда яңа хәрефләр кайтартылгач, Казан университеты типографиясендә татар наширләренең китаплары күпләп чыгарыла башлаган. Ел саен 20-40 яңа басма нәшер ителгән. Шәрыкны өйрәнүче университет галимнәренең дә гарәп хәрефләрендәге фәнни хезмәтләре күбрәк чыгарыла, татар теле грамматикасы буенча дәреслекләр дөнья күрә. 1832 елда Юнысов заказы буенча 10 мең данә тираж белән – «Әлифба», 6600 данә – «Коръән» һәм 3300 данә – «Һәфтияк» нәшер ителгән. Типографиядә татар эшчеләре дә хезмәт иткән. Мәсәлән, 1844 елда 17 хезмәткәрнең 7се татар кешесе булган.

Әлеге типографиядә 1830-1850 еллар эчендә университет һәм бүтән оешмалар өчен гарәп шрифтында 29 китап басылган. Болардан тыш, татар наширләре 165 китап бастырган. Алар арасында мәктәп-мәдрәсә дәреслекләре күпчелекне тәшкил иткән. Шулай ук гарәп телендәге фикъһе китаплары, татар телендәге дини-әдәби кыйссалар, хикәятләр басылган. Мәсәлән, «Кыйссаи Йосыф» поэмасы 1839 елдан алып ел саен диярлек, кайбер елларда хәтта берничә басмада чыгарылып килгән. Татар наширләренең даими эшчәнлегеннән килгән файда нәтиҗәсендә типографиянең матди базасы ныгыган, эш җиһазлары яңартылган.

1815-1850 елларда, Петербург Фәннәр академиясе типографиясендә гарәп хәрефләре белән китаплар бастыру тукталган чорда, академиянең мөһим фәнни хезмәтләре Казан университеты типографиясендә басылып чыккан. Монда шулай ук Мәскәү рухани академиясе үтенече буенча да китаплар бастырылган. Казан университеты басмаханәсендә, төрки-татар китапларыннан тыш, гарәп һәм фарсы телләрендәге әсәрләр дә нәшер ителгән.

XIX гасырның икенче яртысында Казан университеты типографиясе Россиядәге иң куәтле һәм уникаль басмаханәләрнең берсе булып җитешкән. Анда дөньядагы бөтен телләрдәге диярлек (хәтта Азия һәм Европаның үле телләрендәге дә) шрифтлар, математика, химия гыйлемнәренең һәм бүтән төр тамга-билгеләр тупланган. Катлаулы шрифтлардан япон һәм кытай иероглифлары, санскрит, әрмән, монгол, уйгыр хәрефләренең төрле кегльләре булган. (Кызганыч ки, бу кыйммәтле байлык Совет хакимияте урнашкач юкка чыккан.)


٩٨
دارلق ایله آلتی یل تمام اولدی انبارلارده آشلق طعام هیچ قالمادی
یوسف سوچی بوحال اوزه فکر قلدی آلهنامده سندن دیور ایمدی
همانـدم جبرائیل کلدی حاضر ویرب ایدی یوسفه ملک قادر
ایدر بوکز صور تنکنی قلغل ظاهر بنم سن قدرتمی کورکل ایمدی
یوسف صدیق اهل شهره خبر قلدی ایرتهقمو میدانه چقنک دیدی
بنوم کورکلو جمالوم کورنک دیدی آچلقدان کورن یوزین دوبار ایمدی
اولو کچی خاص وعام حاضر کلدی یوسفنک جمالنه نظر سالدی
یمک اچمک قایغوسی جمله قالدی بقان هرکیز جمالنه دویمز ایمدی
آیده برکز یوسف صدیق چقار ایدی کورکلو یوزدن پردهسنی سویار ایدی
اولو کچی بای ویوخسول بقار ایدی برارآیغه تیکرو طعام یمز ایمدی
فصل یوسف علیه السلام وزیر تعیین ایندکی
پیک حضرت جبرائیل کلدی حاضر ویرب ایدی یوسفه ملک قادر
یا یوسف جلیل امری بیله درر ایرته حشم برله سیران قلغل ایمدی
حقیقت کمانسز بایق بلکل هر کشیکا ساتش سنک آلب کلکل
آنی آلب اوزنکا وزیر قلغل خالق امری بیلهدرر بلکل ایمدی
یوسفنک برتازی آطی اولور ایدی اول تازینک عادتی شیله ایدی
قچانکم ایارلنسه کشنار ایدی مصر اهلی جمله آنی ایشتور ایمدی
عزیز یوسف آیده برکز چقار ایدی تازی کشنب جمله لشکر کلور ایدی
بیو ردی قللرینه ایارلادی تازی کشنب اولدم لشکر کلور ایمدی
ایکی یوزبنک ارآشار هم اونکندان ایکی یوزبنک ارآشار سول یانندان
ایکی

Кол Гали «Кыйссаи Йосыф». – Казан: Л.Шевиц матбагасы, 1841 ел

Татар китапларын нәшер итүче беренче хосусый басмаханәләр

XIX гасырда татар наширләренең көннән-көн үсә барган ихтыяҗларын Казан университеты матбагасы гына канәгатьләндерә алмый башлаган. Нәтиҗәдә, зур кыенлыклар кичеп булса да, хосусый басмаханәләр ачылган.

Мөхәммәд Чәләби, «Мөхәммәдия». – Казан: Университет матбагасы, 1880 ел

Андыйларның беренчесе 1840 елда немец эшлеклесе, **гравер Людвиг Магнус Шевиц** тарафыннан оештырылган. Шевиц матбага өчен гарәп хәрефләрен Лейпцигтан алдырган. Бу типографиядә барлыгы 45 татар-мөселман китабы басылып чыккан. 1845 елда патша әмере белән Казандагы хосусый типографияләрдә татар китапларын бастыру тыелгач, Л.Шевиц та татар китапларын бастыруны киметкән. Ул, банкротлыкка чыгудан куркып, типографиясен саткан һәм туган иленә кайтып киткән. Шевицның матбагасын 1848 елда **Алабуга сәүдәгәре Николай Петрович Коковин (Кукубин)** сатып алган. Бу типографиядә 1841-1850 еллар эчендә татар наширләре 57 исемдәге китап бастырганнар, ә 1850-1861 елларда 153 китап нәшер ителгән.

Казан шәһәрендәге икенче хосусый басмаханә-литографияне татар кешесе **Шаһи Яхин** 1844 елда ачкан. Әмма 1845 елда татарча китаплар бастыру тыелгач, Яхин матбагасында татар китаплары күп чыкмаган. 1860 елларда бу басмаханә Ш.Яхинның улы Мөхәммәтвәлигә күчкән, 1870 елларда Әбдрәшитов литографиясе дип йөртелгән, 1883 елдан Касыйм Абдуллин ташбасмаханәсе буларак дәвам итеп, 1908 елда эшчәнлеген туктаткан.

Казан шәһәренең Яңа бистәсендә 1844 елда **Рәхимҗан Сәгыйтов** та хосусый басмаханә оештырган. Ләкин 1845 елда патша әмере белән Казанда татар китабы бастыру тыелгач, типографиянең эшчәнлеге чикләнгән. 1850 елга кадәр анда барлыгы 27 исемдәге, ә 1851-1862 елларда 53 исемдәге китап дөнья күргән.

Татар китабын хосусый матбагаларда нәшер итә башлагач, казна типографиясенең монополиясе какшаган: китап басу бәясе арзанайган, сату бәяләре дә төшкән.

1841-1850 елларда Казандагы хосусый типографияләрдә барлыгы 88 исемдәге татар китабы басылган. Шул ук вакытта университет матбагасында 119 татар китабы чыккан. Әлеге 207 исемдәге басманың гомуми тиражы 600 меңнән артып киткән. Ул чорда татар наширләре буларак Казан сәүдәгәрләре – Апанаевлар, Юнысовлар, Сәетборһановлар, Сәгыйтовлар, Хәсән Карташев, Миңнебай Әхмәтов, Гобәйдулла Габдесаттаров; мещаннардан – Мортаза Максутов, Исхак Уразов һәм башка затлар тырышлык куйганнар. Шәкерт-студентлар, крестьяннар, хәтта хатын-кызларның да наширлек белән шөгыльләнү очраклары күзәтелгән. Китап чыгаруга бу кадәрле төрле катлау вәкилләренең тартылуы халыкның китапка һәм белемгә омтылышы зур булу белән аңлатыла.

Хосусый татар матбагалары патша хөкүмәтенең эзәрлекләүләре һәм тыюлары аркасында ябылырга мәҗбүр булганнар. Татарларның хосусый матбагалары яңадан XIX гасыр ахырында гына ачылган.

***

Казандагы басмаханәләрдә 1801-1855 еллар арасында 577 татар китабы басылган. Ул чорда, Мәскәү һәм Петербургтан тыш, Россиянең барлык провинциаль типографияләрендә барлыгы 1463 китап нәшер ителгән. Димәк, бу басмаларның өчтән бер өлешен татар китаплары тәшкил иткән. Шунысын да искәртергә кирәк: XIX гасырның беренче яртысында, Россиядәге бүтән төрки халыкларның берсендә дә китап басылмаганлыктан, татар китаплары башка төркиләр арасында да күп таралган.

XIX гасырның беренче яртысында Казан шәһәрендә барлыгы 401 татар китабы дөнья күргән. 1840 нчы еллар уртасында татар китабы бастыру тыелгач, китаплар бөтенләй чыкмаган диярлек. Ә тыю бетерелгәч, 1850 нче елларда һәр ел саен 30-50 исемдәге китап басылган. 1860 нчы елларда исә, христиан миссионерларының эзәрлекләве нәтиҗәсендә, ел саен нибары 15-20 китап кына чыккан. Татар китапларын бастыру бары тик 1890 нчы еллар башында гына арткан. Ул вакытта бер елда 100дән артык исемдәге, тиражы белән 1 миллионга якын китап нәшер ителгән.

«

Басмалар саны буенча ул чорда Россия империясендә беренче урынны – рус, икенче урынны – латыш һәм өченче урынны татар китаплары билгәгән. Гомуми тираж ягыннан караганда, татар китаплары, рус китапларыннан кала, икенче урында торган.

Басмалар саны буенча әлеге чорда Россия империясендә беренче урынны рус, икенче урынны – латыш һәм өченче урынны татар китаплары биләгән. Гомуми тираж ягыннан караганда, татар китаплары, рус китапларыннан кала, икенче урында торган.

Казан типографияләрендә чыккан татар китапларының саны артуга карамастан, халыкның китапка ихтыяҗы канәгатьләндерелмәгән. XIX гасыр дәвамында, элеккеге гадәт буенча, кульязма китаплар күчереп язу һәм тарату дәвам иткән. Шулай ук Шәрык илләреннән ел саен меңләгән китап кайтарылып торган. ■

Татар матбугаты тарихы

«Җөмһүрият» газетасы

№ 7 ۱۹۱۷ سنه ۲۹ اوکتبر یکشنبه ۷ نچی نومر ۱۳۳۶ سنه ۲۵ محرم

Җөмһүрият

جمهوريت

Адресъ: г. Симбирскъ, редакція газеты «Джмгуріэтъ».

Мусульманская общественно—политическая и литературная газета „Джмгуріэтъ" (Республика).

۱۷نچی نویابر جمعه کون ملی - مدنی مختاریتمزغه ملی خزینه جیو کوندر!

جمعه کون ۱۷نچی نویابر (۱۵نچی صفر) ده بتون مسلمان شهر وآوللرنده

مختاریت کونی

بوکون جیولغان اعانه‌لردن زور بر ملی خزینه تشکیل ایتولچگن هر بر مسلمان خاطرندن چغارماسقه تیوش.

سمبر ولایتی مسلمانلری اسمندن

اوچردیتلی صابرانیاغه کاندیداتلر

۱- احمد بک تیمر بولات اوغلی صالحف - عالی آبراز وانیه‌لی.

۲- خلیل عبدالولی اوغلی ابلخانف - عسکری - پاروچق.

۳- اسحاق مصطفی اوغلی قازاقوف - اوچیتل.

> «
> **Без – Чыңгыз балалары, без оеша беләбез, без үзебезгә үзебез дошман түгел, без төгән итәбез, без фәлән итәбез, диик, әмма халкыбызның Чыңгыз балалыгыннан күптән колак кагып, коңгыз баласына әйләнгән икәнлегеп күрә белмәдек.**

«Җөмһүрият» газетасының беренче бите. Анда мөселман шәһәр вә авылларында «Мохтарият көне» булачагы хакында хәбәр ителгән. 1917 ел, 29 октябрь

Газета 1917 елның 14 сентябреннән Сембер шәһәрендә чыга башлаган. Мөхәррире – Ибраһим Бикколов. Соңрак әлеге вазыйфаны Габдерәүф Шәһиди дәвам иткән. Газетаның нашире – «Сембер вилаять (губернасы) мөселманары шурасы». Газета «Сембер вилаятенең эш башкару типографиясе»ндә дөнья күргән. Басманың үзенә: «Хәзергә атнага бер мәртәбә чыга торган әдәби, сәяси вә иҗтимагый, милли гәзитәдер», – дип язылган.

И.Рәмиев «Җөмһүрият» турында менә ниләр яза: «Гәзит баштарак милли булган һәрнәрсәне мактады. Чыңгыз балалары эшлиләр, эшләячәкләр, зәгыйфь иманлылар, юлдан китегез, милли әмәлләр ташкынында гарык булырсыз!» – дип кычкырды. Соңгы номерларының берендә: «Без – Чыңгыз балалары, без оеша беләбез, без үзебезгә үзебез дошман түгел, без төгән итәбез, без фәлән итәбез, диик, әмма халкыбызның Чыңгыз балалыгыннан күптән колак кагып, коңгыз баласына әйләнгән икәнлегеп күрә белмәдек. Милли корпус, милли полк, милли батальоннарыбызның


عبدالرؤف شهیدی اثرلری:

«آزادلق نرسه؟» . . . . . . بهاسی ۳۰ تین.

«ۋولصت زیمستۋاسی» . . . . . . » ۳۰ »

«ایل قورولتاینده ییر مسئلەسی» . . . » ۳۰ »

«ئەشەکیلر!» درام ٤ پردەده . . . . » ٤۰ »

«اولوملر!» « » . . . . . » ٥۰ »

باصلماقده:

«ایل قورولتایینه صایلاو قاعدەلری».

«مهتدییه»، درام ٥ پردەده.

بو رسالەلرنی صوراو اوچون آدریس:

Симбирскъ, Панская 19, Союзъ Кооперативовъ.

Газетаның икенче мөхәррире Габдерәүф Шәһидинең иҗтимагый-сәяси эчтәлектәге китаплары сатылу турындагы игълан

форсат чыгу берлә авылга куштанлык сатарга, мөгаллим кыйнарга, мәктәп ватарга, китап таптарга йөгерәчәкләрен исәпләмәдек. Эш башындагыларыбызның күбесе – коры куык, салам сыйрак, куян йөрәк. Бу көн бар эшкә белеп, төшенеп, сөеп түгел, тугры килеп кенә тотынучы, булса – ярый, булмаса – таярга карый торган мәхлукат кына икәнлегебезгә күз йомдык, тугрысы, күз йомарга мәҗбүр булдык. Куыкның озак тормый шартлавы ачык билгеле нәрсә инде ул. Менә безнең куыклар да берәм-берәм шартлый тордылар. Күпчелек тарафыннан көч бирелмәгәч...» – ди.

«Җөмһүрият» татар халкының шанлы тарихы, милли яңарышы, Сембер губернасындагы дәүләт оешмаларына татар милләтеннән булган җитәкчеләрне кую, Эчке Русия һәм Себер төркиләренең милли-мәдәни мохтариятен яклау, Учредительное Собраниегә татар кандидатларын тәкъдим итү, мәгариф турындагы мәкаләләр, башка төбәкләрдәге татар тормышы хакындагы хәбәрләр бастырган.

1918 елның 21 апрелендә, РСФСР Милләтләр эшләре буенча халык комиссариаты һәм Татар-башкорт комиссариаты карары белән, Милли идарә таратыла, акчалары тартып алына. Шулай итеп, газета да апрель аенда чыгудан туктый.

Игътибарыгызга «Җөмһүрият»нең 1917 елгы 29 октябрь санында басылган кайбер мәкаләләрне тәкъдим итәбез.

Мохтарият көне

17 ноябрь, җомга көн – Милли-мәдәни мохтариятемезгә милли хәзинә[1] җыю көнедер! Уфада 10-13 октябрьләрдә Милли идарә һәм мохтарият һәйәте хозурында, махсус чакырылган белгечләрнең иштиракы *(катнашы)* илә ясалган малия *(финанс)* киңәш мәҗлесе милләтемезнең бөеклегенә, шан-шәрифенә

[1] Милли хәзинә – милли эшләр өчен тотылачак акча, финанс фонды турында сүз бара. – **Ред.**

Газетаның мөхәррире – җәмәгать эшлеклесе, педагог, публицист, Милләт мәҗлесе депутаты, Милли идарә сәркатибе **Ибраһим Бикколов** (1880 нче еллар-1938)

муафикъ *(туры килгән)* зурлыкта бер милли хәзинә *(фонд)* тәшкил итүне һәм шуның чараларына керешүне лязим *(тиеш)* тапты. Малия киңәш мәҗлесендә үк нигезе салына башлаган милли хәзинәмезне киңәйтү һәм аны милләтемезнең зурлыгына мөнасиб *(туры килгән)* хәлгә китерү өчен, җомга көн 17 ноябрьдә бөтен мөселман шәһәр вә авылларында Мохтарият көне ясалып, милли хәзинәмезгә иганә җыелачак. Бу көн мохтариятемезнең ныгуын теләгән һәрбер мөселман, киң кулына, саф күңеленә ирек биреп, өч йөз елдан бирле көтеп алган милли хәзинәмезгә сумнарын, тиеннәрен аямыйча иганә итәргә тиешледер.

Бу көн җыелган иганәләрдән зур бер милли хәзинә тәшкил ителәчәген һәрбер мөселман хәтереннән чыгармаска тиеш! Мохтарият көне ясау шәһәрләрдә – Милли шураларга, авылларда исә мәхәлләнең имамы, мәхәлләнең мөтәвәллиләре, авылның комиссары, төзелгән булса, Авыл шурасы әгъзаларыннан гыйбарәт бер һәйәткә *(комиссиягә)* тапшырыла[2].

Сембердә тәртипсезлекләр

26 октябрьдә көндез сәгать икедә солдатлар тарафыннан шәһәрне талау башланды. Әүвәл Падогин магазинын талап, андагы исерткеч эчемлекләрне эчтеләр, соңра исерек солдатлар зур урамдагы магазиннарны рәттән таларга тотындылар. Янә бик күп зур магазиннар һәм талчоктагы кибетләр бик нык таланганнар. Солдатлар, һәммә әйберләрне талап алып, икенче көнне урамда ачыктан-ачык саткалап та йөрделәр. 26 октябрьдә төнгә каршы талаучыларны туктатырга чаралар күрелә башлап, 27 октябрьдә иртә берлә 96 нчы полктагы бишенче мөселман ротасының иҗтиһады сәясендә талаулар тәмам туктатылды һәм тынычлык кертелә башлады. 26 октябрьдә кич, 27 октябрьдә көн буе атышу дәвам итте. Мөселман ротасы җитди эшкә керешмәгән булса, бөтен йортларны талап, утлар салып йөрергә дә исәпләре булган, имеш. Мөселман ротасы һәм гаскәри булмаган күңеллеләрне коралландыру сәясендә шәһәргә тәртип кертелеп, 28ендә иртә берлә шәһәрдә табигый тормыш башланды, магазиннар ачылды. Хәзер шәһәрдә тынычлык инде.

[2] Милли идарә рәисе С.Максудиның да мөселманнарга мөрәҗәгатеннән соң, фондта байтак сумма туплана. Бу акчага Милләт мәҗлесе җыеннары уза торган бина (Уфадагы С.Шәмгулов кибете) җиһазландырыла.

Укытучылар дикъкатенә

Сембер вилаяте укытучылар берегe, вилаятемездәге ачылачак мәктәпләр өчен алты еллык ибтидаи *(башлангыч)* мәктәп програмы белән укылачак дәреслекләр җитештерүне тиеш табып, китаплар хәзерләргә муаффәкъ булды *(иреште)*. «Алты еллык ибтидаи мәктәп програмы»нда күрсәтелгән китапларның күбесе һәм һәр кыйтганың хариталары (картлары) хәзерләнде. Тизрәк мөрәҗәгать итеңез.

Вилаять укытучылар берегe рәисе Кәрим Мөшәрәфов.
Сембердә, Ниж.Татарски урамда ирләр мәктәбе.

Волость земствосы төзелү

1917 сәнә 17 октябрьдә Сембер өязе Олуг Тархан карьясендә Олуг Тархан волость земствосы түбәндәге тәртип берлә төзелде. Управа залында мөселманнардан – 17, рус, мордва, чуашлардан – 17, барлыгы 34 кеше мировой судья тәхте риясәтендә *(җитәкчлегендә)* мәҗлес ачылып, мәҗлес өчен кятиб һәм рәис сайланды. Шуннан соң руслар – бер бүлмәдә, мөселманнар икенче бүлмәдә эш башлау алды догасы ясады. Мөселманнардан өч гласный имам булып, Мазһар хәзрәт Гаффаров Коръән укып, догалар кылынды. Соңра башка гласныйлар вәгазь вә нәсыйхәтләр кылышып, бер-берен иттифакъ вә иттихадка *(фикер берлегенә)* өндәде һәм управага мөселманнардан ике кешене уздырырга тәгаен итте. Соңра, һәр ике фирка бушап, янәдән мәҗлес ачылды. Мәҗлес ачылу илә Земски управага Михаил Казаков – рәис, Мөхәммәдзариф Хөсәенов илә Мөхәммәдгали Мөхәммәдҗанов мөгин *(ярдәмче)* рәис тәгаен ителделәр.

Соңра управаның гади эшләре өстенә продовольство эшләре, гаскәргә терлек әзерләү, пособие бирү вә башка төрле күп эшләр вә хезмәтләр артканга, бу эшләрне дә управа өстенә йөкләтеп, янә ике әгъза арттырылды. Сайлау тәмам булгач, председательне – поп, ике мөгинне *(ярдәмчене)* имам иттерделәр. Бу көннән Милли мохтарият иҗраэ ителә *(эшли)* башлаганга күрә, гаризалар һәркая мөселманча *(татарча)* язылып тапшырылырга лязим *(тиеш)* булып, сәркатипләр эчендә берсе русча-татарча яхшы белгән бер мөселман булуын шарт итеп, протоколга кыйд иттерелде *(кертелде)*. Шуның өчен русча-татарча белгән, милли хисле бер адәм булса, яхшы жалуния берлә кабул ителәчәге игълям *(игълан)* ителәдер.

Габдулла Хәкимов

Управа рәисе – мөселман

Сембер өязе Чынлы волосте Земский управасына рәислеккә мөселманнан Нурмөхәммәд әфәнде Госманов сайланган. Нурмөхәммәд әфәнде гәзитәләрдә исеме күренгәләп торган аңлы вә зыялы егетләремездән булганга күрә, аның рәислеккә сайлануы бик муффәкъкыятьле *(уңышлы)* булган. Нурмөхәммәд әфәнденең мөселманнарга файдалы хезмәтләрдә булынуын өмид итәмез.

Текстларны басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *һәм* ***Рәйсә Шәрәфиева*** *әзерләде.* ■

Яңа Татар бистәсе мирасы

Зариф Әмирханның кабер ташы

Айдар Гайнетдинов

Зариф Әмирхан – дин һәм җәмәгать эшлеклесе, педагог, тарихчы. Күпләргә ул язучы Фатих Әмирханның газиз әтисе буларак билгеле. З.Әмирханның безгә мәгълүм булган шәҗәрәсе мондый: ***Мөхәммәдзариф бине Хөсәен бине Әмирхан бине Габделмәннан бине Исмәгыйль бине Морад бине Кадермәт бине Әхмәд бине Җәлмәт бине Гәрәй.*** *Аның бабалары хәзерге Чистай районының Талкыш авылыннан.*

З.Әмирхан 1853 елның 10 гыйнварында Казан шәһәрендә дөньяга килгән. Ул башлангыч белемне атасыннан алган, Казанда Сәлахеддин хәзрәт мәдрәсәсендә укыган. Соңрак хәзерге Арча районының Югары Курса авылында шәех Хәсән бине Халид мәдрәсәсендә гыйлем эстәгән. 1872-1874 елларда ул Норлатта шәех Фәхреддин бине Мостай мәдрәсәсендә укыган, «Коръән»не тулысынча ятлаган. З.Әмирханга Шиһабеддин Мәрҗани дәресләрендә дә утыру бәхете тәтегән. Ул 1875 елда атасы янына Казанның «Иске Таш» мәчетенә имам итеп билгеләнгән. 47 ел имам булып торганнан соң, Зариф хәзрәт 1921 елның 24 июнендә, эче бик нык борчып, ваба авыруыннан бакыйлыкка күчкән һәм Казанның Яңа Татар бистәсе зиратында җирләнгән. Аның элекке кабер ташы хәзерге көнгә хәтле чагыштырмача яхшы сакланган.

Текстының укылышы түбәндәгечә:

Алгы ягы (уеп язылган):
1) *«47 йыллык*
2) *имамәте әснасында*
3) *дине ислам*
4) *тәлкыйне һәм*
5) *Коръән Кәрим*
6) *тәгълиме белән*
7) *мәшгуль*
8) *булды*
9) *Мөхәммәд-*
10) *зариф бине Хөсәйен*
11) *әл-Әмирхани*
12) *19 шәүвәл 1339 сәнәдә,*
13) *24 ийүн 1921 йыл*
14) *дарел-бәкага күчде*
15) *69 йәшендә».*

Уң ягы (уеп язылган):

1) *«Әл-әхыйлләәәәү йәүмәъизим-бәгъдуһүм ли-бәгъдыйн гадүввүн илләәл-мүттәкыйын*

2) *йәә гыйбәәди ләә хәүфүн галәйкүмүл-йәүмә вә ләә әңтүм тәхзәнүүн».*

Сул ягы (уеп язылган):
1) *«Бу кабер ташы – әһле мәсҗеденең*
2) *мәрхүмгә хатирәләредер».*

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе:

Алгы ягы:
1) *«47 еллык*
2) *имамлыгы вакытында*
3) *ислам динен*
4) *аңлату һәм*
5) *Коръән Кәримне*
6) *өйрәтү белән*
7) *мәшгуль*
8) *булды.*
9) *Мөхәммәд-*
10) *зариф бине Хөсәен*
11) *Әмирхани*
12) *1339 елның 19 шәүвәлендә,*
13) *1921 елның 24 июнендә*
14) *мәңгелек дөньяга күчте*
15) *69 яшендә».*

Уң ягы:

1) *«Кыямәт көнендә кайберәүләр кайберәүләргә дошман булырлар, тик тәкъвалык кылган мөэминнәр генә алай булмас.*

2) *Әй, колларым, бүген сезгә куркыныч һәм көенеч юк».*

Сул ягы:
1) *«Бу кабер ташы – мәчет халкының*
2) *мәрхүмгә хатирәләре».*



Таш үлчәмнәре: 164x21/29x14/18.

Күргәнебезчә, әлеге ташны Зариф хәзрәткә «Иске Таш мәчет» мәхәлләсе халкы ясатып куйдырган.

***

Г.Баруди үзенең «Хатирә дәфтәре»ндә аның хакында болай язган: «Үзе зирәк, аңлы, акыллы, алдан күрүчән, сәламәт йөрәкле, үч итү һәм хөсетлектән пакь, мәхәллә халкы өчен хәерхаһлы, яшь һәм картларны тәрбия итү өлкәсендә тырыш, хуш авазлы, Коръәнне дөрес уку иясе булып, гади халыкны да бу өлкәдә байтак төзәткән иде... Тәрҗемәи хәле сөйләнүче зур гыйлем иясе булмаса да, туры юлда булучы галим иде. Гыйлем, изгелек ияләреннән файда алуда, милләтнең дини, гыйльми, икътисади файдаларында тырышлык һәм туры фикер белән хәрәкәт итә иде. Соңгы елларда гыйбадәтен арттырган, җәмәгать намазларын калдырмый, Коръән укуда дәвамлы, сынык күңелле, яшьле күзле, юмарт, хөрмәтле нәфесле, сагынырлык кеше иде». ■

Безнең мирас №8 август 2020

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов

Гыйбадәтханә. XX гасыр башы

Профессор Таката һәм япон язуы

Мин икенче көнне, язылган адрес буенча, чакырылган җиргә киттем. Бер гыйбадәтханә эчендә халык җыелган. Болар әллә ни күп түгел иде: йөз-йөз егермеләп кеше булыр, көтәләр иде. Ун минутлап вакыт үткәннән соң, профессор трибунага чакырылды һәм мондый чыгышын башлады:

«Безнең, япон милләтенең, көчсез елларында арабызга дошманнар үтеп кергән һәм, үзләренең бозык фикерләрен җәелдерер өчен, бертуктаусыз милләтебезне бүлгәләү эше алып баралар. Һәр тарафта фетнә чыгару юлларын эзлиләр, теләсә нинди сәбәп табып кына торалар, икеләнеп тә тормыйча, уйлаганнарын тормышка ашырырга омтылалар. Максатлары – безне бер-беребездән аеру, шул юл белән көчсезләндерү, рухыбызны какшатып, безне үзләренә кол итү. Инде хәзер ул кара эчле затлар безнең ике мең елдан бирле куллана килгән язу рәвешебезгә бәйләнәләр. Төрле дәлилләр китереп, безнең иероглифларыбызның халыкка авыр булуы, уку-язу өчен башка хәрефләр кабул итәргә кирәклеге турында үз фикерләрен җәелдерергә тырышалар.

Дөрес, хәзерге көндә без кулланган иероглифлар, нигездә, безнең үз хәрефләребез түгел, күрше кытай милләтенең хәрефләре. Әмма без бу хәрефләрне инде менә ике мең елга якын кулланабыз, ул инде безнең үз байлыгыбызга, үз хакыбызга әйләнгән диярлек.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

Чынлыкта да, иероглифлар – үз байлыгыбыз, чөнки бу язу системасына без бик күп өстәмәләр, төзәтмәләр керткәнбез. Бүгенге көндә миллионнарча китабыбыз әлеге хәрефләр белән басылган. Илле миллион кеше шушы хәрефләр белән укый, яза. Шулай булгач, безнең бу язуыбызны башка хәрефләр белән алыштыру мөмкин хәлме?! Моның мөмкин түгеллеген ул кара эчле затлар да белә, тик аларның максаты – милләтне бүлү, бер-берсенә каршы кую, шуңа күрә менә шундый булмастай мәсьәләләрне китереп чыгаралар. Безнең акылсыз, Аурупа гашыйгы ахмакларыбыз буласын-булмасын, файдасын-зыянын уйлап тормыйлар, бары тик шул кара эчле затларның сүзләренә карап: «Менә шундый бернәрсә таптык, шундый бернәрсә ачтык», – дигән булып, мәйданнарга чыгалар. Болар сукыр, сүзләренә дә игътибар итәргә кирәкми. Алар да Ватан дошманнары, чөнки дошман сүзен алга алалар. Дуслар һәм дуслык фикерендә булганнар бервакытта да милләтне көчсезләндерүгә хезмәт итмәсләр. Милләтнең уй-фикерен мондый кирәкмәгән нәрсәләр белән чупләү, милләтне бүлгәләү – милләтне юкка чыгаруга хезмәт итү дигән сүз.

Әлифбаның нигезе кеше табигатенең таләбе буенча барлыкка килгән, иҗатчысы – табигать үзе. Шулай булгач, бу хәрефләрнең үзгәртелүе кеше табигатен үзгәртү белән бәйле һәм ул табигать үзгәрү дәрәҗәсендә үзгәрә. Моны исбатлауга хаҗәт юктыр дип уйлыйм. Кеше, үз язуына игътибар итеп, төрле вакытларда язган язмаларын күздән кичерсә дә җитә: шат һәм канәгать вакытларында язганнары һәм шул чакта кулланган каләме белән күңеле төшкән, кайгырган чакларында язганнары һәм кулланган каләме арасында гаять зур аерма бар.

Аерым игътибарга алып, гомуми бәяләмә бирсәк, шул аңлашыла: милләтләрнең табигате аерым кешеләренең табигатьләреннән оешкан. Әгәр милләт тәрәккый итсә, ул милләтнең гомуми табигатендә, көннән-көн үк булмаса да, айдан-ай, елдан-ел рухи күтәрелеш барлыкка килә, һәр эштә үзеннән-үзе алга бару, күтәрелү билгеләре күренә. Мондый вакытта бу милләт кулланган хәрефләрдә дә үзеннәнүзе үсеш, үзгәреш билгеләре күренә башлый.

Бүгенге көндә алга киткән милләтләрнең моннан 200-300 еллар элек кулланган язулары белән хәзерге язуларын чагыштырып карасагыз, күбесендә гаҗәеп зур аермалар булуын күрерсез, ләкин хәрефләренең нигезләре шул ук кала биргән. Нигездән үзгәртү, алыштыру, әлбәттә, хаклы рәвештә кирәк күрелмәгән.

Тагын шуңа да игътибар итәргә кирәк: милләтләр тарафыннан кулланылган язу төре белән шул милләтнең табигатендә бик зур рухи бәйләнеш бар. Уңнан сулга, сулдан уңга һәм өстән аска таба язулар барысы да милләтләрнең табигате белән бәйле.

Көнчыгыш халыкларының хәрефләре Көнчыгыш табигатенә, Көнбатыш халыклары куллана торган шәкелләр, язу төрләре исә Көнбатыш табигатенә туры килеп тора.

Көнчыгыш халыкларында яратылышлары белән бәйле шундый бер көч бар: Көнбатыш халыкларында андый көчне күз алдына да китереп булмый. Көнчыгыш халыклары авыр хезмәттән тәм таба беләләр. Дөньяда Көнчыгыш милләте өчен авырлык-кыенлык дигән нәрсә юк. Эш никадәр генә авыр булса да, табигате аны авыр итеп күрми һәм, гомумән, асылы белән табигый булган нәрсәдә авырлык булмый.

Менә шул егерме-утыз мең төрле шәкелдән оешкан язу японнарның үзләре өчен гаять табигый. Уйлап карагыз: бүген мәмләкәтебездә укый-яза белми торган кеше юк, әгәр язу табигый булмаса, ул бу дәрәҗәдә җәелә алыр идеме икән?! Бүгенге көндә илле миллион кешене тәшкил иткән милләтебезгә мәгариф җәелдерү

чарасы булып торган иероглифлар, язу системасы буларак, табигатебезгә дә бик ярашып тора. Хәрефләр һәм язу – милләтнең рухи азыгы ул. Без, японнарның, матди азыгы булган ашамлыкларыбыз да Аурупа кешеләренә ризыкланыр өчен туры килеп бетми, безнең ризык белән алар яши алмый. Тик безнең үзебез өчен бу ризыклар менә дигән! Япон кешесенең иң бае белән иң ярлысы арасында бернинди аерма да юк. Белем алыр өчен Америкага, Аурупага киткән яшьләребезнең дә, хәтта мәмләкәткә кире кайткач та, табигый ризыклары булган япон ашларына өстенлек бирүләре мәгълүм хәл. Хәрефләребез дә нәкъ шулай, алар мәгариф өчен ризыгыбыз булып торалар. Язуыбыз тамырдан үзгәртелә алмый, әмма үзеннән-үзе үзгәрә, камилләшә ала – анысы башка мәсьәлә. Язуыбыз, билгеле, үсеш-үзгәреш кичергән, ул әле дә дәвам итә.

Мәсәлән, «тау» сүзе моннан ике йөз ел элек болай язылган: 山, йөз ел элек исә, 山 рәвешле; бүгенге көндә исә менә болай языла: 山. Һичшиксез, нигезе шул ук, бары тик рәсем итеп сызылу рәвеше генә үзгәргән».

Шуннан соң, профессор әфәнде: «Фәлән-фәлән сүзләр ике йөз ел элек болай, хәзер исә менә болай языла», – дип, бик күп хәреф язып күрсәтте. Аннары: «Болардагы үзгәрешләр гаять табигый, аңлатып торуның хаҗәте дә юк», – диде һәм чыгышын дәвам итте: «Хәзерге көндә безнең яшьләребезнең, миссионерларның фикеренә бирелеп, хәреф үзгәртү турында уйланулары табигатькә каршы бару белән бер үк диярлек. Ике-өч мең ел эчендә милләтебез өчен табигый җирлек булып торган нәрсәгә каршы бару – битарафлык, милләт язмышына бармак аша карау дигән сүз. Әгәр иероглиф мәгарифкә һәм алга баруга киртә булып торса, мәмләкәтебез илле ел эчендә бу дәрәҗәгә ирешә алмас иде. Тагын илле ел үтүгә, Япония Җир шарында беренче дәүләт булуга ирешер дигән өметтә калам.

Әле шундый замана да килер: Япония бу иероглиф системасын бөтен дөньяга тәкъдим итәр һәм тәкъдим итүе белән хаклы да булыр. Ник дигәндә, иероглиф системасында бертөрле уртак мәнфәгать бар, кеше әлеге хакта инсаф белән уйланса, инкарь итә алмас. Бүгенге көндә япон, кытай һәм корея телләре өчесе өч аерым тел булып санала. Корея кешесе сөйләшкәндә япон һәм кытай кешесе бер генә сүз дә аңламый, нәкъ шулай ук кытай кешесе сөйләшкәндә япон кешесе дә, корея кешесе дә берни аңламый. Тик бу өч милләт кешесенең берсе, иероглиф кулланып, үз телендә берәр нәрсә язса, теге икесе ул язуны үз телендә укып аңлый ала. Әгәр аз гына тырышлык күрсәтелсә, бу иероглиф системасы әлеге өч милләтне бик тиз берләштерәчәк. Корея кешесе өчен япон телен өйрәнү кирәк булмаячак, нәкъ шулай ук япон кешесе өчен дә корея һәм кытай телләрен өйрәнүнең хаҗәте калмаячак. Иероглиф ярдәме белән тәрҗемәчедән башка да бик яхшы аралашырга мөмкин булачак.

Әйтик, француз, инглиз һәм рус кешеләре үз телләрендә иероглиф белән язсалар, һичшиксез, тәрҗемәгә ихтыяҗ тоймыйча да, бер-берсен укып аңларлар иде. Шундый зур мөмкинлек булганда, аны җәелдерү кирәк түгелме икәнни?! «Без тотабыз да, бу язуны юк итәбез!» – дию – никадәр акылсызлык!

Ватаныбызны, милләтебезне сакларга, якларга теләсәк, милләтебезнеке булган бар нәрсәне дә сакларга тиешбез. Хәрефләребез, һәрбер сүзебез безнең өчен изге. *(Алкышлар.)* Бүгенге иероглиф системасындагы бер генә бөртек сүзебезнең дә юкка чыгуын теләмибез!»

Профессор Такита, көчле кул чабулар эчендә, сөйләвен тәмамлады. Такита җәнапларының чыгышы бик киң, тирән эчтәлекле, җентекле иде. Мин исә бары тик бу кадәрен генә теркәргә җитешә алдым.

Япония. XX гасыр башы.
Арнольде Генте фотосы

Әлеге җыелыштан соң, мин әлеге мәсьәлә буенча күп кенә дәүләт эшлеклеләре һәм япон җәмгыятенең алдынгы шәхесләре белән фикер алыштым. Шуны аңладым: миссионерлар, тагын мең ел буе тырышып-тырмашсалар да, берни чыгара алмаячаклар, бушка маташкан булачаклар.

Хөкүмәт кешеләренең берсе хәтта болай диде: «Бүген дәүләтебезнең бөтен серләре бу иероглиф белән теркәлгән. Иероглиф – дәүләтебезнең рухи көче, дияргә мөмкин. Бүген, булуы мөмкин түгел, шулай да, әйтик, милләт иероглифтан ваз кичсә, хәтта шул очракта да, хөкүмәт һичбервакыт ваз кичә алмаячак. Киресенчә, хөкүмәтнең аны җәелдерәчәге катгый хәл ителгән».

Сүз арасында: Безнең әлифба үзгәртүче «иҗат әһелләребез» гыйбрәт алсын...

Тарихчылар җәмгыяте

Бу җәмгыять турында 212 нче биттә бераз язып киткән идем[1]. Анда җәмгыять рәисенең исемен Хиаши дип язган идем, дөресе Тераши булырга тиеш.

Җәмгыятьнең мартның 20сендәге гомуми җыелышына мине кабат чакырдылар. Мин килгәндә, җитмешләп кеше җыелган иде: барысы да олы яшьтәге кешеләр, яшьләр бик аз.

Җәмгыять әгъзалары җыелып беткәнче, форсаттан файдаланып, мин Тераши җәнапларына берничә сорау бирдем:

– Җәмгыятьнең төп вазыйфасы нәрсә?

– Әһәмиятле вакыйгаларның барысын да теркәп барабыз, моннан тыш, кайбер вакыйгаларның сәбәпләрен дә ачыкларга тырышабыз. Мәсәлән, кеше үтерү вакыйгасында үтерүченең холкын, табигатен дә тикшереп өйрәнәбез. Җинаятьнең сәбәпләрен хөкеме белән бергә теркибез. Мәсәлән, 21 нче Мидинең 18 сентябрендә чит илләр эшләре министры Конт Окоманы үтерергә теләгән Кирошима Җинако кем иде? Әхлагы нинди иде? Боларның һәммәсе дә теркәп, язып барыла. Борынгы тарихыбызны да өйрәнәбез, вазыйфабыз аз түгел. Сезнең Япониягә килүегез турында да һәм ясаган бөтен чыгышларыгызның эчтәлеген дә язып куячакбыз.

Ул арада тагын берничә кеше килде. Җыелышның рәисе Җошима җәнаплары миңа болай диде:

– Сезгә кадәр дә татарлар белән мөнәсәбәтләребез бар иде. Моннан 1110 ел элек, Камчаткадагы Татар бугазын кичеп, Сахалин юлы белән Япониягә Мөхәммәди

[1] Бу 212 нче бит – хезмәтнең госманлы төрек теле белән басылган беренче басмасындагы бит саны (тәрҗ. иск.).

татарларның килүе билгеле. Бу дата Синдай янындагы ташта чокып язылган. Бүгенге көндә дә бар. Моннан 800 ел элек Чыңгыз хан нәселеннән бер мулланың килүе дә тарихыбызга теркәлгән. Безнең японнар башта ул кешегә агентка караган кебек караганнар, аннары, дөреслекне аңлаганнан соң, олы хөрмәт күрсәткәннәр. Моннан тыш, бездә шундый риваять тә бар: японнарның иң атаклы каһарманнарының берсе – Йасҗини исемле кеше берзаман юкка чыга. Бераздан аның Чыңгыз хан гаскәрендә башлык булып торуы беленә. Сезнең тарихыгызда моңа охшаш нәрсәләр бармы?

> «
> **Мин исә, бик уңайсызланып кына: «Безнең татарларның тарихы бик ул кадәр өйрәнелмәгән, теркәлмәгән», – дияргә мәҗбүр булдым.**

Мин исә, бик уңайсызланып кына: «Безнең татарларның тарихы бик ул кадәр өйрәнелмәгән, теркәлмәгән», – дияргә мәҗбүр булдым.

Моннан соң бер яшь әфәнде сары раса турында сөйләп китте, татарлар белән японнар арасында раса (ыру) бәйләнеше барлыгын әйтте. Рус-япон сугышы вакытында яуда үзләре теләп катнашкан Кавказ мөселманнарын тәнкыйть итте.

Җәмгыять әгъзалары һаман киләләр дә киләләр, инде йөздән артык кеше булгандыр. Ул арада җәмгыятьнең гомуми рәисе Синтагана җәнаплары миңа: «Хәзер җыелышны ачачакбыз, рәислек вазыйфасын кабул итеп алуыгызны сорыйбыз», – диде. Һәр яклап кул чабу, «Сорыйбыз!» дигән авазлар яңгырады. Мин торып бастым, сәламләү сүзе белән кыска гына чыгыш ясаганнан соң, җыелышны ачтым. Җәмгыятьнең идарә рәисе Тераши җәнаплары бер ай эчендә башкарылган эшләрнең кыскача эчтәлеген сөйләде. Ул арада җыелышта катнашучылардан берәү аягүрә торып басты да: «Без үз эшләребез белән һәрвакыт шөгыльләнә алабыз, бүгенге җыелышыбызда кунагыбыз Ибраһимны хөрмәтлик, җыелышның рәсми өлешен шуның белән тәмамлыйк», – диде.

Кул чабулар ишетелде. Рәсми өлеш шуның белән тәмам булды.

Табынга ризык-сый китерә башладылар, табын артындагылар бер үк вакытта шигырьләр сөйли иде. Шул рәвешле ике сәгатькә якын аралашу, сыйлану булды. Ризыклары искиткеч гади: бары тик берничә төрле балык белән пешкән дөге, боткага охшаш бернәрсә, май юк, ит юк, тоз да юк. Бар да аралашу-сөйләшү белән мәшгуль иде. Мин дә, форсаттан файдаланып, Япониянең ничек алга китүе, бу үсешнең кайчан башлануы турында сорау бирдем. Мәҗлестә катнашучылар арасыннан Токио Хокук советы рәисе булган олы яшьтәге бер әфәнде кыска гына мәгълүмат бирде. Сезгә шуны китереп үтәм:

«Япония моннан 50 ел элек 300 өлкәгә бүленгән иде. Мәмләкәтнең хакимияте һәм императорлыгы бүгенге династиядән булса да, гомумән алганда, бу өлкәләр аерым әмирлек кебек идарә ителә иде. Һәр әмирлек үз өлкәсендә хөр һәм мөстәкыйль иде. Бер-берләренә каршы сугышлар ачалар, берсенең мөлкәте башкасына күчә торган иде һ.б., һ.б. Шулай булса да, федерация ысулы белән боларның барысы бергә Япония дип атала һәм императорлыкның башкаласы Киото шәһәре иде.

Чимбо Тинго тарихының 20 нче елларында Токио әмирлегендә булган Токогавакики үзе аерым көчле әмирлеккә әверелә бара иде. Ул, бик күп сугышларда җиңеп чыгып, зурайганнан-зурая бара һәм, ниһаять, императорлыкка каршы да сугыш игълан итә.

«

Ризыклары искиткеч гади: бары тик берничә төрле балык белән пешкән дөге, боткага охшаш бернәрсә, май юк, ит юк, тоз да юк.

Шул арада әмирлекләр арасында берләшү, аңлашу башлана. Бу якынаюга 1808 елда Америкада Япониягә каршы оештырылган демонстрация сәбәпче була. Американың һөҗүм итәчәген сизеп алган японнар үз араларында берләшүнең зарурлыгы турындагы кискен карарга киләләр. Токогавакики, табигый көче белән җиңеп чыккач, бөтен әмирлекләр белән бергә үз әмирлеген дә бетереп, үзе бөтен мәмләкәтне хәзерге Микадога тапшыра. Императорлык Токиога күчерелә. Дөресен генә әйткәндә, өебезгә читтән угры-карак килеп керәчәген сизгәч, тиз генә берләшкәнбез булып чыга. Аннары шулар аңлашыла: гыйлем һәм мәгарифкә ихтыяҗыбыз бик зур, яшьләребез Аурупага белем алыр өчен җибәрелә, укытучылар китертелә. Кыскасы, II Миди тарихында 1872 елда бер пароход фирмасы оештырыла, бу – Ниппон Посин Кайси фирмасы. Менә үсеш, алга китеш шуннан башлана дисәк тә була, чөнки моңа кадәр Япониядә пароход кебек берни дә булмый. Моннан соңгы вакыйгалар өчен Сезгә Диңгез эшләре статистикасын күрсәтү белән чикләнәчәкмен.

Япониядә сәүдә пароходлары болай күбәйгән:

10 нчы Миди тарихында 100 пароход, 44.240 тонилато;

15 нче Миди тарихында 216 пароход, 64.416 тонилато;

20 нче Миди тарихында 468 пароход, 70.022 тонилато;

30 нчы Миди тарихында 1428 пароход, 663.643 тонилато;

42 нче Миди тарихында (хәзерге вакытта) 2324 пароход 1400221 тонилато.

Шуны да әйтергә кирәк: болар бар да – сәүдә пароходлары, хөкүмәтнең флот пароходлары аерым исемлектә.

Тагын да шул ук сәүдә пароходларын төзекләндерү яки яңа пароходлар төзү өчен 44 су яны депосы һәм 200дән артык верфь бар.

Шул рәвешле, Япония һәр җәһәттән зур тизлек белән алга китә бара. Боларның һәммәсе дә, әлбәттә, халыкның тырышлыгы белән генә тормышка ашырыла ала. Хөкүмәт тә үз өстенә төшкәннәрне шундый ук тырышлык белән башкара. Ниһаять, нәтиҗәне бүгенге көндә ирешелгәннәрдән бик ачык күрергә мөмкин.

Мин хәзергә менә шундый мәгълүматлар белән чикләнәм. Тагын берәр төрле мәгълүмат алырга теләсәгез, бирербез – җәмгыятебезнең вазыйфасы бу. Сезгә хезмәт күрсәтә алу – безнең өчен зур дәрәҗә».

Шул рәвешле, мәҗлестә гаять самими сөйләшү, фикер алышулар булды. Сәгать ун тулып киткән иде. Шунда ук рикшалар чакырып китерелде. Мин, җәмгыять әгъзалары белән берәм-берәм саубуллашып, китеп бардым.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе.* ■

Мөһаҗирлектәге татар китабы

Әхмәд Гәрәй шигырьләре[1]

Хәятем!

Исемә төшә кечкенә бала чакларым,
Беренче башлап мәктәпкә
барганнарым.
Соңрак абый белән сабан сөргәннәрем,
Җәйге кичләр ат көтәргә йөргәннәрем.

Әл дә онытмыйм авылыбызның зур
кырларын,
Су буйларын, гөрләгән Сабан туйларын.
Уралда урман кискәндә күкрәк белән
«Карурман» дип җырлаган Урал
көйләрен.

Җәйге кичләр яшел хәтфә болыннарда
Үрелеп-киерелеп тирләп печән
чапканнарым.
Көз кичләре салкын сизми, армый-
талмый,
Таудан-тауга, аудан-ауга йөргәннәрем.

Киң Ватанда киләчәктә ак тормышлар
Төзермен дип балалыкдан теләсәм дә,
Теләгемнең хыялында уйламадым
Киләчәктә башымныңниләр күрәсен.

Ничә тапкыр, ничә җирдә төрмәләрдә,
Ничә еллар сөргеннәрдә изелгәнем.
Ничә тапкыр ачлыктан шешенгәннәрем,
Йә, бу көн, дип, йә, үләм, дип качканнарым.

Бәхетсез икәнлегемне соңрак сиздем,
Милләтемнең изелгәнлеген аңладым.
Ләкин киләчәктән өметемне өзмичә,
Бер көн безгә дә азатлык булыр диеп.



S O M E P O E M S
O f
E M I L Y D I C K I N S O N

Translated Into The Tatar Language
By
Ahmed Gerey
June, 1963.

"My Faith is Larger than the Hills -
So when the Hills decay ...."

ЛИЧНАЯ БИБЛИОТЕКА
ПРОФЕССОРА
Х.МИННЕГУЛОВА

Эмилия Дикинсонның татарчага тәрҗемә ителгән әсәре басылган китап тышлыгы

Тормыш миңа никадәр авыр булса да,
Ватанымнан аерылсам, озаклашсам да,
Билем бөкрәеп, күзем күрмәс
картайсам да, –
Мин җырлармын Урал көйләрен һаман да.

Серакуза, 1946

[1] Алар шагыйрьнең 1963-1967 елларда Нью-Йоркта төзелгән ошбу җыентыкларыннан сайлап алынды: «Ниләр, ниләр... тагы да ниләр?!», «Чит илләрдә җырлаганым», «Юлым аерылды икегә», «Корбан бәйрәмегез котлы булсын», «Югалган яшьлегем». Гарәп хәрефләре белән язылган шигырьләрне хәзерге графикага күчерүче, кайбер аңлатмалар бирүче – Хатыйп Миңнегулов. Текстлар, нигездә, оригиналдагыча калдырылды.

Һомерга[2]

Нинди китапка карасаң —
иске юнанлар, диләр,
Һәм шагыйрьләр, һәм галимнәр,
һәм каһарманлар, диләр.

Дөньяның караңгы чагында алар
ут яндырып,
Иң беренче юлны гыйлемгә
алар салган, диләр.

Һәммәгә юл башлаган сукыр шагыйрь
Һомер, диләр.
Җыр белән ул халкының күңлен, күзен
ачкан, диләр.

Соңра килгәнләр юнанлар һәр тарафка
ут тотып,
Табигый фән нурларын караңгы
дөньяга чәчеп.

Әнә шул нурлар гасырлардан үтеп
килде миңа,
Тик һәммәнең син әүвәле, дип
баш иям, Һомер, сиңа.
Искәндәрия, 1951

Бу дөньяны аңламадым

Бу дөньяны аңлый алмадым,
Кылычка куярдай булдым –
куя алмадым.
«Хаклык, гаделлек бармы?» – дип
Кычкырдым – җавап ала алмадым.

Лачын

*(Бала чактагы Урал тауларындагы
бер хатирәдән)*

Һаваларны ярып күк йөзендә
Күз иярми бер лачын оча.
Әйләнеп-әйләнеп оча, meteor[3]
Гүя, кошларга ул падишаһ.

Айдагы Зөһрә

Ачык төндә тулы ай өстендәге Зөһрә
Кош канатларыдай кулларын
болгый миңа;
Диде: «Ничек син йоклыйсың
мин йөзгәндә?
Чык монда, күк йөзенә минем
белән йөзәргә!»

Ни булыр иртәгә?

Ни булыр иртәгә, кем белә?!
Йөрәк әрни үткән көнләргә!
Көннән-көн өмет белән үтә –
Әйтегез миңа: ни булыр иртәгә?
1966



Әхмәд Гәрәй «Ниләр, ниләр… тагы да ниләр?!». Нью-Йорк, 1963 ел

Шигырьләрне журналга филология фәннәре докторы, профессор ***Хатыйп Миңнегулов*** *әзерләде.* ■

---

[2] Һомер (Гомер) – миладидан 850 еллар әүвәл яшәгән үзе карт, үзе фәкыйрь, үзе сукыр – дөньяның иң беренче шагыйре.
[3] Meteor – метеор.

Безнең мирас №8 август 2020

Муса Җәлил китапханәсендә автографлы китаплар

Назирә Фәттахова, Ләйсән Харасова

Бер төркем татар язучылары «Васильево» ял йортында.
Беренче рәттә (сулдан уңга): Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Муса Җәлил, Әхмәт Фәйзи;
икенче рәттә: Әхмәт Исхак, Шәйхи Маннур. 1940 елның июне

Шәхеснең рухи үсешенә китапның йогынтысы зур булуын күрсәткән мисалларны тарих яхшы белә. Китап укуга мәхәббәт һәм аның кеше тормышындагы әһәмияте турында күп кенә язучылар яза: А.П.Чехов, М.Горький, Л.Н.Толстой, шул исәптән татар әдипләре дә. Габдулла Тукайның «Китап» шигырендә мондый юллар бар:

Һич тә күңлем ачылмаслык эчем пошса,
Үз-үземне күрәлмичә, рухым төшсә,
Җәфа чиксәм, йөдәп бетсәм, бу башымны
Куялмыйча җанга җылы һичбер төшкә;
Хәсрәт соңра хәсрәт килеп алмаш-алмаш,
Күңелсез уй белән тәмам әйләнсә баш,
Күзләремдә кибеп тә җитмәгән булса
Хәзер генә сыгълып-сыгълып елаган яшь,
Шул вакытта мин кулыма китап алам,
Аның изге сәхифәләрен актарам;
Рәхәтләнеп китә шунда җаным-тәнем,
Шуннан гына дәртләремә дәрман табам...

Шуңа күрә күп кенә язучыларның китапларга мәхәббәте шәхси китапханәләр булдыруга сәбәп була. Танылган татар шагыйре Муса Җәлил балачактан үз китапханәсе турында хыяллана, әмма мондый мөмкинлек бары тик Мәскәү чорында гына (1927-1938) барлыкка килә. Башка китап тупланмалары кебек үк, аның китапханәсе дә үз хуҗасының мәнфәгатьләрен һәм кызыксынуларын тулысынча чагылдыра. Ул 1882 елдан алып 1941 елга кадәр басылып чыккан китапларны үз эченә ала.

Муса Җәлилнең музей-фатиры экспозициясенә 1983 елның 15 февраленнән башлап, вакытлы басмалар белән бергә, 216 китап куелган. Шуларның 158е – кириллицада, 57се – латин, 4се гарәп шрифты белән басылган. Китапларның күбрәк булуы мәгълүм, бу – шагыйрь үзе алып барган исемлектән билгеле. Китапханә рус һәм татар телләрендәге 400гә якын китапны үз эченә алган, алар арасында украин (Тарас Шевченконың «Кобзар» (1939)) һәм башкорт телләрендә берәр китап бар (Һәдия Дәүләтшина «Хикәяләр җыентыгы» (1935)).

Музей фондына герой-шагыйрьнең шәхси китапханәсе хатыны Нина Константин кызы Сәйфуллинадан (1913-2006) керә. Анда татар классик язучыларының – Г.Камал, Дәрдемәнд, Г.Тукай, замандашлары һәм якын дусларының китаплары тупланган.

«

Китапханәдә Муса Җәлилгә 1925-1941 еллар аралыгында автографлар белән бүләк ителгән 25 китап бар, шуларның 24е – татар язучыларының автографлары белән, берсе рус телендә язылган.

Китапханәдә Муса Җәлилгә 1925-1941 нче еллар аралыгында автографлар белән бүләк ителгән 25 китап бар, шуларның 24е – татар язучыларының автографлары белән, берсе рус телендә язылган (Семен Олендер «Яңа ел»). Туган телдәге автографлар китап бүләк иткән вакытка гамәлдә булган графика белән язылган – гарәп, яңалиф (латин графикасы нигезендә татар алфавиты), кириллица.

Дата буенча фикер йөрткәндә, автографлы беренче китап Мусага 1925 елда бүләк ителгән. Бу – Галимҗан Ибраһимовның 1924 елда Мәскәүдә нәшер ителгән «Пролетар әдәбият турында» җыентыгы. М.Җәлил Г.Ибраһимов иҗатына гашыйк була, аның «Тирән тамырлар», «Кызыл чәчәкләр» әсәрләрен укый, шигърият, әдәбият турында җәмәгатьчелек алдында ясаган чыгышларын тыңлый. 1922 елда, Казанга килгәч, Җәлил «Кызыл Татарстан» («Совет Татарстаны», «Социалистик Татарстан», хәзер «Ватаным Татарстан») газетасы редакциясенә эшкә урнаша. Партия өлкә комитеты кушуы буенча, Г.Ибраһимов бу газетага шефлык итә, яшь язучыларның иҗатын даими күзәтеп бара, яшьләр, аның белән берничә тапкыр очрашып, файдалы киңәшләр алалар.

1928 елның икенче яртысында Муса Җәлил Кырымда, Севастополь янындагы Балаклавада Мәскәү студентларының ял йортын юллама ала һәм үзенең курсташы, удмурт шагыйре Аркадий Клабуков белән Г.Ибраһимов янына бара. Севастопольдән Ялтага 80 чакрымны җәяү үтеп, алар шул елларда биредә яшәгән язучы янына киләләр. Гөлсем Даут кызы Мөхәммәдова (СССР Язучылар берлеге әгъзасы, биология фәннәре кандидаты, табиб, Г.Ибраһимовның тормыш юлдашы) истәлекләреннән: «Г.Ибраһимовны совет хакимияте шартларында татар, удмурт һәм башка милләт вәкилләре арасыннан яшьләрнең университетта укуы бик сөендерде. Алар киткәннән соң, Г.Ибраһимов: «Татарстан» газетасының эшчеләр төркемендә Муса иң актив хәбәрче иде, «Көрәш җырлары» җыентыгында (1923) аның шигырьләре басылды, алар миңа бик ошады,


MƏKTƏP SERIƏSE

Ş. MANNUR

QAZAN UTLARЬ

ŞIGЬRLƏR ÇЬNЬLЬŞЬ

TATGOSIZDAT
MATUR ƏDƏBIAT SEKTORЬ
QAZAN 1939


ƏXMƏT FƏJZI

EZLƏR

TATGOSIZDAT
Matur Ədəbiat Sektorь
Qazan 1939


ŞAMIL GƏRƏJ

ZVENO ÇЬRЬ

ŞIGЬRLƏR HƏM ÇЬRLAR

TATGOSIZDAT
JƏŞLƏR-BALALAR ƏDƏBIATЬ SEKTORЬ
QAZAN
1934


Ƣ. XUÇI

JƏŞLEK TAVЬŞЬ

TATGOSIZDAT
JƏŞLƏR-BALALAR ƏDƏBIATЬ SEKTORЬ
QAZAN 1938

һәм мин аңа үземнең «Пролетар әдәбият турында» китабымны автограф белән бүләк иттем», – дип искә алды».

Г.Ибраһимов белән очрашу турында Муса Җәлил якын дусты Мәхмүд Максудка сөйли, Галимҗан ага белән әңгәмә әдәбиятның җитди проблемалары турында барды, дип билгеләп үтә.

1930 нчы еллардагы автографлы китаплар күбесенчә латин графикасы белән язылган һәм, нигездә, бу – шагыйрьнең замандашларының җыентыклары. Алар арасында Әхмәт Фәйзинең – өч, Әхмәт Ерикәйнең ике китабы бар. Икесе дә Муса Җәлилнең «Мәскәү дуслары».

Замандашларының китаплары арасында Фатих Кәримнең «Яшен яктысы» (1934), С.Хәкимнең Г.Тукайга багышланган «Пар ат» (1939), «Шагыйрьнең балачагы» (1940), Ш.Маннурның «Казан утлары» (1939) җыентыклары бар. Арада яшь шагыйрьләрнеке дә очрый, алар Муса Җәлилне остазлары дип санаганнар. Мәсәлән, Мөхәммәт Садриның «Совет Ватаны өчен» (1939) җыентыгы.

Муса Җәлил бу яшь шагыйрьнең иҗаты турында җылы сүзләр белән искә алган. Нәкъ менә Җәлил эшче хәбәрче Мөхәммәт Садрины шигърият дөньясына җәлеп итә. Шагыйрь Мәскәүдә Театр сәнгате институтында укыганда М.Җәлил белән еш аралашкан, аннан ярдәм алган. Җәлил аны «Коммунист» газетасына штаттан тыш хәбәрче итеп эшкә тарткан, журналистлык осталыгына өйрәткән. 1940 елның 15 февралендә язылган характеристикада мондый юллар бар: «Мөхәммәт Садри – татар совет шигъриятенә производство аркылы килгән шагыйрь. Ул – үз шигъри тавышы булган яшь шагыйрьләрнең берсе».

М.Садри соңрак Муса Җәлилнең яшьләр остазы булуын, аның кулы аша күп кенә яшь язучылар узуын ассызыклаган. Гали Хуҗи юкка гына: «Муса! Ярдәмең өчен чын йөрәктән рәхмәт! 8.04.41», – дип язмагандыр.

Шагыйрь Шамил Гәрәйнең «Звено җыры» (1934) китабында Муса Җәлилгә «Балалар әдәбияты атасы» дип мөрәҗәгать итүе очраклы түгелдер. Муса Җәлил 1920-1930 нчы елларда Мәскәүдә балалар өчен чыккан «Кечкенә иптәшләр», «Октябрь баласы» журналларында редактор була, үзе дә әлеге журнал битләрендә басылып килә.

Шагыйрьнең китапханәсендә автографы рус телендә булган бердәнбер китап – Семен Олендерның «Совет язучысы» типографиясендә 1935 елда нәшер ителгән «Яңа ел» җыентыгы. Автограф М.Җәлилнең хатынына да адресланган. Күрәсең, Олендер Нина Константин кызы Сәйфуллина белән дә таныш булгандыр.

Автографлар буенча Җәлилнең күп кенә яшь шагыйрьләр һәм прозаиклар белән дустанә элемтәләре булуы күренә. Бу турыда «Муса дуска» яки «Муса дус» дип язылган автографлар сөйли. Аларның кайберләре шагыйрьгә рәхмәт сүзләре белән язылган, замандашларының истәлекләре буенча, ул барысына да ярдәм итәргә тырышкан. А.Шамов истәлекләреннән: «Җәлилнең нинди сыйфатлары мине барыннан да бигрәк таң калдырды? Намус һәм гаделлек. Ул чорда авыр вакытлар булды, барысы да җитмәде. Язучылар берлегенә азык-төлек, кием-салым, тукымалар бүлү кебек үзенә хас булмаган эшләр белән шөгыльләнергә туры килә иде. Муса, барыннан да элек, мохтаҗ булган кешеләрне тәэмин итәргә тырышты».

Бүләк ителгән китапларның составы Җәлилнең профессиональ һәм иҗтимагый эшчәнлеген чагылдыра, адресат һәм бүләк итүчеләр арасындагы эшлекле һәм дустанә элемтәләрне раслый. Китаплардагы автографлар билгеле бер рәвештә социаль мохит һәм чорны тасвирлый, алар җәмгыятьтә үз китапларыңны хезмәттәшләреңә бүләк итүнең киң таралуын, иҗади бәйләнешләрнең күптөрлелеген, М.Җәлилнең әдәби мохиттәге урынын күрсәтә. ■

Сиринне фаҗигагә этәргән әсәр

Әнвәр Шәрипов, филология фәннәре докторы



Шагыйрь Сириннең кабер ташы. Баулы

Узган гасырның утызынчы еллары – шагыйрь Сирин иҗатының иң үскән, иң нәтиҗәле һәм киң популярлык казанган чоры. Бу елларда ул үзенең бөтен талант куәсен җигеп, киң колач белән иҗат итә, трибун шагыйрь булып таныла, классик рус һәм дөнья поэзиясен өйрәнә. Владимир Маяковскийга ияреп, «Идәнгә төкермәгез!» (1928), Кытай шагыйре Ши-Кингтан алып, «Кытай җыры» (1928), Шекспирдан алып, «Алтын металл» (1933), гарәп шагыйре Әбел-Галә әл-Мәгарридән алып, «Гаҗәпләнү» (1933), «Сәлманың урынына» (1936), француз шагыйре Пьер Беранжега ияреп, «Аучылар», «Син бит Гөлсем түгелсең» (1933) шигырьләрен, «Гейне фикере» (1929), «Лермонтовтан хат» (1933), «Пушкиннан бер өзек» (1934), Сергей Есенинга ияреп, «Зәңгәр кичтә», «Алсу кофта, зәңгәр күзләр» (1934) кебек әсәрләрен иҗат итә. Сириннең каләме очыннан шул елларда киң яңгыраш алган «Минем трагедиям», «Булмый! Булмый!», «Киләләр» һәм башка дистәләгән шигырьләр кәгазьгә төшә. 1930 елда ул үзенең шактый зур күләмле «Тамчылар» исемле шигъри җыентыгын бастыра. Балалар өчен «Кыш», «Яз», «Җәй» һәм «Көз» (1929) исемле, аннан «Кеше» (1930), «Бә-ә-ә дә мә-ә-ә» (1931), «Тимер юл» (1931), «Трамвайлар ник туктаган?» (1932), «Җиләк бакчасы» (1933) кебек китаплар чыгара. Сириннең әсәрләре «Көрәш җырлары» (1923), «Октябрьнең ун еллыгына безнең бүләк» (1927), «Төзү көннәрендә» (1929), «Безнең яшьлек» (1934) кебек күмәк мәҗмугаларда һәм альманахларда басыла. Шагыйрь шулай ук тәрҗемә белән дә актив шөгыльләнә.

Сирин әдәбиятка 1920 нче елларда яшьлек ялкыны, революцион пафослы шигырьләре белән килеп керә. Аның бу чор иҗаты коммунистлар партиясе идеяләренә чын күңелдән бирелгәнлек, Октябрь инкыйлабыннан соң яңа, матур,

гадел җәмгыять төзүгә тирән ышаныч белән сугарылган. Шагыйрьнең гражданнар сугышы темасына багышланган әсәрләре ул елларда гаять популяр була. Әмма вакыт уза тора һәм тышкы яктан кызыл лозунглар белән бизәлгән совет системасының эчендә, асылында мәкер, алдашу, байлык артыннан куу ятканлыгы ачыклана. Сириннең хөрлек, ирек сөюче бунтарь җаны моның белән, әлбәттә, килешә алмый һәм бер-бер артлы совет идеологиясенең чын йөзен ача торган әсәрләре туа башлый.

Журналда тәкъдим ителәчәк «Ана» поэмасы – шагыйрьне репрессияләүгә сәбәпче булган әсәрләрнең берсе. Сирин аны 1934 елда язган.

Поэманың тулы тексты безгә билгеле түгел, бары НКВД архивында сакланган версиясе генә мәгълүм. Әсәрнең исеменнән соң ук «1931 елда кулак итеп авылыннан куылган бер ананың Казан урамында үз малае белән очрашуы» дигән аңлатма бирелә.

Сталинның «Социализм җиңә барган саен җәмгыятьтә сыйнфый көрәш тә кискенләшә бара» дигән күрсәтмәсенең кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә ничек чагылуы, нинди каршылык-фаҗигаләр китереп чыгаруы тасвирлана бу поэмада. Унөч бала тәрбияләп үстергән һәм аларның барысын да туган оядан «очырып җибәргән» ананы, ике-өч сыер асрауда гаепләп, кулак, дип, өеннән куып чыгаралар, барлык мал-мөлкәтен тартып алалар, ахыр чиктә ул шәһәр урамында хәер сорашыр көнгә кала. Ана белән бала, сәяси каршылыклар аркасында, ике капма-каршы лагерьга тарый.

Вакыйга лирик герой – ананың улы исеменнән сөйләнә:

Бераз барсам,
Тагын юл өстендә
Кулын сузган минем үз анам.
Күкрәгенә кыскан яшь баласын:
«Кызган мине, кызган, – ди, – әй, балам!
Унөч бала бергәләп үстегез,
Көн-төн эшләп, еллар үттеләр.
Сезнең эшләп тапкан малыгыз өчен
Бүген мине кулак иттеләр...»

Ана үзенең улыннан мәрхәмәт сорый. «Әтиегез вафат булды, үлеп котылды», – ди. Үзен ничек итеп кулак «ясауларын» сөйли. Ананың сүзләрендә шул чордагы курку атмосферасы искиткеч реаль чагылыш таба.

Әмма революция идеяләренә нык бирелгән улы... хәер, барысын да үзегез укып белерсез.

Йомгаклап әйткәндә, «Ана» поэмасы укучыга 1930 нчы еллардагы сыйнфый көрәшне, ул көрәшнең никадәр рәхимсез, кешелексез булуын ачып сала. Татар поэзиясе тарихында әлеге рәхимсезлекне шулкадәр тирәнлек һәм ачыклык белән сурәтләп биргән башка әсәр юк шикелле.

Совет системасын тәнкыйтьләгән әсәрләре өчен, шагыйрь Сиринне 1935 елда кулга алалар, «халык дошманы» исеме тагып, биш елга «Сиблаг»ка озаталар. Кеше ышанмаслык газап-кимсетелүләр белән тулы сөрген срогын тутырып, 1957 елда реабилитацияләнүенә карамастан, аның иҗаты озак еллар буе күләгәдә кала. Ул ирекккә чыккач та каләмен ташламый, төрле темаларга туксаннан артык шигырь һәм әкиятләр яза.

Сириннең кабатланмас иҗаты XX гасыр татар поэзиясендә якты бер сәхифә булып тора. ■

Ана

(Поэма)

Сирин

Бер минутта ялгыш кына
Эшләнгән бер хатаны,
Бик күп еллар узса да,
Төзәтеп булмый аны.
Кала ул тик музыкада
Эчтән янып көйләргә.
Кала ул күп буыннарга
Әкият итеп сөйләргә.

Мин һәр көнне
Шушы урамнан узып барам;
Узган саен
Шунда торган бер бала,
Узган саен
Миңа кулын сузып кала.
Узган саен
Миңа кайгы, ут сала.
Үз-үземне көчлим,
Булдыра алмыйм,
Газапланам – каты бәрелсәм.
Ачуланма, бала, мин – шәфкатьсез,
Мин гаепле – белми жәлләсәм.
Кем белә бит, бәлки, таныкламаң –
«Кулак баласы» дип язылган.
Алай булса бетте,
Якын килмә –
Синең яшәү хакың алынган.
Бәлки, мәктәптән качканың,
Бәлки, усал,
Бәлки, ат урлаган бер бала.
Бәлки, тормыш шуңа көчләгәндер,
Әллә, белмим...
Үзең теләп шундый шпана...
Ник дөньяга туып җитмәс борын
Яшәү праваңны югалттың?
Бала булып, бала шатлыгың юк,
Шатлыгыңны кайда,
Кемгә... саттың?
Үз-үземне көчлим,
Булдыра алмыйм,
Газапланам, каты бәрелсәм...
Ачуланма, бала,
Мин – шәфкатьсез,
Мин гаепле – белми жәлләсәм.

Бераз барсам,
Тагын юл өстендә
Кулын сузган минем үз анам.
Күкрәгенә кыскан яшь баласын:
«Кызган мине, кызган, – ди, – әй, балам!
Унөч бала бергәләп үстегез,
Көн-төн эшләп еллар үттеләр.
Сезнең эшләп тапкан малыгыз өчен
Бүген мине кулак иттеләр.

Әтиегез, мескен, бәхилләшеп,
Дөнья куйды, күптән онытылды.
Күрер иде ул да күрәчәген,
Мәрхүм булды, үлеп котылды.
Бер сыерым бер көн ике булды,
Һәр бозавын карап үстердем.
Ике-өч елдан ике-өч сыер булды,
Шул сыерлар кулак ителде.
Мин үзем дә сөйләп бирә алмадым,
Башкалар да эчтән тындылар.
Кем дә булса берәү яклап әйтсә,
«Кулак ялчысы» дип кудылар.
Үз-үзеннән куркып, һәрбер кеше
Кырын карый, белмим нишләргә.
Шул куркулар бозды бөтен эшне,
Юк ярдәмчем киңәш итәргә.
Бәхетемне җуйдым, кызганмадым,
Күкрәк сөтемне мин имездем.
Озын төннәрне күз йоммадым,
Җил-яңгырдан саклап үстердем.
Үз-үземне көчләп суя алмадым,
Килеп бастым урам чатына.
Кызган, бала, мин сиңа ана бит,
Шул аналык хисләре хакына!»

Үз-үземне көчлим,
Булдыра алмыйм,
Газапланам, каты бәрелсәм.
Ачуланма, анам, мин – шәфкатьсез,
Мин гаепле – шәфкать ит, дисәм.
Мине табып, мине үстерсәң дә,
Бик күп кыйналулар күрсәң дә,
Мин болай ук ярдәм күрсәтәлмим,
Ярдәм сорап миңа килсәң дә.
Син «милекче», ана, һәр сүзеңдә
«Вак милек»не сөеп яклыйсың.
Яшьләр коеп, урам чатларында
«Вак буржуа хисе» саклыйсың.
Бер кулак печате басылгач,
Үз анам дип сине якласам,
Нәрсә булыр сыйнфый көрәштән
«Кода-кодагыйлык» ясасам?..
Без икебез – ике фронтта,
Канлы кинжал тора арада.
Их, шәфкатьле анам! Сыйнфый көрәш...
Мәрхәмәт юк «дошман анага»!

Сулыш кызды ана башында,
Шәфкать үлде, шатлык югалды.
Ачу белән уйлар томаланды,
Күз аллары ямьсез, караңгы.
Өерләнеп утлар бөтерелде,
Өмет яраланды, шул ара –
Күңеле туңды, күздән яшьләр китте,
Ачу белән диде карт ана:
«Мин алайса дошманнар үстердем,
Киләчәкне алдан белмәдем...
Ник үстердем сез унөч баланы,
Корсакта чак ник үтермәдем?..
Ник имезәм тагын бу соңгысын?
Дошман булыр, аны үстерсәм...
Ул ашыйсын үзем ашармын,
Беркем белмәс, буып үтерсәм...»

Шәфкатьле, киң, йомшак ана күңеле
Тагын туңды, тагын эреде,
Тагын май күк йомшап китте,
Тәндә вак-вак энәләр йөгерде.
Тагын тирән уйга талды –
Ниләр күрми бала анасы!
Кинәт күреп, шашып калды, –
Кулда үлгән имчәк баласы...

Их, син тормыш!
Ник соң болай?!.
Хисләр белән сәүдә итәсең,
Бала – ана, туганлык хисләрен
Үтмәс кайчы белән кисәсең?..
Күкрәк сөте белән үз гомерендә
Унөч солдат биргән бер ана
Шәфкать эзли көрәш мәйданында,
Яшь баласын кочып җиргә ава.
Катып торам үз әнием янында...
Мин гаепле...
Мин гаепле диктатура алдында...
Мин гаепле – шәфкать ит, дисәм...

1934 ел ■

Безнең мирас №8 август 2020

Тимердән дуга бөгәләр...

(Хикәя)

Туфан Миңнуллин



Т. Миңнуллин:
«Безнең авылга берәр кадерле кунак килсә яки кайтса, шул уңай белән табын корылса, берәвесе яңа өй җиткереп, йә өйләнеп, йә кияүгә чыгып, туй-мазар уздырылса, бәйрәм-сәйрән араларында берәрсендә мәҗлес оешса, Бәрттинне чакырмыйча калмыйлар иде...»

Безнең авылга берәр кадерле кунак килсә яки кайтса, шул уңай белән табын корылса, берәвесе яңа өй җиткереп, йә өйләнеп, йә кияүгә чыгып, туй-мазар уздырылса, бәйрәм-сәйрән араларында берәрсендә мәҗлес оешса, Бәрттинне чакырмыйча калмыйлар иде. Бәрттин, дип әйтеп ялгышлык, мәгънәсезлек кылдым, гафу итегез. Чөнки ул минем өчен Бәдретдин абзый булырга тиеш. Мин авылдан чыгып киткәндә, аңа алтмыш биш яшьләр чамасы булгандыр. Әмма авылда, ни өчендер, Бәдретдин абзыйга «абзый» дип эндәшмиләр иде. Бала-чагасына хәтле Бәрттин дигән була иде. Шунысын әйтергә кирәк: абзый димәгәнгә ул үзе дә үпкәләми иде. Чөнки абзый димәсәләр дә, Бәдретдин абзыйга тиле-миле итеп, түбәнсетеп, көлеп-мыскыллап карамадылар. Ничектер шулай киткән инде – Бәрттин дә Бәрттин. Тумачиәнинең әйтүенә караганда, Бәдретдин абзыйның төс-кыяфәте унбиш яшеннән башлап кырык яшенә хәтле үзгәрмәгән. Кырыктан узгач кына картаебрак киткән ул. «Әүвәле малай булды, аннары бабай булды, самайлыкка керми дә калды», – ди иде тумачиәни. Буй-сынга да әллә ни түгел иде Бәдретдин абзый. Җыйнак гәүдәле, җиңел сөякле кеше иде. Бәдретдин абзый кыстатып тормый, скрипкәсен култык

астына кыстыра да мәҗлескә кунаклар җыйналганчы ук килеп җитә. Аңа урынны түрдән бирәләр. Билгеләнгән урынга утыргач, Бәдретдин абзый, үзе ясаган такта тартмадан скрипкәсен, смычокны, канифольне алып, ашыкмыйча гына скрипкәне көйли башлый – чината, җылата. «Баламишкин»ны уйнап җибәрә дә скрипкәне яңадан тартмасына салып куя. «Баламишкин» уйналса, скрипкә көйләнгән дигән сүз.

Кунаклар җыелып, мәҗлес ачылгач, бераз гына кабып алгач, җыр башлана. Башта гармунга йә баянга кушылып җырлыйлар.

Мәҗлескә гармунчылар да чакырыла һәм алар йөкнең иң авырын төпкә җигелеп тарталар. Бәдретдин абзый яннан гына юыртып бара. Ләкин барлык мактау, барлык матур сүзләр аңа эләгә. Гармунчылар үпкәләмиләр – күптәннән шулай кабул ителгән, шулай тиеш. Бәдретдин абзый бүтән чакта Бәрттин генә булса да, скрипкәсен кулына алгач, илаһи бер затка әверелә. Скрипкә Бәдретдин абзыйда уйныймы, Бәдретдин абзый скрипкәдә уйныймы – аера алмыйсың. Шунысын да әйтергә онытмыйк: Паганини скрипкасы дөньяда ничек данлыклы булса, Бәдретдин абзый скрипкәсе дә безнең авылда шундый ук данга ия иде. Әллә ничә ел уйнаса да, бер тапкыр да кәҗәләнгәне, шыңгырдаганы булмаган аның.

…Мәҗлес кызганнан-кыза бара. Җырны бию, биюне тагын җыр алыштыра, һәм, ниһаять, Бәдретдин абзый кулында – скрипкә. Мәҗлес тагын тынып кала. Гармунчылар гармун каешларын иңнәреннән салалар. Табын өстенә «Авыл көе» сибелә – беркем кушылмый, «Авыл көе»н, сиздермичә генә, «Шахта көе» алыштыра – беркем кушылмый. Кушылудан мәгънә юк, чөнки Бәдретдин абзый бу көйләрне үзенчә, бормалы-сырмалы итеп уйный – нинди генә оста җырчы булсаң да, иярә алырлык түгел.

Менә «Баламишкин». Менә «Сандугачым-гүзәлем»… Менә… Җырла, әйдә, күрсәт һөнәреңне! Монда инде Бәдретдин абзый синең карамакта. Ул синең җырыңны шундый итеп озатып бара, җырлый белмәвең дә, тавышың юклыгы да сизелми. Үз күз алдында үзең үсеп киткәндәй буласың, җырлап туймыйсың. Мәҗлес таралгач та, өеңә хәтле җырлап кайтасың, карчыгыңның, йокла инде, дип әрләвенә дә карамыйча, түшәк өстендә җырлап ятасың.

Биш-алты көй уйный да Бәдретдин абзый, скрипкәсен тартмага салып куя. Яңадан ул аны мәҗлес таралыр алдыннан гына ала. Кушылып җырларлык өч-дүрт көй уйнагач, «Авыл көе»нә, «Шахта көе»нә күчә. Мәҗлес тагын тынып кала. Бәдретдин абзый, уйный-уйный да, кинәт уйнавыннан туктап, җырлап җибәрә:

«Тимердән дуга бөгәләр
Кытай тимерчеләре...»

Җырлап җибәрә дигәч тә, көе юк ул җырның. Һәрхәлдә, тыңлаучылар аңларлык түгел. Моңсыз, тавышсыз кешенең иң моңлы көйне җырлап азапланганы сыман:

«Тимердән дуга бөгәләр
Кытай тимерчеләре...»

Шушы ике юлдан соң Бәдретдин, нәрсәнедер хәтеренә төшерергә тырышкандай уйланып тора да, тиз генә скрипкәсен тартмасына салып, саубуллашмыйча кайтып китә иде.

Мәҗлес рәхәтләнеп көлеп озата иде аны. Чөнки җыелган кунаклар Бәрттиннең шулай эшләячәген белеп, көтеп торалар. Ул инде ничәмә-ничә кабатланган. Барысы да Бәрттин кунакларның кәефен күрү, көлдерү өчен мәзәк ясый дип уйлыйлар иде.

Чынында исә…

Күптән инде, бик күптән, унсигез яшьлек чагында Мәфруза исемле кызны яраткан Бәдретдин. Аның ратканын кыз белмәгән. Хәер, белсә дә, Бәдретдингә карамаган булыр иде, кирәгеннән артык чибәр булган ул. Зифа буйлы, кара

кашлы, кара күзле, пешкән, ярмалы бәрәңге төсле ап-ак йөзле һәм башкалар… Әкиятләрдә сөйләнгәнчә, койган да куйган хан кызы. Ә Бәдретдин кем? Үзенең тиңдәшләре арасында кыяр-кыймас кына буталып йөрүче кәтәнә генә бер малай. Атасыннан калган скрипкәдә өздереп уйнаган уйнавын: кышкы кичләрдә аулак өйләрдә, җәен су буендагы уеннарда Мәфруза шул скрипкәгә кушылып та җырлаган, әмма андый гүзәлнең мәхәббәтенә тиң булыр өчен ул гына җитмәгән, күрәсең.

Бәдретдин Мәфрузаның үзенә карамаганын бик яхшы белгән һәм гомердә карамаячагын да тойган, шуңа күрә ул зурга өметләнмәгән: Мәфрузаны күреп торса, аның тавышын ишетсә, аңа шул җиткән. Тик йөрәк дигәнең үзенекен кылана, күңелнең кайсыдыр бер почмагында, бәлки, бәлки, дигән өмет тә пыскып ята. Кабынып китәр иде Бәдретдин, кабынып китүеннән куркып, ул өметне сүндерә торган, сүндерә торган. Чөнки сизгән ул: бер көн киләчәк – Мәфруза, җан сөйгәнен очратып, күңелен мәңгелеккә шуңа салачак, гомерен шуңа бәйләячәк, аулак өйләргә йөрми, су буена төшми башлаячак. Менә шул көннең киләчәген сизүләре авыр булган Бәдретдингә. Килмәсен иде бу көн. Бәдретдингә күз салмаса да, бүтәннеке дә булмасын иде Мәфруза.

Әмма килеп җиткән бу көн. Бәдретдин белмичә дә калган.

Күрше авылның шахтадан кайткан Исхак исемле егетенә кияүгә чыга икән Мәфруза, дигән хәбәрне генә ишеткән.

Озакламыйча туйлары да булачак икән. Егет өйләнеп китәргә генә кайткан. Мәфрузаның әтисе Гариф абый яшь чагында зимагурлыкта йөреп шомарган һәм хәзер дә авылдан чыгып качарга җай көтеп йөргән кеше – кызын шахтерга бирергә риза булган. Өстәвенә, егет кызны бер күрүдә үк ошаткан, кызга да егет ошаган һәм вәссәлам: өч көннән соң – туй.

Туй табыны ашык-пошык әзерләнсә дә, зимагурларча бай булган, Мәфрузаның әтисе бар булганын бердәнбер кызының туй табынына куйган. Бүген гөрләтеп, дөбердәтеп туй итик, янәсе, иртәгесе өчен эт кайгырсын. Сыер сатылса ни дә, сарык-тавык суелса ни: ул барыбер йорт-җирен туздырып, хатынын ияртеп, киявенә тагылып, Донбасс ягына китәчәк.

Туйның кызык булачагы, әлегә хәтлеге башка туйларга охшамаячагы алдан ук билгеле булган. Кыз белән егеткә мулла-мазардан никах укытып тормаганнар.

– Гамәлдән чыккан муллага ничу акча түләргә, аңа биргәнче, бер чирек аракыны артыграк алам мин, – дигән Гариф абзый.

Һәм аракыны, чыннан да, мул итеп алган. Авыл кешеләре аның бу эшен өнәп тә бетермәгәннәр. Ул чакта аракы модада булмаган әле, бер тустаган бал эчеп, төн буе җырлап, күңел ачып утыра торган чак булган, исергән кешегә мыскыллап, җирәнеп караган чак булган.

Туйга Бәдретдин дә чакырылган. Гариф абзый үзе килеп чакырган аны.

– Каз муенында уйнаганыңны тыңлап торганым бар, атаң сыман килештерәсең. Килми калма, урының түрдә булыр. Шәп итеп уйна, кодаларның күзләре дүрт булсын, күрсеннәр Гарифның кем икәнен! – дигән.

Әгәр дә бүтән берәүнең туена чакырсалар, очынып куанган булыр иде Бәдретдин, үзен кешегә санап, түрдән урын тәкъдим итүчегә рәхмәтләр укыган булыр иде. Бу бит Мәфруза туе. Аны Бәдретдиннән мәңгегә аера торган, пыскып янган өметне мәңгелеккә сүндерә торган туй.

Барыргамы, бармаскамы дип икеләнгәннән соң, Бәдретдин туйга барырга булган. Мәфрузаны җылап озатканчы, уйнап озатырга дип санагандыр, күрәсең. Әгәр җыларга кирәк икән, скрипкә җыласын, скрипкә өзгәләнсен.

Туйның ничек башланып киткәнен дә, ничек дәвам иткәнен дә Бәдретдин хәтерләмәгән. Уйнаган да уйнаган ул. Нинди көйләр уйнаганын да белештермичә уйнаган. Томан, томан... Мәфруза шул томан эченә кереп югалган, юкка чыккан.

Исхак белән бергә Донбасс якларыннан кайткан кодаларның берсе җырлап җибәргәч кенә айнып киткән Бәдретдин. Авылда әлегә хәтле ишетелмәгән җыр булган ул. Әллә нинди ят, сәер җыр. Бәдретдин, скрипкә кылларыннан смычокны да алмыйча, онытылып тыңлаган ул җырны. Башка чак булса, Бәдретдин яңа көйне отып алган булыр иде, андыйга маһирлыгы зур аның. Бу юлы ул тыңлаган гына.

Җырлаучы, җырлап туктагач, ни өчендер, кычкырып көлгән дә, стаканына тутырып аракы коеп, эчеп җибәргән. Бәдретдин алдында да аракы салынган стакан тора икән. Ул мәҗлес буе аңа кагылып та карамаган. Кода эчеп куйгач, егет, үзе дә сизмәстән, кулына стаканын алган һәм гомерендә беренче тапкыр аракы эчкән. Эчкән дә – исергән дә. Мәлҗерәп төшкән Бәдретдинне скрипкәсе-ние белән өенә илтеп салганнар. Ике көн чирләп яткан Бәдретдин. Адәм рәтенә килеп, урамга чыкканда, Мәфруза ире белән Донбасс якларына китеп тә барган булган.

> **«**
> **һәм аракыны, чыннан да, мул итеп алган. Авыл кешеләре аның бу эшен өнәп тә бетермәгәннәр. Ул чакта аракы модада булмаган әле, бер тустаган бал эчеп, төн буе җырлап, күңел ачып утыра торган чак булган, исергән кешегә мыскыллап, җирәнеп караган чак булган.**

...Кичкырын капка төбендәге утыргычта моңаеп утырганда, Донбасстан кайткан коданың җырлавы Бәдретдиннең исенә төшкән. Нindирәк көйгә җырлады соң әле ул? Сүзләре ничек иде?

Тимердән дуга бөгәләр
Кытай тимерчеләре...

Ничаклы гына тырышса да, Бәдретдин көйне һәм җырның әлеге ике юлдан башка сүзләрен хәтеренә төшерә алмаган.

Озак эзләгән. Айлар, еллар буе, гомере буена эзләгән – көй дә, җырның сүзләре дә табылмаган...

Тимердән дуга бөгәләр
Кытай тимерчеләре...

Бары тик шул гына.

Мәҗлесләрдә, туйларда скрипкәдә уйнаганда, күңелгә килеп кергәндәй була ул көй, бәрелә-сугыла һәм, Бәдретдин аны тотып алам дигәндә генә, ычкына, тагын китеп адаша. Бәдретдин тагын эзләргә тотына. Көйне алдап китерер өчен, җырның ике юлын кычкырып җырлап җибәрә:

«Тимердән дуга бөгәләр
Кытай тимерчеләре...»

Юк, көй инде әллә кая китеп өлгерә. Җырның соңгы ике юлын Бәдретдин белсә-хәтерләсә, бәлки, көй әйләнеп тә килер иде, ләкин бары тик ике генә юл күңелгә сеңеп калган. Ике генә юл:

Тимердән дуга бөгәләр
Кытай тимерчеләре...

1978 ■

Безнең мирас №8 август 2020

ХАТИРӘ

«Авылыңны чынлап яратсаң...»

Ләбиб Лерон

Илдус Гыйләҗев (уңда) каләмдәшләре Ирек Бәдретдинов һәм Нур Әхмәдиев белән. 1990 нчы еллар

Шагыйрь Илдус Гыйләҗев – авылдан әдәбиятка килгән һәм, гомер буе авылда яшәп, шунда тир түгеп эшләп, иҗат итеп, олуг Әдәбиятта тирән эз калдырган әдипләребезнең берсе.

Шагыйрьнең тәүге җыентыгы «Җир китабы» дип атала. Бу тикмәгә түгел. Китап авторы – чын мәгънәсендә Җир кешесе!

«Кеше өчен ана белән
Җирдән якын нәрсә бар соң?
Күңелем очкан чакларда да
Аякларым җирдән барсын», – дип яза Шагыйрь.

Без алда телгә алган җыентыгындагы икенче бер шигырендә ул Җиргә мөнәсәбәтен болай белдерә:

«Шигырьләрне бит мин Җиргә язам,
Сездән бары шул аермам.
Үзем корган һәр йорт – яңа куплет,
Яңа урам – яңа поэмам!..»

Әлеге китапка кереш сүзне Шагыйрьнең укытучысы, остазы, мәшһүребез Мөхәммәт Мәһдиев язган. 1988 елның июнендә куелган шул сүз башыннан Илдус Гыйләҗевкә нисбәтле бер өземтә: *«Илдус Гыйләҗевнең әдәбиятка киләсен мин моннан күп еллар элек сизенгән идем. Университетта укыган елларында ул сәхнәне ярата, җыр, гармун белән әвәрә килеп яши иде. Бераздан мин аны хәрби формада*

очраткаладым. Лейтенант погоннары таккан бу егет белән татар әдәбияты, сәнгате турында сөйләшә идек. Шинель, фуражка киеп, погоннар таккач та, татарча сөйләшеп була икән, чын менә!..

Йә, шундый кеше әдәбиятка килми каламы инде?!

Ул бит җирдә, «мин колхоз председателе», дип, «барысын да мин хәл итәм», дип, күкрәк киереп, команда биреп йөрми, җирне, кешеләрнең йөрәген тоеп, җирдән, кешеләрдән илһам алып яши.

Аның шигырьләрен укып карагыз, сез анда буш лозунглар, пафослы җөмләләр күрмәссез, аларда сез шушы җирнең моңын, җылысын тоярсыз. Шул җирне бизәүче хезмәт кешесенең сулышын тоярсыз. Бу китапка сүз башын мин шуңа күрә «Җир турында җыр» дип исемләдем».

Җир турында җыр... Җир китабы...

Безнең күбебез – авылдан китүчеләр, кабат туган җиргә кайтып төпләнә алмаучылар. Ә Ул кайтты, авылын сагынып кайтты:

«Әйе, кайттым, әйе, түзәлмадым!
Чыдап булмый, җиргә табынсаң.
Бака тавышы да якын икән,
Авылыңны чынлап сагынсаң...»

Галиҗәнап Авылга, Туган Төбәккә чын мәгънәсендә гомерләре буе дан җырлаган ике әдипнең исемен хәтердә яңартмый мөмкин түгел. Алар – остаз һәм Шәкерт – Мөхәммәт Мәһдиев һәм Илдус Гыйләҗев.

Бүген сүзем, инде аңлашылганча, Илдус абый хакында булыр.

Аның белән кайчан, ничек танышканымны инде хәтерләмим дә. Әмма соңгы елларда еш аралаштык, еш очраштык кебек.

2014 елда «Безнең мирас»ның баш редакторы вазыйфасын башкара башлагач, Азнакайга юлым еш төшеп, Шагыйрьнең Туйкәдәге йортында күп кунгаларга туры килде. Кайвакыт, алдан шылтыратып, берәр юлдашым белән кичләтә килә идек. Ул, билгеле, бөтен шартын китереп, табынын әзерләп, мунчасын ягып, безне түземсезләнеп көтеп торыр иде. Янында нәни дәвамчысы – оныгы Камил булыр иде.

Табын яныннан кузгалып, эссе мунчадан сихәтләнеп чыккач, Илдус абыйның эш (иҗат) бүлмәсенә кереп, җайлап-җайлашып утырабыз һәм... рәхәтләнеп шигырь тыңлыйбыз. Башта миннән берничә яңа шигырен укыта. Укыйм. Шигырьнең һәрберсе гап-гади, бик тә самими булып тоела миңа. Ә инде үзе укый башласа... Бөтенләй икенче төсмер ала, мәгънәсе, эчтәлеге башкача ачыла да китә. Хикмәт инде менә!

Туган көннәребез вакытында бер-беребезне таң атуга котларга тырыша идек. Бу да үзенә күрә бер кызыклы гамәл, аралашуның бер күркәм әмәле булган, күрәсең.

Миндә аның култамгалы байтак китабы саклана. Менә кайберләре: «Яратканга күрә» (Казан, 2006): «Ләбиб дуска, иҗади уңышлар теләп – Илдус. Март, 2006 ел»; «Күкрәгемә тургай оялады» (Казан, 2010): «Ләбиб дуска, ихтирам белән, Илдус. Июнь, 2011 ел». (Аның култамгасы янына минеке өстәлгән: «Сәяхәтче китап! Илдус абый Гыйләҗевнең ошбу китабы Белградта (Сербия) булды. Имза (Ләбиб Лерон). 12-18 сентябрь, 2011 ел»); «Үземә кил» (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2011): «Ләбибкә яңа көлке пародияләр өчен. Илдус абый. Март, 2011 ел»; «Назга сусау» (Казан, 2014): «Имин тормыш, иҗат шатлыклары теләп калам – Илдус абый. Февраль, 2015 ел»; «Ихлас тойгылар» (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2016): «Ләбибкә иң матур теләкләр белән – Илдус абый. Ноябрь, 2016 ел».

Илдус Гыйләҗев

Безнең максат

Иң бөек максат безем –
Хөр мәмләкәт, хөр Русия...
Габдулла Тукай

Кискән тырнагына тормасам да
Шигырь осталыгы буенча,
Мәшһүр Тукай бераз хаталанган
Бу урында, минем уемча.

Баскынчылык аша үскән илдә
Буламы соң бәхет түгәрәк?
Аның хөрлегеннән безгә нәрсә? –
Тигәч бары ярык тагарак.

Күчерәм дип монгол җирләренә
Шаулый әнә берәү – җирәнгеч.
Куар да шул, башка халыкларга
Коллар итеп карап өйрәнгәч.

Без дә, юкса, Хода балалары,
Азатлыкка мохтаҗ тумыштан.
Иң бөек максат безнең, туган,
Хөр мәмләкәт, хөр Татарстан!..

Дуслыкның кадерен белә иде ул. Әмма кайбер дусларының хыянәтен бик авыр кичерде. Рәнҗеде дә бугай. Җаны авыртуына түзә алмыйча, бу хакта шигырь дә язып калдырды шикелле... Сөекле улы белән кадерле хатыны вафатыннан соң да, алга карап яшәргә көч тапкан иде ул. Ә менә дуслар хыянәте аның тез астына каты сукты кебек... Ошбу якты дөньядан кинәт китеп баруының сәбәбен мин әле дә аңлап-төшенеп җиткерә алмыйм...

Күптән түгел генә Азнакайда булып, көн саен яңарыш кичереп яшәгән шәһәр белән җәһәт кенә танышып чыкканнан соң, юлдашларым – археолог Альберт Борһанов һәм «Безнең мирас» журналы хезмәткәре, яшь галим Ленар Гобәйдуллин белән бергә, Илдус абыйның туган авылы Урсайга барып чыктык. Минем, шәхсән, беренче килүем, беренче күрүем: зур авыл икән, янәшәдә генә Ык ага, елганың аргы ягында, чал тарихтан бер өнсез истәлек булып, борынгы шәһәрчек урыннары тын гына җәйрәп ята, катлам-катлам булып, җир астында без беләсе могҗизаи серләр, моңлы-шанлы еллар йокымсырый...

Урсайдан Азнакайга кайтышлый, үрләр-чокырлар аша үтеп, Чатыртауга күтәрелдек. Читек Сабир малае – татарның милләтпәрвәр улы, талантлы шагыйрь Илдус Гыйләҗев йөргән эзләргә басып йөрү безгә дә насыйп әйләде. Кояшта назланып үскән үлән-чәчәкләрнең башларын сыйпап, җилләр йөгереп узган бер мәлдә Хәтернең кайсыдыр төшеннән Илдус абыйның шагыйранә тавышы ишетелгәндәй булды:

Чатыртауны биш урадым,
Әйләнеп карый-карый.
Шунда узган көннәремнең
Исәбен саный-саный...
Чатыртаудан китеп барам,
Борылып карый-карый.
Җирдә үткән гомеремнең
Елларын саный-саный...

27 июль, 2020 ел ■

Безнең мирас №8 август 2020

УТКӘННӘН ХАТ

Әйбәт истәлек

Сибгат Хәким – «Казан утлары»на



Мәхмүт Хәсәновның ике язмасын укыдым. Берсе – Туфан турында истәлек, берсе – колхоз агрономы турында очерк. Туфан – «Пар канат» җылырак язылган, күбрәк ошады. Мин күреп бетермәгән детальләр күп. Прозаик шагыйрьдән шуның белән аерыладыр. Шагыйрь фәлсәфи ягына күбрәк игътибар итә, прозаик җентекле. Бигрәк тә Ык буе табигатен сурәтләгән урыннар матур. Тагын бер тапкыр балык ашыйсым килеп китте. Мәхмүтчә бераз озын. Үземә кагылган урыннарны кысар идем. Яратып язган Туфанны. Әйбәт истәлек. «Бер уч арыш»та да конкрет образ бар – агроном Әшрәф. Кыссаң, тагы да конкретлашыр иде. Икесен дә «Казан утлары»на тәкъдим итәм. Кулыма тоттырган әсәрне кире җибәрә алмыйм. Хәзер начар укыйм. Күзнең басымы үзгәрде, ахры, авырта, тиз арый.

Сәлам белән, Сибгат Хәким.

12/XI – 84. ■

Ык буенда каләмдәшләр балык тота. Мәхмүт Хәсәнов, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким. 1970 нче еллар

Безнең мирас №8 август 2020

«Сабыр канатларым сынды...»

Мәхмүт Хәсәнов – Туфан Миңнуллинга

Туфан дускай, саумы!

Иң әүвәл үзеңә, шулай ук дус-ишләргә чуктин-чук сәламнәремне иңдерергә рөхсәт ит. Бу хат, бәлки, сине чак кына гаҗәпләндерер дип уйлыйм. Тик бер дә исең китмәсен.

Мин, ниһаять, соңгы чиккә җиткерелдем, уннарча ел буена тешләремне кысып булса да түздем, ахыр чиктә сабыр канатларым сынды, «сынды кылыч, бетте көч», инфарктның бик начары белән егылдым, больницада ятам.

Хикмәт менә нәрсәдә: әгәр дә исән калып, чыга-нитә калсам, иң беренче КПСС Өлкә комитетына барам. «Үзегезнең партоешмагыз кайда иде?» – дип әйтмәсеннәр өчен, син дә белеп тор, Туфан. Менә алты ел инде нәшрият минем китапларымны чыгармый. (Күз буяу өчен чыгарылган вак-төяк брошюраларны санамыйча, әлбәттә.) Бүгенге көндә нәшриятта минем биш романым ята. Чыгу белән, КПСС Өлкә комитеты тарафыннан, С.Хәким, Х.Хәйри, Р.Фәйзуллин һ.б. кебек иптәшләрне кертеп, комиссия төзелүен таләп итәчәкмен. (Биш әсәрем турында да уңай рецензияләр, матбугатта чыккан материаллар бар.)

Мине хәйран иткәне, кешелектән чыгарганы – бер уч, бер төркем сволочьларның гомеремне багышлаган, үзем өчен изгегә санаган олуг Татар әдәбиятында, ничек теләсәләр, шулай эшләүләре, күтләкләрчә алыш-биреш итүләре.

Гомеремдә кешегә этлек эшләмәдем, шулай булуга карамастан, бер төркем җирәнгеч вак җан (үзләренең тоткан урыннарыннан файдаланып) мине материаль яктан, мораль яктан юк итүне үзләренә максат итеп куйдылар. Көчләрен күрсәтәләр, янәсе! Әлеге эт җаннар максатларына өлешчә ирештеләр: мине аяктан ектылар, икенчедән, бүгенге көндә дару алырга да акчам юк. Үзем муеннан бурычта. Шуның өстенә, әни рактан үләргә ята.

Билгеле, нәшриятта 1980 елда да «Шайтан малае» дигән ике хикәясе чыга дип әйтүләре бар. Әмма аннан аласы акча Лит-

Алгы рәттә уңнан беренче – Туфан Миңнуллин.
Аның баш очы турысында дүртенче рәттә – Мәхмүт Хәсәнов

фондка түләргә дә җитмәячәк. (Андагы бурыч – 300 сум.) Син, Туфан, мине дөрес аңла, хикмәт бер бурычта гына да түгел, иң гарьләндергәне – йөрәгеңә каләм очы белән кадап язган әсәрләреңне халкыңа җиткерә алмау. Һәм шундый чакта берәүнең дә әлеге җирбитләргә: «Җиткәндер бит, җәмәгать!» – дип әйтә алмавында.

Синең: «Мәхмүт, нәрсә телисең?» – дип соравың бар. Менә җавап. Мин «Шөгеровлар» дигән роман яздым. Аны Әлмәт бүлегендә тикшердек. Бик яраттылар. Моннан төп-төгәл өч ел элек (төзәтеп, эшен бетереп) нәшриятка китереп тапшырдым. Әсәр турындагы фикер нәшриятка да килеп җиткән иде инде. Шунда нәшрият директоры Г.Шәрәфетдинов, бүлек мөдирләрен җыеп алды да: «Мәхмүтнең берничә әйбере бездә ята. Әйдәгез, «Шөгеровлар»га туктыйк», – дип тәкъдим ясады. Шулай иттеләр дә. Шулай да Гарәф бер искәрмә ясаган икән әле: «Әгәр дә ки әсәр «Казан утлары»нда басылса, китап итеп чыгару бермә-бер җиңеләячәк», – диде. Аның ул шарты да үтәлде. Әсәрнең 1981 ел планына керүенә шигем юк иде. Идарәдә тикшергәндә дә: «Син бар», – дигәннәр иде. Тагын алдадылар, тагын мыскыл иттеләр. Монда керер алдыннан гына, ниһаять, әйттеләр: «Күзеңә карап алдыйлар бит, беркатлы булма, алты ел буена әсәрләреңне кертмәделәр һәм кертмәячәкләр», – диделәр. (Бу хәлләр турында Гариф Ахуновка язган хатым бар, зинһар, дип сорыйм, алып танышсаңчы. Күп нәрсәгә күзеңне ачачак.) Теләгем шул: Туфан, «Шөгеровлар»га договор төзеп, хатыныма чак кына аванс бирсеннәр иде. Югыйсә гаилә бик аяныч хәлдә.

Туфан, ни өчендер, сиңа ышанам, ярдәм итәрсең дип өмет итәм. (Үзеңә ярдәмгә Сибгат аганы чакыр, мин аңа әдәбиятыбызның намусы, вөҗданы итеп карыйм.) Әсәргә договор төзеп, хатынга бераз акча бирсеннәр иде. Югыйсә мине тиз генә чыгармаячаклар. Бу больницадан (өйгә дә кертеп тормыйча) «Васильево»га алып китәчәкләр икән. Кыскасы, миңа беренче звонок бирелүе шулдыр...

Ярар, Туфан туган, бу сүзләрне мин сиңа, партоешма секретаре булудан бигрәк, олуг художник, чын кеше буларак язам.

P.S.: «Көя күбәләге» турындагы кәгазь миңа да килде. Саба районының Халык театры куйган булган икән.

Кабат сәлам һәм ихтирам белән,
М.Хәсәнов. Зеленый Дол. 30.7.80 ел. ■

Безнең мирас №8 август 2020

Әкиятче бабай

Мөҗәһит Әхмәтҗанов

Зариф Мөэминов (Әхмәтзариф Әхмәтлатыйф улы Мөэминов) – Мөслим районының Октябрь авылында яшәгән фольклорчы, мөгаллим. 1893 елда туган, 1966 елда вафат булган. Исеме «Татар энциклопедиясе сүзлеге»нә кергән. Аның турында: *«Әкиятче, 1939-1941 елларда Татарстан Халык Комиссарлары Советы каршындагы Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институтына 50дән артык әкият туплап җибәргән. Аларның күпчелеге халык авыз иҗаты җыентыкларында басылып чыкты»*, – диелгән. Укымышлы зат, мөгаллим, гомере буе татар халык авыз иҗатын өйрәнгән, туплаган, җае чыккан саен, Казанга – Тел, әдәбият һәм тарих институтына җибәргән, анда эшләгән фольклорчы галимнәрне яхшы белгән. «Татар халык иҗаты» җыентыкларындагы беренче чыганакларга – 1938 ел, соңгыларына 1948 ел дип куйган. Тынгысыз мөгаллим әле аннан соң да бу эшен туктатмагандыр. Зариф Мөэминов бигрәк тә күренекле фольклорчы галим Хәмит Ярми белән эшлекле мөнәсәбәттә булган. Чыганаклардан күренгәнчә, 1941, 1948 елларда Хәмит Ярми фольклорчы дусты Зариф Мөэминовтан шактый әкият, бәет, җыр, мәкаль-әйтем, табышмаклар язып алган. Безнең якта аны Зариф абзый яки «Әкиятче бабай» дип йөрткәннәр. Ул яшәгән, озак еллар укыткан, мөгаллимлек иткән авыл – Мөслим районындагы Октябрь (1940 елга кадәр Teләнче атамасы белән йөргән, төбәктәге борынгы авылларның берсе). Язмаларыннан күренгәнчә, язмыш Зариф бабайга бик үк миһербанлылык күрсәтмәгән. Күп илләр, җирләр гизәргә, күпти-күп җәфалар күрергә, җәбер-золымнар аша да кичәргә туры килгән. Беренче Бөтендөнья сугышы башлангач, Зариф Мөэминов Австрия-Венгрия территориясендә әсирлеккә эләгә. Монда ул башка әсир татарлардан ишеткән халык әкиятләрен язып ала башлый. Алардан җыелган әкиятләр берничә дәфтәр тәшкил итә… Әсирләрне Сараево шәһәренә күчергән вакытта тентеп, Зарифтан әкиятләр тупланган дәфтәрләрне дә табалар һәм алалар. Ләкин әкиятләр югалмый, чөнки күбесе әкиятченең башында була, ул аларны яттан белә. Зариф әкиятләрнең бер өлешен, күрәсең, авыл картларыннан ишетеп, Бөек Ватан сугышына кадәр язып алгандыр. Дәфтәрләргә, шулай итеп, Исмәгыйль карт, Латыйп бабай, Габдрахман агай, Габделҗәлил карт, Йосыф карт Хәлилов, Шакир Закировлардан ишеткән әкиятләр керә. Әкиятләр шактый туплангач, ул аларны Казанга юллый. Әлеге үрнәкләр белән танышкан Гомәр Бәширов әкиятче Зариф Мөэминов эшенә югары бәя бирә.

Зариф ага озак еллар туган авылы Теләнчедә балалар укыта. Октябрь революциясеннән соң, авылның беренче укытучыларыннан санала. Ул чорда укытучыларны бер авылдан икенчесенә күчерү тәртибе була. Шуңа күрә, истәлекләргә караганда, Зариф Мөэминов Теләнчедә, өзеклекләр белән, 1919-1927 һәм 1937-1948 елларда мөгаллимлек итә. 1943-1944 елларда Бөек Ватан сугышында катнаша. Ул – өч сугышта катнашкан, ил, халык язмышындагы барлык фаҗигаләрнең, сынаулы елларның турыдан-туры шаһиты булган солдат-әдип. Сугыштан кайткач, Зариф Мөэминов укытучылык эшен дәвам итә. Туган авылында гына да балаларга унҗиде ел белем бирә ул.

Зариф бабай үзенең көчен әдәбиятның барлык өлкәләрендә сынап карый. Мондый шәхесләр, бигрәк тә халык авыз иҗатын халыкның үзеннән җыеп алып, аны язма рәвештә кире кайтару максаты белән шөгыльләнүчеләр күп булмаган. Җитмәсә, Зариф Мөэминовка татарның күренекле фольклор галимнәре бик зур бәя дә биргән. Әле бүгенгесе көнгә кадәр без ул җыйган әкиятләрне генә дә тәгаен белеп бетерә алмыйбыз. Ул авторны безгә әле һаман өйрәнергә дә өйрәнергә кирәк. Без әлеге шәхес белән лаеклы рәвештә горурланабыз.

Зариф бабайның кайбер шигъри формадагы әсәрләре, бәет исеме астында, 1960 елда Татарстан китап нәшриятында чыккан бәетләр китабында да дөнья күргән. Кайбер бәетләрне ул кемнәрдәндер ишетеп тә теркәп куйган. Мәсәлән, ул «Уяну» бәете турында болай дип яза: *«Бу бәет мәдрәсәләрдә 1905 елдан соң әйтелә иде. Мин белгән «Күбәк» мәдрәсәсенә бәет 1908 елларда килеп керде, соңга таба массовый төстә җырлана башлады. Бу бәетне әйтү күп мәртәбәләр тыелды, язмалары җыелып алынды. Шушы бәет аркасында мәдрәсәләрдә зур-зур эшләр чыкты, укучыларны эзәрлекләүләр булды. Бәет озын иде, мин аның хәтеремдә калган өлешен генә әйттем».*

Каләм

(Шигырь)

Кара савытта тора көмеш башлы җиз каләм,
Каләм хезмәте белән агарды бөтен галәм.
И, каләм-каләмем, сиңа булсын сәлам!
Синең иткән хезмәтеңә юктыр һичбер кәләмем.
Кәгазь өстен каралттың, дөньяны син агарттың.
Мең миллион томнарны җир йөзенә тараттың.
Китаплар булырмы иде, кешеләр белерме иде?
Каләмнән башка белем дөньяда булырмы иде?
Диңгез кичергән каләм, дөнья гиздергән каләм,
Ярны ишеп, тауны тишеп, ташны кистергән каләм!
Тупны аттырган каләм, дөнья ваттырган каләм,
Иң кирәге безгә шул: солых ясата каләм.

Суга баткан Гайшә бәете

Чәршәмбе көн кер юарга
Ник җибәрдең, әнкәем?
Барма, Гайшә, дигән булсаң,
Бармас идем, әнкәем.

Кулымдагы көмеш йөзек
Көнгә каршы эридер.
Тал чыбыктай зифа буем
Су төбендә черидер.

Өстемдәге камзулымны
Элеп куйдым казыкка.
Зифа буем үскән икән
Балыкларга азыкка.

Баткан чакта итәкләрем
Батадыр да калкадыр.
Муенымдагы тәңкәләрем
Су төбенә тартадыр.

Аучы мылтык атадыр,
Төтене җиргә ятадыр.
Матур Гайшә баткан, дигәч,
Туе җылап кайтадыр.

Чәршәмбе көн мунча яктым
Битем-күзем юарга.
Чәршәмбе көн кер чайкадым
Газиз башым җуярга. ■

Безнең мирас №8 август 2020

Нәкый Исәнбәт вафаты
(1899-1992)

....

(Гомәр Бәширов көндәлегеннән*)

Әдип һәм фольклорчы галим Нәкый Исәнбәт (сулдан икенче) бер тантаналы чарада

Н.Исәнбәт хакында сүз барганда аның җәмәгате Нәҗибә ханым турында берни дә әйтмичә китү гаделсезлек булыр иде. Чөнки Нәкый абзыйның шундый өлкән яшьтә дә исән-сау булуы, фәнни эш һәм иҗат белән шөгыльләнә алуы Нәҗибә ханымның фидакярлегенә бәйле. Нәҗибә ханым үзе һөнәре буенча рәссам кеше. Ләкин ул, Нәкый абзыйның элекке хатыны Гөлсем ханымның вафатыннан соң Нәкый Исәнбәткә кияүгә чыккач, бөтен тырышлыгын гына түгел, бөтен гомерен Нәкый Исәнбәтнең сәламәтлеген саклауга, аның әдәби иҗатын, фәнни эшчәнлеген дәвам иттерүгә багышлады. Нәкый Исәнбәт астма белән авырый, аның ун төрле чире бар, гомумән, ул тормышын бик кыенлык белән генә дәвам иттерә иде. Нәкыйнең сәламәтлеген ныгыту өчен, Нәҗибә ханым ниләр генә эшләмәде! Ул аны Башкортстанга ниндидер махсус курортка, Казакъстанга җир астындагы тоз шахтасында дәвалану өчен алып барды. Нәҗибә ханым, аны үләннәр ярдәмендә дәвалау өчен, бөтен республикадан гына дип әйтмим, хәтта Мари-Эл Республикасына чыгып, дару үләннәре белән сихәтләндерү чараларын күрә. Ул Н.Исәнбәтнең үзен генә беркая да җибәрми, һәрчак озата бара, аны балалар кебек кайгырта, дәвалый, аңа һәртөрле иҗат мөмкинлекләре тудыра. Нәтиҗәдә, Нәкый абзый хәзер элеккегә караганда тазарак яши, күбрәк эшли ала. Бу – бик зур бәхет.

---

* Бәширов Г.Б. Күңел дәфтәре: көндәлек язмалар [төзүчесе, кульязмаларны һәм искәрмәләрне әзерләүчесе – Зөфәр Бәширов]. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011. – 464 б.

Гомумән, без, Нәкый Исәнбәтнең татар әдәбиятына, аның культурасына керткән зур өлешен телгә алганда, Нәҗибә ханымны да ихтирам белән искә алырга тиешбез.

1984, 4 ноябрь

Сентябрь аеның икенче дистәсе тулып килгәндә, Нәкый Исәнбәт, элеккечә әйткәндә, фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте. Аның кырыгы тулган көндә мин Нәкый Исәнбәтне искә алу мәҗлесендә булдым, аны озату митингында (Татар академия театры бинасында) нотык белән чыктым, 29 октябрьдә «Татарстан хәбәрләре»ндә «Йолдыз кебек» дип исемләнгән мәкалә белән чыктым. Әмма ничек вафат булуын, кайда һәм ничек күмелүен, ул вакытта ниләр хис итүемне бу дәфтәргә язарга һаман да кулым бармады.

Нәкый Исәнбәт

Нәкый ага миннән яшь ярымга өлкәнрәк иде. Моннан бер ел чамасы элек мин, аның янында булып, аңа өч имза белән газетада басылачак мәкаләне укып күрсәткән идем. Ул вакытта ук Нәкый ага бик начар күрә, бик кыенлык белән генә ишетә иде. Чәчесакалы агарган, кыенлык белән генә аягында йөри. Аңа соңгы егерме ел эчендә чын-чыннан ярдәм иткән, аны кадерен белеп тәрбияләгән кеше – беренче җәмәгате Гөлсем ханым үлгәннән соң өйләнгән яшь хатыны Нәҗибә ханым булды. <...> Гомумән, Нәҗибә ханым Нәкый Исәнбәтнең гомерен байтакка озайтты, дип әйтергә мөмкин.

Быелгы җәйне алар, һәрвакыттагыча, Мари-Элның Яльчик дигән матур урынында уздырдылар. Сентябрьнең икенче яртысына кергәч (Нәҗибә ханым сөйләвенчә), Нәкый ага, нигәдер, борчыла башлаган, Казанга кайтырга теләвен белдергән. Теләге үтәлеп, үз фатирларына кайтканнан соң, бик куанган.

– Үз өебездә нинди рәхәт бит! Әйдә, чәй әзерлә әле, бер рәхәтләнеп чәй эчик! – дигән һәм шулай булган да. Нәкый ага ул көнне үзен яхшы хис иткән, вакытында йоклаган.

Икенче көнне дә ни дә булса сизелмәгән әле. Әмма өченче көнне ул инде урыныннан тора алмаган. Табиб чакырганнар. Ниндидер дарулар кулланганнар. Күрәсең, организм тәмам тузып җиткән булган, ул күзен мәңгегә йомган.

Нәкый Исәнбәтне озату митингына (Татар академия театры бинасына) халык күп җыелган иде. Аны, табутка салып, биек урынга куйганнар иде. Төрле оешмалардан һәм бигрәк тә аерым шәхесләрдән веноклар һәм чәчәкләр күп куелды. Сөйләүчеләр дә күп булды.

Табутны, күтәреп, Мәрҗани мәчетенә алып бардылар. Анда да халык күп иде. Ишегалдында тагын берничә мәеткә җеназа укылды. <...>

1992, 6 декабрь

*Журналга **Рүзәл Мөхәммәтшин** әзерләде.* ■

Безнең мирас №8 август 2020

Әхмәтҗан хәлфә

(1860-1938)

Тәэминә Биктимирова, тарих фәннәре кандидаты

Әхмәтҗан хәлфә Мостафин (утырганнар арасында уңнан беренче) гаиләсе һәм туганнары белән

Талантлы педагог, галим һәм мәртәбәле дин әһеле Әхмәтҗан Мөхәммәтрәхим улы Мостафин үзе язган мәкаләләре астына әнә шулай Әхмәтҗан хәлфә дип кул куйган.

Ни кызганыч, гомере фаҗигале үлем белән өзелгән олуг шәхеснең тормыш юлы һәм хезмәтләре бүгенге буынга мәгълүм түгел. Әмма, Аллага шөкер, халкына күрсәткән игелекле хезмәтләре турындагы мәгълүмат архивларда һәм әсәрләре «Әд-дин вә әл-әдәб», «Шура», «Укытучы» журналларында сакланган.

Әхмәтҗан Мостафин 1860 елда Саратов губернасының Кузнецк өязендәге (хәзер Пенза өлкәсенә керә) Татар Кынадысы авылында туа. Туган авылы мәдрәсәсендә белем алгач, ул 1890 елда Казандагы атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керә. 1894 елдан хаклы рәвештә татар университеты саналган «Мөхәммәдия»нең алыштыргысыз мөдәррисе һәм уку-укыту эшләре мөдире була. Әхмәтҗанның тырышлыгын, сәләтен һәм тормыштагы гаделлеген бик тиз күреп алган мәдрәсә җитәкчесе – олуг галим Галимҗан Баруди аны үзенең ышанычлы фикердәше, якын ярдәмчесе итеп саный башлый һәм үз бәясендә гомер буе ялгышмый. 1908 елда Россия эчке эшләр министры карары белән Вологдага

сөргенгә җибәрелгәндә Г.Барудиның мәдрәсә белән җитәкчелек итүне нәкъ менә Әхмәтҗан Мостафинга тапшырып китүе шушы ышанычның ачык дәлиле бит инде.

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе турындагы хезмәтләр, шөкер, матбугатта шактый басылып чыкты, конференцияләр дә үткәрелде. Шуңа күрә аның ачылу тарихына, шәкертләр тормышына тукталып тормыйм. Тик мәдрәсәдәге уку-укыту тәртипләре хакында гына бер-ике сүз әйтеп китәм.

1891 елдан ук «Мөхәммәдия»дә ысулы җәдид, ягъни яңа метод белән укыту гамәлгә керә. Мәдрәсәдә низам (тәртип) ныклы режимга салына: шәкертләр өчен тәртип кагыйдәләре төзелә, аларның тормышы махсус расписаниегә нигезләнә. Биредә, Европа төрендәге мәктәпләрдәге кебек, парталар, кара такталар, тарих һәм география карталары, плакатлар булдырыла. Мөгаллимнәр өчен мөнбәрләр (кафедралар) урнаштырыла. Шәкертләрнең киемнәренә дә үзгәрешләр кертелә: алар дәрестә өсләренә – утырма якалы тужурка, башларына тигез түбәле кәләпүш киеп утыра.

Мәдрәсәдә, дини фәннәрдән тыш, рус-европа гомуми белем бирү мәктәпләрендәге барлык дөньяви фәннәр дә укытыла.

1906 елдагы мәгълүматларга караганда, биредә 500дән артык шәкерт укыган һәм педагоглар коллективы да шактый зур булган – 20дән артык мөгаллимнән торган. Кайбер фәннәр программада каралмаса да, өстәмә рәвештә укытылган. Мисал өчен, доктор Әбүбәкер Терегулов – медицина, гигиена; адвокат Сәетгәрәй Алкин – хокук, сәясәт; Йосыф Акчура – сәяси тарих (1905 елда), Фатих Әмирхан (үзе дә 1895-1906 елларда шушы мәдрәсәдә укыган) сәяси партияләр хакында дәресләр биргән.

Әхмәтҗан хәзрәт исә гарәп теле һәм педагогия фәннәрен укыткан. Педагогия фәненнән белем биргәндә ул динебезгә һәм көнкүрешебезгә якын булган Ислам дөньясы мөгаллимнәренең хезмәтләренә мөрәҗәгать иткән. «Педагогия гыйльмия вә гамәлия, – дип яза мөгаллим, – Россия мөселманнары дөньяви хәлләрендә тәрәккъый итсеннәр өчен балаларын тәрбияләмәктә беренче һәм вә иң мөһим шарттыр... Имди без дә шул кабиләдән бер хезмәт булдыру касыды (нияте) берлән галәмәи Исламның бөек педагогларыннан мәрхүм Хәсән Тәүфыйк Мисрыйның педагогия китабын тәрҗемә илә «Әд-дин вә әл-әдәб» мәҗәлләсендә бирергә карар бирдек»[1]. Бу зур хезмәтне ул «Әд-дин вә әл-әдәб», соңрак «Шура» журналларында тәрҗемә итеп бастыра һәм 1907 елда аерым китап итеп тә чыгаруга ирешә[2].

«Мөхәммәдия»дә яңача укытуны кертү, шәкертләрне яңа программаларга туры килүче яңа дәреслекләр белән тәэмин итү бурычы куела. Яңа дәреслекләр булдыруга Галимҗан Баруди башлап үзе керешә. Аның беренче китабы «Гыйльме әт-тәүхир» («Аллаһы Тәгаләнең берлеге турындагы тәгълимат») 1890 ел башында ук бастырып чыгарыла. Әхмәтҗан Мостафинның тел белеменә багышланган «Төрки сарыф» (төрки дигәне татар телен аңлаткан) исемле зур хезмәте 1905 елда нәшер ителә. Хезмәтнең дәвамы буларак язылган «Төрки нәхүе»н ул 1914 елда бастыра. Болардан тыш, «Милләт вә мәктәпләр тугрысында» (1906), «Иттихаде лисан – тел берлеге» (1906), «Хат хакында мөляхәзә» (1907), «Мөсаувәр әлифба» (елы күрсәтелмәгән), «Тәгълим вә тәрбия» (1913), «Балаларны укыту турында берике сүз» (1915), «Гыйлем вә китап хакында» (1915), «Язуымызны төзәтү хакында» (1918) һәм башка хезмәтләре «Әд-дин вә әл-әдәб», «Шура», «Мәктәп», «Укытучы» журналларында чыгып килә һәм аерым китап та булып дөнья күрә.

---

[1] Педагогия гыйльмия вә гамәлия (Хәсән Тәүфыйк Мисрый китабы хакында) // Әд-дин вә әл-әдәб. – 1907. – №1. – 27 б.

[2] Педагогия гыйльмия. – Казан, 1907. – 66 б.; Педагогия гамәлия. 2 кис. – Казан: Идрисов-Галиев, 1908. – 51 б.

Мәгълүм булганча, XX гасыр башында татар укучы яшьләренең мәктәп реформасын гамәлгә ашыру, уку-укыту процессларын европалаштыру максатында киң колачлы эш башлана. «Мөхәммәдия» шәкертләре анда иң актив катнашучылар була. Биредә 1901 елда яшерен «Иттихад» («Берлек») оешмасы төзелә. Аның максаты – бөтен Казан шәкертләрен иске, кадими мәдрәсәләрне үзгәртеп кору өчен көрәшкә туплау була. 1903-1904 елларда Ф.Әмирхан җитәкчелегендә әдәбият түгәрәге оештырыла. Мондагы түгәрәкләрдә чыныгу алган шәкертләр арасында татарча театр уйнау фикере туа. Ул тормышка да аша. 1903 елның декабрь аенда мәдрәсәдә Ф.Әмирхан, Әхмәтҗан хәзрәтнең улы Габдрахман Мостафин, Гыймай Нугайбәк, Хәлил Әбелхан, Солтан Рахманколый һ.б. катнашында Г.Камалның «Бәхетсез егет» драмасы буенча спектакль куела.

1905-1906 елларда Россиядә борынгы милли кыйммәтләрне барлау һәм аларны үстерүнең яңа юнәлешләрен билгеләүне максат итеп куйган татар иҗтимагый хәрәкәте җәелеп китә. 1905-1907 елларда әлеге хәрәкәткә юнәлеш бирүче Бөтенроссия мөселманнары фиркасе «Иттифак әл-мөслимин» оеша, аның программасын Идел буе, Урал, Кырым, Кавказ, Урта Азия, Азәрбайҗан зыялылары хуплый. Фиркане оештыруда турыдан-туры катнашучы Г.Баруди «Иттифа...»ның Үзәк комитетына сайлана. Әхмәтҗан Мостафин Түбән Новгород шәһәрендә үткәрелгән III корылтайда мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укытуны үзгәртеп кору буенча төзелгән комиссия әгъзасы була[3]. Комиссия съезд карамагына милли мәктәп турында 33 маддәдән торган проект тәкъдим итә. Ул белем бирүнең бердәм системасын булдыру, мәчетләр каршындагы мәктәпләрне җәмгыять кулына тапшыру, барлык мәктәпләрне дәүләт һәм җирле үзидарәләр хисабына тотуны һ.б. тормышка ашыруны кирәк дип саный. Бу тәкъдимнәр хуплап каршы алына. Чөнки заман барышы татар мәгарифенә әлеге таләпләрне үзе үк куйган була инде. 1905-1906 елларда Казан, Уфа, Оренбург, Троицк, Әстерхан, Орск (Өре), Самара кебек шәһәрләрдә генә түгел, хәтта зуррак авылларда да мөгаллимнәрнең төрле җәмгыятьләре оеша. Бу җәмгыятьләрнең максаты уртак: татар мөгаллимнәренең тормышын, эш шартларын яхшырту, мәдрәсәләрдә уку-укытуга үзгәрешләр кертү, барлык уку йортлары өчен бердәм программалар, ә һәрбер сыйныф өчен аерым дәреслекләр хәзерләү, балаларны тормышка әзерләү өчен һөнәр мәктәпләре булдыру, телебезне, әдәбиятыбызны камилләштерү һәм татар телендә дарелмөгаллимат ачу.

Мөгаллимнәр өчен курслар да оештырыла башлый. Ниһаять, 1906 елның 13-16 октябрендә, 1907 елның 15 маенда мөгаллимнәрнең киңәшмәләре үткәрелә. Әмма һәр ике очракта да катнашучылар полициянең эзәрлекләвенә дучар була. Аларның күбесе кулга алына, уку әсбаплары юк ителә, мәдрәсәләрдә әледән-әле тентү үткәрелеп тора. Нәтиҗәдә, 1908 елның маенда Галимҗан хәзрәтнең үзен, курслар оештыруда активлык күрсәткән энесе Салихҗан хәзрәт Галиевне (курслар Салихҗан мәдрәсәсендә ачыла), Габдулла мулла Апанаевны һәм сәүдәгәр Габделхәмит Казаковны губернатор әмере белән ике елга Вологда губернасына сөргенгә җибәрәләр. Нәкъ шул вакытта мәдрәсә язмышы өчен тирән борчылу кичергән Галимҗан хәзрәт «Мөхәммәдия»не тулысы белән Әхмәтҗан хәзрәт Мостафинга һәм аның энесе мулла Габдрахман Галиевкә ышанып тапшыра да инде.

Әхмәтҗанның үз хәле дә кыл өстендә диярлек була. 1909 елның 8 гыйнварында Казандагы жандарм идарәсе җитәкчесе К.И.Калинин, «Мөхәммәдия» мөгаллимнәре

[3] Аршаруни А., Габидуллин Х. Очерки панисламизма и пантюркизма в России. – Рязань: Изд-во «Безбожник», 1931. – С. 114.

Әхмәтҗан Мостафин, Шәһретдин Шәрәф, Фатыйх Зәбиров һәм Рәхим хәлфәне панисламизм идеяләрен таратуда гаепләп, полиция департаментына донесение яза. Алар полициянең даими яшерен күзәтүе астына алына[4] һәм 1911 елда барысы да эштән җибәрелә. Бу вакыйгалардан соң мәдрәсәдә мөдирлек вазыйфасы да үз өстенә төшкән Габдрахман мулла Галиев, мәдрәсәнең могътабәр попечителе Әхмәтгәрәй Әҗемев, мәхәллә кешеләре исеменнән күренекле җәмәгать эшлеклесе Әхмәтҗан Сәйдәшев, уку-укыту эшләренең, мәдрәсәнең авыр хәлдә калуын аңлатып, рәсми органнарга мөрәҗәгать итәләр һәм эштән җибәрелгәннәрне «вакытлыча гына» булса да кайтаруга ирешәләр[5].

Әхмәтҗан хәзрәт 1917 елгы Февраль революциясен зур өметләр белән каршылый. Ул Вакытлы хөкүмәт шартларында туган вазгыятьне милли тормышны җайга салуда әһәмиятле шарт итеп күрә. Әхмәтҗан хәзрәт тиз арада «Азат Русиянең азат угыл вә кызларына» мөрәҗәгать яза һәм болай ди: «Сезнең кулларыгыздан, күңелегездән иске хөкүмәтнең богаулары төште. Инде сез теләгән җәмгыятьләрегезне ясап җыела аласыз, теләгән эшләрегезне эшли аласыз, теләгән сүзләрегезне сөйли аласыз... Инде сездә булды дин азатлыгы, сүз азатлыгы, җыелу азатлыгы, эш азатлыгы... Кадерен белеңез. Мәңге бу дәүләтләрнең иясе булырсыз. Урынлы тота белмәсәңез, ул янә сезнең кулдан ычкыныр, тагын коллыкка кайтырсыз. Ул чакта инде, бәлки, котыла да алмассыз»[6]. Тарих хәзрәтнең хак булуынраслады.

> «
> **Кадерен белеңез. Мәңге бу дәүләтләрнең иясе булырсыз. Урынлы тота белмәсәңез, ул янә сезнең кулдан ычкыныр, тагын коллыкка кайтырсыз. Ул чакта инде, бәлки, котыла да алмассыз.**

Әхмәтҗан хәлфә сүздә генә түгел, эш-гамәлдә дә активлык күрсәтә. 1917 елның 7 мартында Казанда татар җәмәгатьчелегенең зур җыелышы үткәрелә һәм анда Казан мөселман комитеты төзелә. Аның составына, Садри Максуди, Ильяс һәм Җиһангир Алкиннар, Вәлидхан Таначев, Фуад Туктаров кебек күренекле сәяси эшлеклеләр белән беррәттән, Әхмәтҗан һәм аның улы Латыйф, энесе Әмин Мостафиннар да кертелә. Әхмәтҗанның кызы Әминә Мостафина комитетның сәркәтибе була. Мөселман комитетының программасы милли хәрәкәткә халыкның киң катлауларын тартуны күздә тота.

1917 елның 1-5 августында Казанның «Новый клуб»ы залында Россия мөселман укытучыларының икенче съезды эшли. Аның көн тәртибенә куелган мәсьәләләр бик җитди: 1) мәктәпләрдә иҗтимагый фәннәр укыту; 2) 6 еллык ибтидаи мәктәп, дарелмөгаллимин һәм дарелмөгаллимәт программалары; 3) имля вә хат; 4) милли вә мәдәни мохтарият хакында; 5) укытучыларның матди һәм мәгънәви җәһәдләре, дәреслекләр хакында; 6) мәктәптән тыш тәрбия; 7) укытучылар тарафыннан журнал чыгару һ.б.

Ә.Мостафин программалар, дәреслекләр турында берничә тапкыр үтемле чыгышлар ясый, укытучылар өчен махсус журнал чыгарылмавына бик борчыла, съездда шул хакта да сүз кузгата. 1918 елда журнал «Укытучы» исеме белән чыга башлый. Әмма 1918 ел – «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе ябылган, күренекле педагоглар эштән куылган вакыт. Журнал да ярты ел гына чыгып кала.

---

[4] ТР МА, 199 нчы ф., 1 нче тасв., 675 нче эш, 11 б.
[5] ТР МА, 92 нче ф., 2 нче тасв., 14853 нче эш, 29-30 б.
[6] Әд-дин вә әл-әдәб. – 1917. – №10. – 237 б.

1917 елның 20 ноябрендә Уфада Эчке Россия һәм Себер төрки-татар мөселманнарының Милли мәҗлесе җыела. Әхмәтҗан Мостафин – Милли мәҗлес депутаты, дини эшләр буенча төзелгән комиссия әгъзасы. Әлеге орган, белгәнебезчә, Октябрь революциясенә тискәре мөнәсәбәттә була һәм Идел-Урал штаты оештыру турындагы карар кабул итә. Милли-мәдәни автономиянең башкарма органы – Милли идарә булдырыла, ул финанс, мәгариф һәм дини ведомстволардан тора. Әхмәтҗан Мостафин Галимҗан Баруди җитәкчелегендәге дини ведомствоның әгъзасы булып та сайлана[7].

Кызганыч, Милли идарә озак яшәми, РСФСР Милләтләр эшләре һәм Татар-башкорт комиссариатларының 1918 елдагы 21 апрель карары нигезендә таркатыла. Бу турыдагы декретка И.Сталин һәм М.Вахитов кул куя.

1918 елның 23-31 маенда, Үзәк мөселман комиссариаты карары нигезендә, Бөтенроссия мөселман укытучыларының III съезды җыела. Бу – Октябрь революциясеннән соң үткәрелгән беренче съезд. Ул татар мәдәнияте һәм мәгарифенең киләчәккә үсеш юлларын Совет властена яраклаштырып билгеләргә тиеш була. Шуңа күрә аның көн тәртибенә совет хакимиятенә мөнәсәбәт, мәктәпкәчә, мәктәптә һәм мәктәптән тыш тәрбия, яңача укыта торган укытучылар әзерләү, укытучылар берлеге оештыру мәсьәләләре куела.

Төп докладны Үзәк мөселман комиссариаты вәкиле Галимҗан Ибраһимов ясый һәм үз чыгышында 1917 елның апрелендә Газиз Гобәйдуллин җитәкчелегендә төзелгән Укытучылар берлеген таркату кирәклеге хакында әйтә. Берлек озакламый таркатыла да. Әмма бу съездның тарихи әһәмияте шунда: биредә, татар әдәби теле һәм орфографиясенең үсеше, татар мәдәнияте турындагы фикерләрне бергә туплап өйрәнү өчен, фәнни коллегия төзү мәсьәләсе күтәрелә. Нәтиҗәдә, 1918 елның 2 июнендә Ә.Мостафин, Х.Бәдигый, Г.Шәрәф һәм Үзәк мөселман комитеты вәкилләре Г.Ибраһимов һәм М.Вахитов катнашында фәнни коллегия төзелә[8].

Әхмәтҗан Мостафинның 1918 елдан соңгы эшчәнлеген тулысынча ачыклап булмады. Әмма педагогик эшчәнлеге туктамагандыр диясем килә. Болай дип уйларга нигез дә бар, чөнки 1927 елда Исхак Рәхмәтуллин (бу вакытта халык мәгарифе комиссары) мөгаллимнәрдән Әхмәтҗан Мостафин, Фатиха Аитова, Гайшә Терегуловаларны һәм укытучы Фәхрелислам Рәшидовны, күпьеллык педагогик эшчәнлекләре өчен, персональ пенсиягә тәкъдим итә. Пенсия бирелми, ләкин аларның хезмәтләренә югары бәя куела. Монысы да бик мөһим.

Ә.Мостафинның тагын бер игелекле эше хакында әйтми китү мөмкин түгел. Ул 1919 елда, Г.Баруди белән бергәләп, Казанда 18 нче мәчет (Кабан арты) төзүгә рөхсәт алуга ирешә. Бу вакытта Татарстан хөкүмәтенә милли җанлы Кашшаф Мохтаров җитәкчелек итә һәм ул мәчет төзелүгә үзе дә теләктәш була. Әхмәтҗан хәзрәт шушы мәчет өчен хәзерге Ирек мәйданында булган һәм янган театрның иске кирпечләренә хәтле үзе кырып, әлеге эшне оештырып йөри. Мәчет 1927 елда ачыла, беренче намаз аның җитәкчелегендә укыла. Мәгълүм булганча, ул 1930 елда ябыла һәм яңадан 1991 елда гына эшли башлый. 1931 елда Ә.Мостафин, кулак-муллалар төркемендә катнашуда гаепләнеп, кулга алына, бөтен мал-мөлкәте конфискацияләнә. 1933 елда эш туктатыла. Әмма 1938 елның 10 гыйнварында ул кабат кулга алына һәм атып үтерелә. Бөтен гаиләсе, туганнары белән милләткә хезмәт иткән шәхеснең гомере әнә шулай өзелә. Мәшһүр мәгърифәтчебезнең урыны җәннәттә булсын. ■

[7] Тормыш. – 1918. – №787. – 18 гыйнвар.

[8] Терегулов И. Очерки истории революционного и общественного движения мусульман России // ОРРК НБ им. Н.И.Лобачевского К(П)ФУ, рукопись №3881.

Япон феномены

Фарук Нәфиев

«Русский» утравы «Сай сулы» бухта

«Безнең мирас» журналында Габдерәшит Ибраһимовның Япония һәм аның халкы турындагы ифрат кызыклы вә гыйбрәтле язмаларын сокланып укып барам. Нәкъ шулар тәэсирендә үземнең дә ярты гасырдан артык элек бу илдә күргәннәрем, аның соңгы чор тарихындагы кызыклы вакыйгалар, һәр өлкәдә ирешкән казаныш-уңышлары турындагы истәлекләремне укучыларга да җиткерәсем килде.

Моннан 65 ел элек миңа Япон диңгезендәге «Русский» исемле утрауда флотта хезмәт итәргә туры килгән иде.

Хәрби корабльдә хезмәт иткәндә берничә тапкыр Япониянең башкаласы Токио һәм Иокогама шәһәрләрендә булып, бу илнең халкы һәм аның тормыш-көнкүреше, безнең өчен гадәти булмаган бик кызыклы вә гыйбрәтле кайбер гореф-гадәтләре белән бераз танышу насыйп булды.

Үзләренең утрауларында меңеллар буена ябылып, дөнья белән аралашмый яшәгән бу уникаль халыкның йолалары, гореф-гадәтләре дә башка беркайда очрамый торган гаҗәп кызыклы һәм гыйбрәтле.

10 миллион халкы булган Токиога беренче тапкыр баргач (бүген исә анда 30 миллион кеше яши!), төркемебез җитәкчесе боцман Коломейчук башта безне шәһәр читендәге бер кафега алып керде. Барыбыз да, ишек катындагы махсус киштәләргә матрос ботинкаларыбызны салып, бина эченә оекбашлардан гына үттек. Безнең өчен гайре табигый хәлләрнең башы шуннан башланып китте. Кафе эчендә без гадәтләнгән озын өстәлләр дә, урындыклар да юк иде. Берничә урынга урнаштырылган тәбәнәк кенә журнал өстәлләре сыман нәрсәләр янына килеп, аякларыбызны бөкләп утырдык.

Шунда официант, бернинди заказлар кабул итеп тормастан, өстәлләргә үз белдеге белән кечкенә генә тәлинкәләрдә дөге боткасы, чиле-пешле балык телемнәре, диңгез кәбестәсе салаты, миниатюр касәләрдә төрле тере әкәм-төкәмнәр һәм әлегә хәтле без күрмәгән-белмәгән әллә нинди экзотик диңгез ризыклары китереп куйды.

Боцман мондагы кухня-кулинариянең кайбер үзенчәлекләре белән таныштырып үтте. Йөзеңне чытып, канәгатьсезлек билгесе чыгарып, ризасызлык белдерергә ярамавы турында да кисәтергә онытмады. Мондый гамәл хуҗаларның кунакчыллыгын санга сукмау, үзләрен ихтирам итмәү булып аңлашылачак икән. Япон ашханәләрендә (рестораны, кафесында да) азыкны бездәге сыман җанын алганчы кыздырып-пешереп маташмыйлар. Чөнки алай эшләгәндә, аның витаминнары да, тәме дә калмый дип саныйлар. Мәсәлән, йомырка тәбәсен кыздырганда табаны ут өстендә берничә минут йөртеп алалар да алдыңа китереп куялар. Балык һәм дөгене дә тозсыз гына чиле-пешле әзерләүне бик файдалы дип саныйлар икән. Диңгез кысласы, әкәм-төкәмнәр, төрле юанлыктагы һәм формадагы суалчаннар да клиентларга тере килеш махсус савытларда китерелә. Башкалар белән чагыштырганда бик алга киткән бу цивилизацияле халык һәр ашамлык-азыкның үз табигый төсе һәм исе килеп торырга тиеш дип саный. Галимнәр бүген япон ирләре һәм хатыннарының уртача яше 90га җитеп килүне бу илдәге туклану һәм яшәү рәвешенә бәйләп аңлаталар. Озын сүзнең кыскасы, безгә, аеруча кыстыбый, пәрәмәч, өчпочмак ише нәрсәләргә күнеккән татарларга, японнар дәрәҗәсенә менеп җитәр өчен нык тырышырга, потлаган тоз ашарга кирәк булачак икән әле дип уйлап куйдым шул чагында.

«

Шунда тозсыз дөге кабып сытылган чыраемны күргән Әзһәр дус: «Биредә һәр ризыкны елмаеп, канәгать кыяфәт белән ашарга кирәк, чөнки күзәтеп торучылары бар», – дип куйды.

Ярый, хуш. Саф һава сулап, байтак җирләрдә булырга өлгергән егетләрнең аппетиты нык кузгалган чак. Кайберәүләр, әкәм-төкәм, кысла, суалчаннар өстенә соусын, аджика ише нәрсәләрне мул тамызып, сыптыралар гына. Үзем электән яратып ашаган диңгез кәбестәсе салатына үрелдем. Әмма ул бөтенләй тозсыз булганга, күңелем төште. Өстәлдә ипи урынына чиле-пешле, тозсыз дөге боткасы. Тау-таштан торган утрауларда, гомумән, сөреп иген игәрлек җирләре юк.

Шунда тозсыз дөге кабып сытылган чыраемны күргән Әзһәр дус: «Биредә һәр ризыкны елмаеп, канәгать кыяфәт белән ашарга кирәк, чөнки күзәтеп торучылары бар», – дип куйды.

Ярый әле нерваларым тыныч, яшь чак. Берәр псих булса, безнең Мишәрстан якларындагыча: «Кит, анасын сатыйм, чиле-пешле, тозсыз, майсыз азык ашап утырырга мин бозау түгел ләбаса!» – дип сүгенеп куяр иде. Әмма без, совет диңгезчеләре өчен беренче урында – тәртип-дисциплина.

Мин инде, бөтен чыдамлыгымны бер йодрыкка туплап, «дегустация»не дәвам иттем. Бер матур гына касә эчендә үземне тәмле кәнфит кебек күптән ымсындырып, сырты ялтырап торган коңгызга охшаш бернәрсәне алып каптым да, чәйнәп тә тормастан, йотып җибәрмәкче булдым. Әмма бу диңгез кысласы, бугаздан төшеп китәргә теләмичә, кытыршы тәпиләре белән өскә үрмәли башлады! Мин шунда, аны юып төшермәкче булып, зур гына касәне күтәреп, суын эчә башладым. Әзһәр тагын, кабыргама төртеп: «Тизрәк урынына куй, син бит кул юарга дип куйган суны эчәсең», – дип пышылдады. Башка иптәшләр дә, сәерсенеп, миңа карап утыралар иде. Ә үзем исә,

диңгез кысласының бүксәмә хәвеф-хәтәрсез генә, шома төшеп китүенә куанып, елмаеп куйдым. Әмма эчемдә «бүре концерты» барса да, суалчаннарга да, кыслаларга да, әкәм-төкәмнәргә дә бүтән үрелмәдем. Шунда япон кухнясы белән танышуыма нокта куеп, эчемнән генә амин итеп: «Нишләтәсең инде тамагың туймагач, үзең Япониядә тумагач», – дип, башкалар белән бергә кафедан чыгып киттем. Укучы игътибар иткәнчә, барысын да тәфсилләп, бәйнә-бәйнә язам. Чөнки бу илдә ике тапкыр гына булган килеш, борынгы Рим империясе полководецы Гай Юлий Цезарь кебек: «Килдем, күрдем, җиңдем», – дип, телеграмма теле белән бер-ике генә җөмлә язып куйсам, бер кызыгы да калмас иде. Бер тотынгач, сәяхәтнамә булсын, дим.

...Кафедан чыккач, барыбыз да бульвар буйлап портка таба атладык. Шунда шәһәр читендә тезелешеп киткән бер катлы өй түбәләрендәге калайдан бик килештереп ясалган, җилдә флюгер сыман боргаланып торучы карп балыкларына күзем төште. Кайсы түбәдә – бер, кайсыларында ике-өч карп боргаланып торуның серен дә Әзһәр аңлатып бирде. Япониядә, электән килгән гадәт буенча, малайлар культы яши икән. Калай карплар гаиләдә ничә малай булуын аңлата, диде ул.

Бераздан алсу чәчәккә күмелеп утыручы сакуралар тезелеп киткән гүзәл бер сквер-бакчага килеп кердек. Шунда 3-4 яшьлек улы белән баручы яшь кенә бер японга күзем төште. Менә малай, уңга-сулга күз ташлап, агачлардагы кошларга да караштыргалап барганга, абынып егылды һәм елый башлады. Атасы исә, ни гаҗәп, берни булмагандай, акрын гына алга таба атлавын дәвам итте. Шунда малай, елавыннан туктап, аякларына торып басты һәм йөгерә-йөгерә атасын куып тотты.

«Биредә балаларга менә шулай спартан тәрбиясе бирәләр икән» дигән уй йөгереп үтте баштан. Ә бездә мондый очракта әтисе, улының күз яшьләрен сөртеп, башыннан сыйпап: «И, мескенкәем, ялгыш кына ап иттеңме, бик авырттымы?» – дип җәлләр, юатыр иде. Кечкенә чакта мондый нәрсәләр булып торганга, бала акрынлап җәлләтергә, иркәләнергә өйрәнеп, зәгыйфь һәм нәзберек булып үсәр иде. Беренче карашка вак-төяк кенә булып күренгән нәрсәдән дә японнарның акыллы гадәтен, тәрбия ысулын аңларга мөмкин. Гомумән, биредәге тәрбия системасының балаларның мөстәкыйльлек, тырыш, хезмәт сөючән булып үсүләре өчен көйләнгәнлеге күренеп тора.

Гыйбрәт алырлык

Үзебезнең «Татар бугазы»на якын гына урнашкан бу бик кызыклы ил турында кыска гына мәгълүмат бер дә артык булмас дип уйлыйм.

Ерак Көнчыгыштагы кояшлы алсу таңны беренче каршылаучы бу ил дүрт зур утрауга һәм бик күп кечкенә атауларга урнашкан. Ул, җир мәйданы буенча Россиядән 100 тапкыр бәләкәйрәк булса да, халык саны буенча аңа тигезләшеп килә. Җитмәсә, ил мәйданының 70 процент җире таулар, урманнардан тора. Еш булып торучы җир тетрәү фаҗигаләреннән белүебезчә, бу дәүләт дөньяның иң куркыныч сейсмик төбәгендә урнашкан.

Утраулар үсемлек һәм хайваннар дөньясының уникальлегенә, үзенчәлегенә зур тәэсир ясаган. Биредәге атауларда имезүчеләрнең – 270, кошларның – 800, күбәләкләрнең 600 төре исәпләнә.

Шунысы кызык: Япон утрауларын хәтта макака маймыллары да үз иткән. Алар төньяк атаулардагы кышкы шартлардан да курыкмаска өйрәнгән. Маймыллар салкынрак көннәрдә кайнар су – гейзерлар чыганагыннан хасил булган күлләрдә коенып-җылынып рәхәтләнәләр.

Япониянең калган дөньядан аерылып, изоляциядә яшәве, күп гасырлар буе дәвам итеп, 1860-1870 нче елларга кадәр сузыла. Әмма XIX гасыр азагында бу дәүләттәге сәнәгать һәм мәдәният революциясе аның тормышын тамырдан үзгәртә. XX гасыр башында бу илнең сәнәгате гөрләп үсә башлый. Россиянең чәнти бармагыдай бәләкәй дәүләтнең 1905 елда дөньяның иң зур илен тукмап оятка калдыруын да яхшы хәтерли кешелек. Ә Икенче Бөтендөнья сугышы чорында исә Япония икътисади яктан Җир шарының иң алга киткән илен – Америка Кушма Штатларын да җәберли башлый – аның Перл-Харборда урнашкан заманча иң зур 30лап хәрби корабын батырып хур итә. Шуңа күрә мактаулы АКШ 1945 елда Гитлер Германиясен тар-мар иткән СССРны ярдәмгә чакырырга мәҗбүр була. Ачуын басар өчен, ул хәтта Япониянең Хиросима һәм Нагасаки шәһәрләренә атом бомбалары да ташлый. Кешелек дөньясы, бу халыкара җинаяте өчен АКШны хурлык баганасына терәп гаепләсә дә, дөньяның иң көчле державасын берни дә эшләтә алмый. Чөнки бөтен чал тарих буенча шулай килгән – җиңүчене хөкем итмиләр.

Япониянең әлеге ике шәһәрендәге 200 меңнән артык кешесе кырыла, калганнарында нурланыш чире башлана.

Бу хәлләрне күзәтеп торган бөтендөнья халкы ул чорда: «Япония 200 елдан соң да аягына баса алмас», – дигән фикергә килә. Күзләре чит җирләргә козгындай кызыгып караган диктатор Сталин исә, бу вазгыятьтән файдаланып, кечкенә илнең яшәү чыганагы, таянычы булган Курилл утрауларын тартып алуга ирешә. Ә Россия Көнчыгыштагы көчле, булдыклы, икътисады буенча беренче бишлеккә керүче Япония белән, бөтен дипломатия ысулларын эшкә җигеп, инде ничәмә дистә еллар дуслашырга, хезмәттәшлек килешүе төзергә тырыша. Югыйсә аңа, моңа ирешү өчен, бер генә адым ясыйсы – Курилл утрауларын законлы хуҗасына кайтарып бирәсе генә бар. Япония халкы шуны таләп итә дә бит инде.

Гасырлар дәвамында дистәләгән халыкларны канга батырып, дәүләтләреннән мәхрүм иткән империягә һаман җир җитми! Миллионлаган гектар җирләрендә бүген кырмавык һәм тигәнәк, алабута белән билчән үсеп ятса да!

1945 елгы капитуляциядән соң аякка баскан янкилар, Япониядә үзләрен хуҗа тоеп, үз сәясәтләрен үткәрә башлый, Корея сугышы чорында алар бу илне үзләренең хәрби базасы итеп файдалана. Япония исә үзенең миллиардлаган капиталын, бүгенгечә әйткәндә, инвестиция итеп, бу илнең инфраструктурасын яңадан аякка бастыруга кертә. Яңадан хәл алып, көч туплый башлаган Япон монополистлары, ни гаҗәп, АКШның кече партнеры булу белән генә канәгатьләнмичә, аның белән тигезләшергә тырыша!

Сугыштан соң үткән барлы-юклы 15 ел эчендә инде 200 елсыз аягына баса алмас дип саналган Япония җиңел автомобильләр һәм электроника җиһазлары белән бөтендөнья базарыннан АКШның үзен кысрыклый башлый!

Көлдә гөл үстергән халык

Гаҗәпләнми мөмкин түгел. Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң үткән 15-20 елда Япониядә икътисади бум туа.

Ә бит Япония утрауларында тимер рудасы, ташкүмер, газ һәм нефть бөтенләй юк! Шуңа карамастан, көлдән гөл булып үсеп киткән ил феникска әйләнә. СССРдан 100 тапкыр кечерәк булган Япония корыч һәм чуен кою, автомобильләр, электроника җиһазлары җитештерү буенча, АКШтан соң, дөньяда икенче урынга

чыга. Бу бит әкияттәгедәй могҗизалы хәл: «Үзендә бернинди файдалы казылмалар булмаган ил ничек, нәрсә хисабына моңа ирешә алган?» дигән кануни сорау туа.

Әйдәгез, моңа җавап эзләп карыйк. Япония үзенең верфьләрендә дистәләп җитештерелүче яртышар миллион тонна сыйдырышлы танкерлары, баржалары белән Австралия, Яңа Зеландия һәм башка дәүләтләрдән көне-төне нефть, ташкүмер ташый башлый. Ә үзенең утрауларында бөтен дөньяның алдынгы илләреннән сатып алынган патентлар һәм ул чордагы иң алдынгы америка технологиясе нигезендә, сугыш чорында җимерелгәннәр урынына заманча өр-яңа сәнәгать предприятиеләре төзи. Аларда хезмәт куючы эшчеләрнең хезмәт җитештерүчәнлеге биш ел – 1950-1955 нче еллар эчендә генә дә 84 процентка арта! Россия исә бу күрсәткеч белән бүгенгә хәтле мактана алмый.

Япониянең сугыштан соң кабул ителгән Конституциясендә хәрби максатларда бер иена да тотылмаска тиеш дигән маддә бар. Шуңа күрә бөтен капитал сәнәгатьне, авыл хуҗалыгын күтәрүгә һәм халыкның социаль хәлен яхшыртуга тотыла.

Кеше факторы

Япония ирешкән барлык казанышларның нигезендә кеше факторы ята. Иң мөһиме – япон халкына искиткеч хезмәт сөючәнлек һәм аек тормыш рәвеше хас. Өстәвенә, мәктәп яшеннән үк аларны әйләндереп алган мохит, чынбарлык, идеология дә шуңа ирешүгә юнәлдерелгән. Һәркайда «Безнең җирләрдә бернинди файдалы казылмалар юк. Шуңа күрә, башка илләрдән артта калмас өчен, үз көчебезгә генә ышана алабыз» дигән лозунглар күрәсең.

Завод-фабрикаларда тулы бер династияләр эшли. Бер урында хезмәт куйган өчен аларга һәр биш ел саен 10 процент арттырып түлиләр. Яңа урынга күчеп китүче исә үзенең эшен нульдән башлый. Япония предприятиеләрендә салган килеш эшкә килүне, 5 минутка эшкә соңга калуны хәтерләүче дә юк. Һәрбер эш урынында үрнәк тәртип. Чит ил делегацияләре цехлар аркылы үткәндә, аларга баш күтәреп караучы да юк.

> «Япония ирешкән барлык казанышларның нигезендә кеше факторы ята. Иң мөһиме – япон халкына искиткеч хезмәт сөючәнлек һәм аек тормыш рәвеше хас.

Мәгарифкә килгәндә исә, мәктәпләрдә сугышка кадәр үк түләүсез уку булган. Шуңа күрә ул чакта да, бүген дә урта белемсез яшьләрне эшкә алмыйлар. Илдә 350 университет исәпләнә: 100е – дәүләтнеке, калганнары хосусый. Япония бүген дә студентлар саны буенча АКШ һәм Россиядән соң, дөньяда өченче урында. Җәмәгать транспортында, метрода да күбесенең китап, газета-журнал укып барганын күрәсең. Һәрберсендә заманча иң шәп гаджетлар, айфоннар, мобиль телефоннар. Кыскасы, вакытның кадерен белү һәм бөтен мөһим нәрсәләр белән кызыксыну хас бу халыкка.

Көнкүреш һәм мәдәнияткә килгәндә, бу илдә беренче нәүбәттә өлкәннәргә ихтирамлы мөнәсәбәт күреп сокланасың. Аннары бөтен япон халкына хас булган идеаль чисталыкка игътибар итәсең. Җәмәгать урыннарында гына түгел, урам-

нарында да тузан бөртеге дә күрә алмыйсың. Аек тормыш, чисталык һәм тәртип биредә үзенең гүзәл җимешләрен бирә. Миллионлаган автомашина, җәмәгать транспорты өч дәрәҗәдә ясалган юллардан йөргәнгә, бөкенең һәм аварияләрнең нәрсә икәнен дә белүче юк. Әйе, бу дәүләтне, аңа кайсы гына яктан карасаң да, могҗизалар иле дип танымый хәлең юк.

Тагын бер кызыклы хәл: япон кызлары кияүгә чыгуга кая да булса эшкә керү хокукын югалта. Ул, балаларын карап, торагын тәртиптә тотып, иренә хезмәт итеп, өендә генә яши. Бүгенгечә әйткәндә, үзизоляциядә, өендә генә утыра! Шуңа күрә Япониядә ясленләр, балалар бакчалары юк. Ирләрнең гаиләсен матди яктан тулысынча тәэмин итүе хатын-кызның социаль хәлен билгели.

Япон хатыны, иртәнге 5ләрдә торып, ире өчен аш-су әзерли. Аннары, иренең караваты-ятагы янына килеп, аның яраткан җырын суза. Ире күзләрен ачып карауга, ул: «Торыгыз, әфәндем, Сезне бөек эшләр көтә!» – дип, аның кәефен күтәреп җибәрергә дә онытмый. Аннары ире, урыныннан торып, юынып-киенеп, өстәл янына ашарга утыргач, янында басып елмаеп тора һәм соңыннан: «Хуш, әфәндем, исән-сау әйләнеп кайтыгыз!» – дип, башын идәнгә хәтле иеп озатып кала.

Япон кызларының кияүгә чыкканчы сакура чәчәге кебек чибәр булуына күпләрнең игътибар иткәне бардыр. Алар төрле илләрдә үткәрелеп торучы чибәрлек конкурсларында да еш җиңәләр. Әмма кияүгә чыгып, 40 яшьләр тулганда битләрен җыерчык челтәре бизи башлый. Иренә колларча хезмәт, бала карау, өйне тәртиптә тоту, яшь баласын аркасына аскан килеш кибетләрдән кирәк нәрсә алырга йөрү эзсез калмыйдыр шул. Ә аны иртә картайтучы социаль халәте иренә бер кыек сүз дә әйтә алмыйча, колларча кимсетелгән хәлдә яшәвеннәндер дип уйлыйм.

Безнең хатын-кыз бит иренә, әфәнде, дип, көлеп, киная белән генә эндәшергә мөмкин. Чөнки ул да ире кебек үк предприятие яки оешмада эшли, өстәвенә, аш-суын да әзерли, балаларын да карый, өйне дә тәртиптә тота. Шуңа күрә Россия хатын-кызы кайчак салып, соңга калып кайткан «әфәнде»сен, уклау алып, кызган табага да бастырырга мөмкин. Әйе, безнең илдәге хатын-кыз, шундый шәп эмансипацияләгәнгә күрә, үзен бик бәхетле тоеп яшидер. Чөнки без, ирләр, әллә нинди революцияләр, үзгәртеп корулар үткәрә-үткәрә, бүген менә шундый «бәхетле» көнгә ирештек тә бит инде.

Сүз башым бит Шүрәле, дигәндәй, япон халкының кухнясына, туклануына килгәндә исә, бөтен яктан диңгез һәм океан сулары белән уратып алынганга күрә, ашамлыкларының төп өлешен диңгез ризыклары тәшкил итә. Аларда кеше организмы өчен бик файдалы витаминнар һәм микроэлементлар мул булу халыкның сәламәтлегенә, гомер озынлыгына тәэсир итүе бәхәссез.

Сәүдә мәсьәләсенә тукталганда, иң элек шунысын әйтергә кирәк: һәркайда уңышлы эшләп килүче кибет-супермаркетларда сатып алучыга карата зур игътибар һәм ихтирам хөкем сөрә. Биредәге кибетләрдә төрле товар һәм азык-төлекне, сатулашып, арзанракка да алырга мөмкин. Чөнки сәүдә нокталарының күбесе хосусый-шәхси. Клиент 5 сумлык әйбер алса да, аны, 500 сумлык нәрсәләр алгандай, кат-кат башларын иеп, рәхмәт әйтеп озатып калалар.

Балаларга алдарак билгеләп үткәнчә, спартан тәрбиясе бирәләр. Узындыру, артык иркәләү, җәлләү дигән нәрсә юк. Кечкенәләргә, син алай бул, син болай бул, тегеләй түгел, болай эшлә, дип вәгазь укучылар да күренми.

Озын сүзнең кыскасы, ерактагы якын күршебезнең булдыклы, тәртипле уникаль халкыннан күп нәрсәләргә өйрәнергә кирәк икән әле безгә. ■

Җиңүгә – 75 ел!

Үлемсез батальон солдаты

Ирек Нигъмәти

Минем кадерлеләрем – әнием, хезмәт ветераны Файзә Зәйнулла кызы белән әтием, Бөек Ватан сугышы ветераны Гарифулла Нигъмәтҗан улы. 1947 ел.

Әтием Гарифулла Нигъмәтҗанов Биектау районының Абсабаш авылында туып үскән, Ходай тарафыннан бирелгән гомерен мәгънәле итеп үткәргән кеше иде. Сугышка чакыру кәгазе аңа Бөек Ватан сугышы башланган көнне, 22 июньдә үк тапшырыла. Бу хакта әтинең 1944 елда сугышта яралану сәбәпле бирелгән демобилизация кенәгәсендә язылган. 23 июньдә әти ул чакта район үзәге булган Дөбьязда медкомиссия уза һәм тәгаенләнгән командасы белән Мари ягындагы яманаты белән бөтен илгә даны чыккан Суслонгер хәрби әзерлек лагерена җибәрелә. Монда 31 нче укчы бригада өчен һәр ярты ел дәвамында кече командирлар – кече лейтенантлар әзерләнергә тиеш була. Әтиләр килгәндә, лагерь солдатлар кабул итәргә төзелеп бетмәгән була әле. Ул бары тик 1 сентябрьдә генә файдалануга тапшырыла.

– Без кеше аларынып сөйли торган андый шәрә ачлык күрергә өлгермәдек, – дип сөйләгәне истә калган әтинең. – Солдат ашы кайда да бер инде. Бәлки, безнең төркемне, бер ай эчендә тиз генә өйрәтеп, Ленинградны сакларга җибәрергә тиеш булганнардыр. Мине 96 нчы аерым инженер-сапер батальонына кече сержант итеп билгеләделәр. Командирлар безне сугыш кырына мина куярга, аны минадан тазартырга, дотлар һәм дзотлар төзергә, күперләр салырга, аларны шартлатырга һәм,

әлбәттә, мылтыктан атарга, граната ыргытырга өйрәттеләр. Әзерлек иртә таңнан башланып, урманга салкын төшкәнче бара иде.

Әти, бәлки, Суслонгер ачлыгын да күргән булыр иде. Солдатлар бетли башлагач, ул командирына мунча салырга теләге барлыгын белдерә. Рөхсәт алгач, берничә коралдашы белән ике көндә мунча салып куя алар. Шундый осталыгы барлыгын белгәннән соң, аны батальон командиры үзенә чакырта.

Әтинең сөйләгәнен сүзен-сүзгә хәтерлим:

– Командир – урыс кешесе – тонык кына ут янган бер нәни бүлмәдә утыра иде, – дигән иде ул. – Килүемне белдереп рапорт биргәч, ул миңа күтәрелеп карады да: «Ну что, Гарифулла, воевать будем?» – дип, бер генә сорау бирде. «Будем!» – дип җавап бирдем. Ул миңа иртәгесен юлга кузгаласын җиткерде.

...1941 елның 2 августында алар баржа белән Ладога күлен кичеп чыга. Фашистлар Ленинградны блокадага алырга 37 көн калган була – ул тимер боҗрага 8 сентябрьдә алына. Шулай да баржа өстеннән түбәннән генә, һавага ачы керосин исе таратып, солдатлар йөрәгенә сугыш уты салып, немецларның разведка самолеты очып уза.

Әтине Ленинградны сакларга сугышка әзерлексез солдатлар туплануы гаҗәпләндерә. Аларның берәүләре мылтыкны беренче тапкыр күрә, икенчеләре исә аяк чугын (портянка) да бәйли белми. Кыш җитүгә, ашарга җитмәве сиздерә башлый. Алай гынамы, атарга мылтык йә патрон, өскә кияргә җылы кием булмый. Әллә диверсия, әллә корал заводында эшләүче хәлсез сабыйлар кулы – корал әрҗәләренең кайберләрендә винтовка урынына металл йомычкасы тутырылганлыгы да беленә. Шунысына гына сәерсенәм: солдатларның ни сәбәпле ашарларына булмый? Тылда бу вакытта авыл халкы көне-төне фронт өчен эшли бит. Кырыс законнар күзәтүендә, дәүләткә икмәк, ит, сөт, йомырка һәм башка азык-төлек тапшырыла. Алар кая киткән соң? 1942 елның 11 июнендә, үзара килешү нигезендә, Америка СССРга ленд-лиз буенча хәрби ярдәм күрсәтә башлый. Фронтка ерак Америкадан хәрби техника, азык-төлек, кием-салым, медикаментлар, кораллар агыла һәм ул 1945 елның июненә кадәр дәвам итә.

Әтинең гомере буе Кронштадт диңгезчеләренә хөрмәте зур булды. Алар батальоны Ленинградны Фин култыгы ягыннан саклый. Бервакыт фашистларның бик зур көче Финляндия ягындагы биеклектән безнең үзәндә урнашкан солдатларны бөтен төр коралдан утка тота башлый. Кызылармиячеләргә баш күтәрергә дә ирек бирмиләр. Күз алдында йөзләрчә солдатларның гомере киселә. Шунда безнең элемтәчеләр Кронштадт диңгезчеләреннән ярдәм сорый, аларга дошманның ут нокталары урнашкан координатларны җиткерә. Диңгезчеләр санаулы минутлар эчендә фашистларның көлен күккә очыра.

«

– Ну что, Гарифулла, воевать будем? – дип, бер генә сорау бирде. «Будем!» – дип җавап бирдем.

Әтием, батыр солдат Гарифулла Нигъмәтҗанов, заманына күрә укымышлы кеше була. Казандагы «Касыймия» мәдрәсәсендә укый ул. Бу хакта белгән командование аны батальонда политагитатор итеп билгели. Әти казакъ, үзбәк, таҗик солдатларының гаиләләренә хатлар яза, өйдән килгән хатларын укып бирә. Беркөнне политрук әтигә партиягә керүне бурыч итеп куя һәм кулына Партия уставын тоттыра. Әмма әтиебез Коммунистлар партиясенә керүдән баш тарта. Моны Аллаһы Тәгаләгә хыянәт итү дип кабул итә ул.

– Ә командирларыңа нәрсә дип җавап бирдең? Сугышта партиягә кабул итү бик җитди куелгандыр бит? – дип сораган идем мин әтиемнән шул чакта.

Әти мыек астыннан гына елмайды.

– Аз гына хәйләгә бардым, – диде ул. – «Уставны укып чыктым. Үзеңне андагыча тоту өчен изге булырга кирәк, миңа бу сафта булырга иртәрәк әле», – дип җавап бирдем. Артык бәйләнеп тормадылар. Батальонда абруем зур иде. Мине казакъ һәм үзбәк егетләре: «Әкә», – дип кенә атап йөртте. «Әкә, безнең сугыштан исән-сау чыгуыбызны сорап дога кыл әле», – дип киләләр иде алар минем яныма. Югыйсә сугышка бергә керәбез инде.

Әтием сугышта бик зур батырлыклар күрсәтә. Ул командирларына күп тапкырлар дошман көтмәгән-уйламаган якта мина кырлары булдырырга тәкъдим итә. Тапкырлыгы һәм кыюлыгы өчен, әтием иң беренче сугышчан бүләгенә – «Батырлык өчен» медаленә лаек була. Заманында атаклы Батырша газап чиккән Шлиссельбург кирмәнен фашистлардан азат итүдә күрсәткән батырлыгы өчен, иң югары солдат ордены – III дәрәҗә сугышчан «Дан ордены» белән бүләкләнә. Ә II дәрәҗәле шул ук «Дан ордены» аны фашистлар корган мина кырын чистартуны югалтуларсыз оештырганга бирелә. Әти бу вакытта отделение командиры була.

Безгә каршы, немецлар белән бергә, финнар да сугыша. Аларны әти бик төз атучы, мәргән халык дип сөйли иде. Безнең разведчикларның хәрби задание белән урманга кереп юкка чыгуларыннан әйтә иде ул аны. Аларны агач башларына урнашкан фин «күке»ләре – снайперлар шулай чүпләп утырган.

Бервакыт лазаретка әсир төшкән яралы фин солдатын алып киләләр. Әмма теге әсир безнең докторны шулхәтле дошман күрә ки, хәтта ярдәм итәргә сузылган кулын тешләп ала. Безнең табиб та кимен куймый – дошман солдатын пистолетын чыгарып шундук атып үтерә.

> **«Безгә каршы, немецлар белән бергә, финнар да сугыша. Аларны әти бик тә төз атучы, мәргән халык дип сөйли иде.**

– Мин бу минутта үзебезнең табиб яклы булдым, – дип сөйләгән иде әти әлеге хәл турында. – Әсирне үтергән өчен особистлар табибны хөкемгә тартырга да теләгәннәр иде. Янәсе бик кирәкле «тел»не юк иткән. «Аның шул кулы белән күпме солдатларны дәвалыйсы бар!» – дип кычкырдым мин шулчак НКВДышникларга. Табибка да, аны яклаган өчен миңа да кагылучы булмады. Кайсы вакытта юк кына сүз дә кеше язмышын хәл итә.

Әти сугышта өч тапкыр яралана. Саперлар арасында: «Сапер бер генә ялгыша», – дигән гыйбарә бар. Ике тапкыр яраланып, госпитальгә эләккәннән соң, палатадашлары (ә алар диңгез авиациясе очучылары була): «Сиңа, Гариф, өченчесендә нәрсәдер була, син болай да саперлар тәртибен бозгансың», – дип шаярталар. Чынлап та, өченче тапкырында әти бик каты яралана. Мина ярчыгы аның башын яралый, бер күзен югалта. Шулай итеп, әти хәрби хастаханәдә 4 ай дәваланып чыга. 1944 елның 27 гыйнварында Ленинградның фашистлар блокадасы өзелүен бәйрәм салютлары белән билгеләп үтүне күрү насыйп була аңа. Ленин шәһәрен саклаганда күрсәткән батырлыклары «Ленинградны саклаган өчен» медале белән бәяләнә. «Ватан хакына кан түккән өчен» дип язылган бүләкләү кенәгәсе миндә әле дә саклана. Туган авылы Абсабашка 1944 елның маенда гына кайтып җитәргә насыйп була аңа. Оныгы – генерал-майор Линар Нигъмәтҗанов легендар солдат бабасы Гарифулла Нигъмәтҗановның данлы эшен хәзер дә дәвам итә – Ватанның иминлеген саклый. ■

Истә, һаман да истә!

Язучы
Мәҗит Гафуриның
тууына 140 ел



Шагыйрь, прозаик, публицист һәм драматург Мәҗит Гафури 1880 елның 1 августында Уфа губернасының Эстәрлетамак өязендәге Җилем-Каран авылында укытучы гаиләсендә туган.

Ул яшьли ятим кала. Авыл мәдрәсәсендә укый. Уралда (шул исәптән Рәмиевләрнең алтын приискаларында) сезонлы эшләр башкара.

М. Гафури 1898 елда «Рәсүлия» мәдрәсәсенә (Троицк шәһәре) укырга керә. Җәйләрен приискаларда, казакъ җәйләүләрендә көнлекчелектә эшли.

1905 елда Казанга килә, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керә.

1906 елдан Уфада, 1909 елга кадәр «Галия» мәдрәсәсендә белем ала.

1902 елда дини фанатизмны фаш иткән «Ишан хәзрәтләренә» исемле беренче сатирик шигырен яза.

Башлангыч чор лирикасы «Гафури шигырьләре» (1909), «Тәэссоратым» (1909), «Моң вә зар» (1911) җыентыкларында тупланган.

1927 елда язылган «Кара йөзләр» повесте М.Гафурины күренекле язучы итеп таныта.

Ул 1934 елның 28 октябрендә Уфада вафат булды.

Галим
Фуат Ганиевнең
тууына 90 ел



Тел галиме, ТАССРның (1989) һәм РФнең атказанган фән эшлеклесе (1994), Татарстан ФАнең мөхбир әгъзасы, Россия Гуманитар фәннәр академиясе академигы, ТРның фән һәм техника өлкәсендәге дәүләт премиясе лауреаты (1994) Фуат Әшрәфҗан улы Ганиев 1930 елның 1 августында (кайбер чыганакларда – 31 июльдә) Башкортстанның Салават районындагы Нәсибаш авылында туган.

Аның бөтен гыйльми эшчәнлеге һәм тормыш юлы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән бәйле. Ул 1963 елда – кандидатлык, 1977 елда докторлык диссертацияләрен яклый.

Ф.Ганиевнең фәнни эшчәнлеге гаять күпкырлы, ул – 300дән артык гыйльми хезмәтләр авторы. Ф.Ганиев татар телендә сүз ясалышы һәм грамматика буенча 17 монография чыгарган; лексикография тармагы буенча төп белгеч буларак, бик күп сүзлекләрнең оештыручымөхәррире һәм автордашы: «Татарча-русча сүзлек» (1966), «Русча-татарча сүзлек» (1971), «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (1977-1981), «Татарча-төрекчә» һәм «Төрекчә-татарча» сүзлекләр (1997-1998) һ.б.

Ул 2016 елның 28 февралендә Казанда вафат булды.

Язучы
Халикъ Садриның
тууына 130 ел

Язучы Г.-Халикъ Садри (Габделхаликъ Гариф улы Садретдинов) 1890 елның 4 августында Самара губернасының Богырыслан өязендәге (хәзерге Куйбышев өлкәсенең Клявлин районы) Иске Ярмәк авылында ярлы крестьян гаиләсендә туган.

1913 елда Уфа матбугатында аның «Тегермәндә» исемле беренче хикәясе басылып чыга.1919 елда иҗат ителгән «Унике ел төрмәдә» исемле пьесасы шул елларда сәхнәләрдә куелып йөри.

Г.-Халикъ Садри Бөек Ватан сугышы елларында, полк хәрби комиссары буларак, фронтның алгы сызыгында сугыша, яралана, шәхси батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз, Икенче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә. Армиядән кайткач, Г.-Халикъ Садри СССР әдәби фондының Татарстан Язучылар союзындагы вәкиле булып эшли.

Әдипнең сугыштан соңгы әдәби иҗатыннан «Йөзмә госпитальдә» (1950) исемле очерк-хикәясен, драматург Әнәс Камал белән бергә язган «Юллар» (1950) дигән сәхнә әсәрен күрсәтеп үтәргә мөмкин. Шулай ук аның курчак театрлары өчен «Камал бабай әкияте» (1951) дигән пьесасы да бар.

Г.-Халикъ Садри 1955 елның 8 мартында Казан шәһәрендә вафат булды. Ул 1939 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы иде.

Артист
Мөхит Кичүбаевның
тууына 110 ел

Актер, режиссер, ТАССРның халык артисты (1957) Мөхит Әхрар улы Кичүбаев 1910 елның 16 августында Пермь губернасының Кызылъяр өязендәге Сыскы авылында туган.

1936 елда Минзәлә колхоз-совхоз театрында (1957 елдан – Минзәлә татар дәүләт драма театры, 1996 елдан – С.Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры) эшли башлый.

М.Кичүбаев – Минзәлә театрына нигез салучыларның берсе.

Ул 1939 елда Мәскәүдә Колхоз-совхоз театрларының Беренче бөтенсоюз фестивалендә катнаша.

Уйнаган рольләре: Госман («Козгыннар оясында», Ш.Камал), Гаяз («Чаткылар», Т.Гыйззәт), Зариф («Ил өчен», Р.Ишморат), Гобәй («Һәйкәл», Ә.Баян), Шәйхнур («Язылмаган законнар», Ю.Әминов), Бәдри («Галиябану», М.Фәйзи), Морат («Рәйхан», Н.Исәнбәт) һ.б.

Ул 1979 елның 24 июнендә Казанда вафат булды. ■

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.*

Безнең мирас №8 август 2020

Иҗат мөһере

Рәдиф Сәгъди

Татарстанның халык артисты Илгизәр Галимҗан улы Хәсәнов

Илгизәр Галимҗан улы Хәсәнов белән без 1969 елны затлы 113 нче татар мәктәбенең коридорында таныштык. Ул бина Киров районының бик матур почмагына – Халтурин белән Фрунзе урамнары кисешкән тау башына урнашкан. Тәнәфестә укучылардан берсе яныма килеп: «Анда стена газетасы чыккан, синең шигырьләрең дә бар», – дигәч, танышыр өчен шул тарафка юнәлдем. Менә ул мәктәп балаларының иҗатын чагылдырган, айга бер мәртәбә чыга торган чуар газета. Балалар язган шигырьләр, рәсемнәр белән тулган калын ватман кәгазенең бите. Шулай итеп, тәнәфестә әлеге басмага күз салып торганда, яныма чем-кара калын чәчле (әле бөдрә дә иде бугай) бер укучы килеп басты. Бер миңа, бер газетага карый-карый, түзмәде: «А что, и по-татарски понимаешь, да?» – дип аптырап, мине гаҗәпләндереп сорап куйды.

– Моңа хәтле дә белә идем! – дип җавап бирдем тегеңә.

– Кайсы класстан соң син?! – дип кабат аптырый әлеге бөдрә чәч.

– Алтынчы «Б»дан, – дим.

– Алтынчы «Б»дан? – ди бу, шикләнебрәк.

– Әйе! Быел гына сезнең мәктәпкә килдем әле мин!

– Ә, менә ничек! Таныш булыйк, мин – Илгизәр, – дип, кулын суза бу. Аннан: – Гафу ит, хәзер мәктәпне урыс класслары белән тутыра башладылар. Шуларның берәрсе, ахры, дип уйлаган идем. Рәдиф инде алайса исемең. Тукта, тукта, әллә бу шигырьләр дә синекеләрме? – дип тә өсти.

– Әйе!

– Шәп! Ә менә болары минем рәсемнәрем, – ди ул, Шүрәле һәм Су анасын чагылдырган сурәтләргә төртеп күрсәтеп. Шулчак, әңгәмәбезне өзеп, дәрескә чакырып кыңгырау оран сала.

– Кайсы мәктәптән килдең соң? – дип сорый Илгизәр, дәрескә ашыгып.

– Кама Тамагының Балчыклы авылыннан мин, – дим тегенең артыннан.

Ул, борылып:

– Балчыклыданмы? – дип гаҗәпләнеп кайтарып сорый. – Алайса күрешербез әле берәр көнне дәресләрдән соң.

Озак та үтмәде, соңгы уку көнне – чираттагы шимбәдә эзләп тапты ул мине. Кул биреп күрешүгә:

– Сине әтинең дә, тәтәнең дә күрәсе килә, бүген безгә кайта алмыйсыңмы? – диде.

– Мин бит кайда торганыгызны да белмим, – дидем, гаҗәпләнеп. – Ә нәрсәгә? – дип тә өстәдем.

– Килгәч белерсең! Бергә кайтабыз, соңыннан үзем озатып та куям, – дип, шикләремне таратырга ашыкты.

Галимҗан абыйлар Җиләкле базарының артына урнашкан Грязнушка бистәсендә яшиләр икән. Тирә-юне гел сазлыклардан торганга, әллә ни балчыгы булмаса да, шулай дип йөртәләр. Нишләп Болотная дип атамаганнардыр?.. Болотников урамы элегрәк булу сәбәпле, Грязнушка дигән исем кушканнардыр, күрәсең. Югыйсә, күпме генә яңгыр яумасын, комга сеңеп бетеп бара иде. Машиналар буксовать итеп, балчык ябышкан резина итекләр сөйрәп йөргәнне күрергә туры килмәде биредә.

Урамнарында үзеңне татар авылына эләккәндәй тоясың, авыз тутырып, колакны рәхәтләндереп татарча сөйләшә бистә халкы. Илгизәр әйтә: «Мондагы урыс балалары да, безнең белән аралашып үскәч, чип-чиста татарча беләләр», – ди. Әлбәттә,

Күренекле сәнгать җитәкчесе, режиссер Әнвәр Әхмәдуллин Казанның 113 нче мәктәбендә укучы шәкертләре белән. Уңнан беренче – Илгизәр Хәсәнов. 1971 ел

Илгизәр Хәсәнов (сулдан өченче) Рәдиф Сәгъдинең «Яз галәмәте» комедиясе буенча куелган спектакльдә Инфир ролендә. 2000 ел

саладан яңа гына аерылып килгән бала күңеленә рәхәтлек өсти бу хәл! Өстәвенә, урысчасы да әлегә ипи-тозлык кына.

Илгизәрнең әнисе урта бүлмәгә чәй өстәле әзерләгән, тәмле шулпа исе таралып, борынны кытыклый. Бибинур апа, елмаеп, ачык йөз белән каршы алды.

– Барыгыз, улым, кулларыгызны юып алыгыз да, тамагыгыз ачып кайткандыр, капкалап алырсыз, – ди.

Аннан түр бүлмә ишеген ачып:

– Галимҗан, көткән кунагың килде, чыгасыңмы, – дип эндәшә.

Озак та үтми, олпат гәүдәле, култык таяклы абзый үзе күренә. Хуҗаның бер аягы юклыгын чамалап алам. Баштан: «Сугышта югалткандыр, ахры», – дигән уй йөгереп үтә.

– Ни хәл, Зәйнет абый белән Фәгыйлә апа оныгы, – дип сәлам бирә ул.

«Каян белә соң ул минем әби-бабайларымны?» – дип аптырыйм.

– Димәк, Гөлчирәнең улы син буласың, – дип бөтенләй гаҗәпләндерә ул мине.

– Аптырама, улым, мин үзем дә Балчыклы авылыныкы, Бибинур апаң исә күрше Олы Бортастан.

Шатлыгым эчемә сыймый. Үзебезнекеләр икән бит!

Илгизәрнең әнисе бик тәмле итеп пешерә белә иде, ул безне:

– Әтисе, дим, әйдә, табын артына утырып гәпләшегез әле, балалар мәктәптән ачыгып кайтканнардыр, – дип, өстәл янына дәшә.

Аннары кызына эндәшә:

– Әлфинур, син тәтәңне чакырып чыгар Салихҗан абыйларыңнан, Рәдифне ул да, күреп каласым килә, дигән иде.

Без зур өстәл артына урнашабыз.

– Син дә Зәйнет абый кебек мәзәкчәнме? Ул бит безнең Балчыклы авылының Хуҗа Насретдины. Ә Фәгыйлә тәтәңнең пешергән ризыклары тел йотарлык иде, – ди.

Миңа шундый рәхәт, әйтерсең, якын туганнарым арасына эләктем. Озак та үтми, күршеләренә хәл белергә кергән Бибикамал тәтә дә, оныгы Әлфинурны култыклап, өлкәннәргә хас салмак адымнар белән кайтып керә. Ул Галимҗан абыйның әнисе булып чыкты. Димәк, Бибикамал тәтә дә безнең Балчыклыныкы! Әби мине кочып ук ала, күз яшьләре белән:

– Әй, улым, улым, син Әхмәтсафа бабаңның оныгының оныгы икәнсең бит. Зәйнет дәү әтиең, Фәгыйлә тәтәңнәр ни хәлләрдә соң, исән-сау гына яшәп яталармы? – ди.

Күренеп тора, Тау ягын, туган авылын сагынып яши. Үземнең дә күңелем тула, чөнки авылымны көн саен юксынам. Шәһәргә ияләшеп бетүләре җиңелдән түгел икән. Өстәвенә, русча рәтле-башлы белмәгәч, классташлар: «Колхозник!» – дип үртиләр. Үги әтием белән яшәгән әнинең дә холкы коры. Сагынмас җиреңнән сагынырсың. Ярый әле, бәхеткә, Илгизәр, аның әти-әниләре, абый һәм апалары гомер юлымда очрады.

Тора-бара, Илгизәрнең үҗәтлеге, укытучыларның тәкъдиме буенча, язмыш мине сәнгать, олы иҗат белән бәйләде. Алтынчы класста башланган дуслык бүгенгәчә дәвам итә! Ул – танылган артист, мин – язучы, драматург! Ләкин әле бу көннәргә килеп җиткәнче, олы, озын-озак сикәлтәле юллар үтәсе бар иде безгә!..

Театр түгәрәге

Сигезенчедә укыганда, мәктәбебезнең данлыклы директоры Рәшидә Мәрдән кызы Еникеева тырышлыгы белән, балалар өчен театр түгәрәге ачылды. Аңа кадәр бокс белән дә шөгыльләнә башлаган идек, сугыш бияләйләрен спорт залы тәрәзәсеннән кереп урлап чыктылар. Шуннан соң тренерыбыз Рылов, ничек утырып килгән булса, урындыгына сарык тиресе җәелгән «Ява» мотоциклын үкертеп, үпкәләп китеп тә барды. Каракны, күпме эзләсәләр дә, таба алмадылар. Күп булса бер айлап шөгыльләнеп калдым микән, ләкин, урысча әйткәндә, авыз-борын җимерергә хватило! Хәтта ул секциянең ябылуына шатланып та куйдым әле. Үзем ташлап качсам, куркакка санарлар иде.

Шундый көннәрнең берсендә безгә музыка дәресе бирергә легендар Рифкать Гомәров килде. Ул, биредәге талантлы, чибәр татар кызларын җыеп, «Саз» ансамблен оештырып җибәрде. Икенче бер яңалык – балалар театры да эшли башларга тора икән! Шул яңалыкларны җиткерергә класска Илгизәр белән Мансур дусларым кереп, коридорга чакырып чыгардылар.

– Әйдә, театр уйнарга, гармунда да сыздырасың, җырлый да беләсең! – дип үгетли башладылар.

Дусларга каршы килеп булмый, өстәвенә, кирәк чакта терәк тә була беләләр, ризалык бирдем. Илгизәр белән Мансур яңа шөгыльгә җиңел кереп киттеләр. Әтисез үскәнгәме икән, тәвәкәллек җитмәү, оялчанлык комачаулый. Халык алдына чыгып тамаша кыласы барлыгын уйлыйм да, суга эләккән ипи кебек, җебим дә төшәм. Аяккулларыма кадәр калтырый, авызымнан рәтле-башлы сүзем чыкмый. Мине порукага Илгизәр ала. Йә аларга кайтып, йә безгә кереп, минем белән рухи яктан да, иҗат ягыннан да репетиция ясый. Шулай итеп, алдагы елларда гел алдынгы урыннар гына аласы төркем барлыкка килде. Талантлы тере балалар тупланган иде аңа. Мансур, Шамил, Ильяс, Фәүзия, Мәдинә һәм мин ошбу төркемнең тоткасы булдык. Илгизәр исә – иң әйдәп баручы артистларның берсе. Ул бөек шагыйребезгә багышланган пьесада Габдулла Тукайны уйный, Фәүзиябез «Беренче театр»да Биби ролен башкарса, Илгизәр – икенче герой Фатыйхны. «Мулланур Вахитов»та төп каһарманны Мансур Бикмуллин шәп итеп уйнаса, Илгизәр монда да төп рольләрнең берсен – комиссар Орловны башкарды. Ә режиссерыбыз Әнвәр ага Әхмәдуллин мәктәп директорының зур табышы иде. Ул безнең белән үзешчән сәнгатьчә түгел, профессиональ артистлар белән эшләгәндәй хезмәт куйды. Шундый талантлы, ыспай гәүдәле шәхеснең нишләп Академия театрына барып актер булып хезмәт итмәве безне гаҗәпләндерә иде. Ул бит М.Сәлимҗанов, П.Исәнбәтләр белән бер дәрәҗәдә аралашып яшәде. Аны санлыйлар, олылыйлар, без куйган әсәрләрне килеп карап, зур бәя биреп китәләр иде. Әнвәр ага үзе дә талантлы балалар туплый алганына сөенеп эшләде. Тыйнак, тәртипле Илгизәрне

якын туганыдай күрә иде. Чөнки шәкерте үзенә тапшырылган рольләрне һәрчак тырышып эшли, режиссер биргән алымнарны тиз үзләштерә, тыңлаучанлыгы, максатчанлыгы белән аерылып тора. Без генә җилбәзәкләрчә кыланабыз: шаярабыз, хихылдыйбыз. Аеруча Шамил белән мин! Илгизәрнең, ачуы чыгып: «Җиттеме сезгә, юкмы, эшләргә комачаулыйсыз!» – дип әйтеп куюлары гына безне дә тәртә арасына кертә.

Илгизәр Галимҗан улы шул чорларда гына да дистәләгән рольләр башкарды. Мәктәп бәйрәмнәрендә театр гына уйнап калмыйча, Г.Тукайның дистәләгән шигырьләрен яттан сәнгатьле итеп сөйли белә иде ул. Илгизәр җаны-тәне белән сөйде театр сәнгатен. Ул гына да түгел, Петров паркында урнашкан «Татарстанның 10 еллыгы» дип аталган гүзәл сәнгать сараендагы Халык театры коллективына да барып, кемдер башкарып чыга алмаган рольләргә алынып, спектакльләрне коткарып калгалады. Үзе белән мине дә шунда тартты. Ул коллективның режиссеры Гөлсем апа бездә татар театрының киләчәген күрә иде.

Кәсеп

Кыш якынлашкач, әни белән үги әти минем башка күн тышлы, йон эчле бүрек алып кидерде. Шуны мәктәпкә киеп барырга бик гарьләнә идем. Кая барасың инде, атаң үзеңнеке булмагач. Сигезенчедә укыганда Илгизәр мине, гадәттәгечә, үзләренә мунча керергә гел чакырып торды. «Әйдә, әтинең дә үзеңне күрәсе килә, тәтә дә сагынган», – ди торган иде. Хәсәновлар миннән чакрым ярым тирәсе ераклыкта торалар. Ә мин яшәгән йорт Киров районының кыл уртасында. Аста универмаг урнашкан «сталинка»ның бишенче катында яшибез. Каршыда – дары заводыннан калган тарихи кызыл капка. Янәшәдә – төрле аттракционнары булган Петров бакчасы. Йортыбызның арткы ягында – Химия-технология техникумы, аннан арырак исә зур ашханә урнашкан. Мин шулар яныннан узып китеп, Болотников урамына юл алам. Җиләк базарына борылып төшәм дә, ниһаять, күңелгә якын авыл күренешләре башлана. Хәзер миңа биредәге җирле зимагурлар да бәйләнә алмыйлар, чөнки ничә мәртәбә Илгизәр белән Мансур янәшәсендә күрделәр. Кайчагында табылсалар да, Илгизәр дустымның бертуган абыйсы Гаделҗан Хәсәнов исемен атау да җитә. Биредә дә үз авылымдагы кебек хәзер миңа. Грязнушка бистәсенең яртысы минем якташлардан тора икән. Яшәгән саен, аралашу көчәя бара. Илгизәрнең төрле бәйрәмнәргә гармун уйнарга чакырып торуы да мине җирле халыкка ныклап танытты. Тора-бара, дустыма ияреп, кая кунакка чакырсалар, гармун гел кулымда булды. Үзем дә «местный»га әйләнеп беттем диярлек.

Шундый көннәрнең берсендә Галимҗан абый хәл-әхвәл сорашып утырды. Ул, гадәттәгечә, Зәйнет бабамны да искә алды:

– Беркөнне әти мине чакырып алды да: «Улым, Зәйнет абыеңнарга төшеп, бурычка биреп торган акчамны гына алып мен әле», – дип җибәрде.

Төшәм! Зәйнет абыйны күрәм!

«Улым, әле бүген төнлә генә печатать иттем, әле Фәгыйлә түтәң кибәргә элеп куйган, Хәсән туганга әйт, кипшегәч, үзе менгерә диярсең!» – дигән сүзләрен кайтып әйттем. Ул да түгел, Зәйнет ага үзе дә килеп җитеп, бурычын кайтарды. Ахры, балачагага биреп, җаваплы буласы килмәгәндер инде, үз кулы белән алганны үз кулы белән тапшырды. Шуны да искәртеп китәсем килә: Илгизәрнең бабасы Хәсән карт та бик оста пәлтәләр, туннар тегүче булган. Әнинең әйтүе буенча, кечкенә Хәсән безгә туган да тиешле, аннан Зәйнет бабам белән Фәгыйлә тәтәмнең ут кебек өлкән улларына сугыш алдыннан шул заман өчен затлы саналган пәлтә-бишмәт тә тегеп биргән икән.

...Галимҗан абый әйтә: «Илгизәр, бар, теге куян бүрегеңне алып кер әле!» – ди. Шуннан башымдагы кара күн тышлысын салдырып, миңа куянныкын кидерә. «Менә бу бүреккә бер генә ел әле, рәхәтләнеп ки! Югыйсә артист булып йөрисең, әллә нәрсә элгәнсең шунда!» – дип үсендерә. Мин дә, Илгизәр дә аңламыйчарак торабыз. Галимҗан абый, безнең кыяфәтләрне күреп, серле генә елмая да: «Сиңа, улым, яңасын тектем, туган көнеңә дә булыр, ә монысын Рәдифкә бирәбез!» – ди. Мин инде ул бүреккә күптән сокланып йөри идем. Иптәшемнән алып киеп караганым да бар. Шундый җиңел, йомшак мамыклары колакларыма хәтле назлап иркәли, рәхәтлек бирә. «Әлегә шунысын кия тор, тиздән биш-алты куянның тиресен эшкәртәсем бар, бер бүрекне сиңа җайлап тегәм. Әниеңә әйт, йөртмәсен артист, баянчы малаен бу кыяфәттә! Югыйсә рәтле-башлы кызлар карамаслар үзеңә, – дип тә шаярта. – Зәйнет абый оныгына килешми шулай йөрергә! Тик яңасын сиңа бушлай биреп булмас, 15 сумга бик шәт булыр», – дип, күңелемне тагын бер кат үсендереп куя. Ул куян бүрекләр бит базарда 30-40 сум тора, әле мондый затлысын табуы анда да җиңел түгел. Тегүче Хәсән бабайның улы Галимҗан абый да балта остасы да, затлы бүрекләр тегүче дә иде. Галимҗан ага өйләрен, мунчаларын, сарайларын, хезмәт инвалиды булуына карамастан, үзенең сөялле куллары белән салган, койма-рәшәткәсен дә үзе тоткан. Бу йортта, ни сәбәпледер, миңа да урын бар, биредә миңа да рәхәт. Кәсепчелек алар гаиләсенә күпмедер дәрәҗәдә терәк тә. Хәсәновлар кечкенә генә җир биләмәләрендә өч-дүрт алмагач, төрле яшелчә үстерәләр, сарайларында – дистәләгән куян, тавык-чебеш. Уңган-булган, ярдәмчел, ачык йөзле кешеләр иде алар. Якты чырай, такта чәй, дигәндәй, һәрчак үз кеше идем мин биредә.

Артист юлы...

Четерекле вә сикәлтәле артист тормышы. Ярты гомерең гастроль-командировкаларда үтә. Бигрәк тә элеккеге Күчмә театр иҗатчыларына кыен, кайчагында утызар-кырыгар көн өеңдә булма инде. Ярый ла учак саклар ышанычлы тылың калса! Гаиләләләр өчен коточкыч сынаулар китергән хезмәт ул күчмә тормыш. Сәнгать корбаннар сорый ул, дигәндәй, күпчелек очракта таякның иң авыр башы гаилә бәхетенә төшә. Аерылышу-бүлешүләр сәнгать кешеләре тормышында да җитәрлек. Бигрәк тә Күчмә театрда эшләүчеләргә гаиләне саклап калу иң четерекле мәсьәләләрнең берсе. Шуңа карамастан, без, бер төркем 113 нче мәктәп шәкертләре, искитмәле талантлы режиссерыбыз юлламасы белән, 1974 елда урта мәктәпне тәмамлап, театр училищесына кердек. Шамил, Мансур һәм мин, дүртенчебез, әлбәттә, Илгизәр. Галимҗан улына тешләрең тигез түгел, дип бәйләнделәр, тимер тарттыргычлар куеп, аларны рәтләде. Дикцияң начар, диделәр, ул аны еллар буена чарлап, тиешле дәрәҗәгә җиткерде. Мин, 1984 елда Әлмәт дәүләт театрыннан кайтып, Күчмә театрга эшкә килгәндә, Илгизәр инде шактый гына рольләрдә уйный торган әйдәп баручы яшь актерларның берсе иде. М.Гафуриның «Кара йөзләр»ендә – төп каһарман Закир, Н.Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»ында – Хаммат, Ю.О'Нилның «Богауланган мәхәббәт»ендә – Эбин, Ш.Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә»сендә – самавырчы да, хәлфә дә, Шекспирның «Гаугалы мәхәббәт»ендә – Клавдио, Т.Миңнуллинның «Гармун уйный беләсеңме?» комедиясендә – Хисам, Р.Вәлиевнең «Әйдә, барыйк, кызлар карыйк» мюзиклында – Хаммат, Н.Гаетбайның «Әстәгъфирулла»сында – Даян, П.Бомаршеның «Фигароның өйләнүе»ндә – Антонио, Мольерның «Галиҗәнап де Пурсоньяк»ында – Оронт һәм дистәләгән башка рольләр бары тик анык гына буларак кабул ителә иде.



Туфан Миңнуллинның «Гармун уйный беләсеңме?» комедиясе буенча куелган спектакльдән бер күренеш. Сулдан икенче – Рәдиф Сәгъди (Мәрди ролендә), өченче – Илгизәр Хәсәнов (Хисам ролендә). 1988 ел

1977 елда дөнья күргән «Сынган беләзек» мелодрамасындагы Хафиз роле аңа багышлап язылса да, Исламия Мәхмүтова, ни сәбәпледер, Харис Төхвәтулловка тукталды. Шулай да Илгизәргә минем өч әсәремдә уйнарга насыйп булды. Аның беренчесе – «Баһадурның бәхете» әкиятенең дәвамы булган «Баһадурның яңа дуслары»ында төп геройны – Бортас атлы урам мәчесен гаҗәеп кызыклы итеп тәкъдим итте ул.

Аның иң курыкканы бию белән җырлар иде, чөнки әсәрдә андый мизгелләр бик күп. Ничек булдырасың, шулай җырла, ничек бии аласың, шулай бие, ди торгач, барысын да тиешле дәрәҗәдә башкарып чыкты Илгизәр. Чөнки аның белән бер рольдә булган икенче артистның бию һәм җырлары отышлырак чыкса, Илгизәрнең актерлык осталыгы югарырак тоелды.

Өченче пьесам – «Яз галәмәте» дигән музыкаль комедиямдә ул чын мәгънәсендә комик образ тудырды. Аның башкаруындагы Илфир – хәерче интеллигент кисәге, әллә ничә вуз бетерсә дә, бер җирдә дә озак вакыт эшли алмаган, буш хыяллар белән янып яшәүче зат. Илгизәр аның бөтен нечкәлекләрен тоеп, көлкеле образ тудырды. Р.Вәлиевнең «Әйдә, барыйк, кызлар карыйк!» мюзиклында Д.Сираҗиев режиссерлыгында куелган спектакльдә аңа Хаммат роле тапшырылган иде.

Илгизәргә, җырлый да, бии дә белми, дип, бу хәрәкәтле рольне шикләнеп, сан өчен генә биргәннәр кебек иде, репетиция барышында бу образда аны алыштырырлык партнерлары юклыгы ачыкланды. Ул әлеге рольдә үзе дә бик яратып уйнады. Эксцентричный, хыялый студентның чын мәгънәсендә күңел халәте ачылды. Сәер дә, көлкеле дә иде Илгизәр Галимҗан улы бу ролендә. Җырлар инде комедия жанрына китереп башкарыла, биюләре дә кирәкле юнәлештә иде.

Шулай итеп, күренекле актерның җыр-биюле рольләрдән шикләнүе, куркуы тарала, тәвәккәллеге арта барды. Ул үзен чын мәгънәсендә фидакарь итеп таныта алды.

1984 елда бөтен театр коллективына диярлек ипиле-тозлы Ташкент каласына гастрольгә барырга туры килде. Хәтерем ялгышмаса, ул театр көннәре айдан артык

зур уңыш белән дәвам итте. Әлмәт дәүләт театрының легендар режиссеры, фронтта алган яраларына шифа булыр дип, әлеге гаҗәеп матур шәһәргә күчеп китеп, Мәдәният һәм сәнгать университетында тугандаш үзбәк халкын сәнгать серләренә төшендерә, белем бирә иде. Ул гына да түгел, биредә эшләп килүче татар халык театры нигезендә профессиональ иҗат коллективы оештырырга дип, Үзәк комитетка әллә ничә тапкыр хатлар да юллата. Үзбәкстан җитәкчелеге, Мәскәү белән килешеп, бина да, бюджеттан акча да табарга вәгъдә бирә. Ләкин СССР дигән империянең таралуы, илдә ыгы-зыгы башлану әлеге омтылышны юкка чыгарды. Гали ага Хөсәенов безнең бөтен спектакльләребезне карап, киңәшләрен биреп барды. Ә беркөнне ул: «Рәдиф, Сания апаң Исмәгыйлева белән сезне берсекөнгә чәй табынына чакырам. Көндезге уннарга килегез, теләсәгез, тагын бер-ике кешене ал! Минем поварым сезгә үзбәк халкының иң затлы ризыкларын пешереп куяр», – дип, кунакка дәште. Үзем белән иң ышанычлы дустым Илгизәрне дә алдым. Аңа даһи режиссерыбыз белән күрешү үзе бер шатлык иде. Илгизәр моңа хәтле Гали аганы ишетеп кенә белсә, бүген турыдан-туры сөйләшеп утырачак бит. Чәйдән соң, китәр алдыннан, Илгизәр даһи режиссер Гали Хөсәен улыннан, Сезгә дәресләргә йөреп булмасмы икән, дип үтенде. Классташымның үз профессиясен бик яратуы шул гастрольдә дә күренде. Күпчелек артистлар, буш вакыты булдымы, ял паркларына, су буйларына, базарларга чапса, ул, кулына каләм белән дәфтәр тотып, Гали ага дәресләренә йөгерде. Һәм кайтып китәр алдыннан, сокланып: «Театрда күпме эшләп, аннан алган тәҗрибәне мин, гомумән, белмәгәнмен икән!» – диде. Әлеге сабаклар роль өстендә эшләүнең төп нигезләренә төшенергә бик ярдәм итте Илгизәргә. Бүгенге көндә ул – татар-башкорт халкының яраткан актеры. Заманында аксакалыбыз – драматург Р.Хәмитнең «Исәнлеккә-саулыкка» дигән пьесасында эчептиптереп ятучы түрәне уйнап, авторның соклану шаһиты булды Илгизәр. «Исерексәрхүшләрне үзләреннән дә кызыклырак итеп уйный белә, гаҗәп кәмит актер икән ул Илгизәр Хәсәнов!» – дип мактый иде драматург аны. Илгизәр, кайсы режиссер белән генә эшләмәсен – Равил Тумашевмы, Дамир Сираҗиевмы, Празат Исәнбәтме, Туфан Миңнуллинмы, Рәшит Заһидуллинмы – үз эшенә, куючының хезмәтенә хөрмәт белән каравы белән гомер бакый зур ышаныч тудыра килде. Күпчелек артистлар репетициядән репетициягә генә роль өйрәнсәләр, Илгизәр урамда да үзенә кирәкле персонажны эзләде, буш вакыты булдымы, бакчасында да, өендә дә образын чарлады. Өстәвенә, режиссерның һәрбер биргән алымын зур игътибар белән кабул итү осталыгы бүгенге көндә барыбыз тарафыннан да танылган актерның формалашуына нигез ташлары булып ятты. Профессиональ сәхнә тормышын М.Сәлимҗанов дәресләреннән башлап җибәргән актер иҗат җимешләрен халыкка мулдан өләшә.

Шуны да искәртеп китү кирәк дип саныйм: үземә дә Илгизәр Галимҗан улы белән, мәктәп, мәдәният сарае, театр училищесы сәхнәсендә генә түгел, К.Тинчурин театрында да партнер буларак бергә уйнарга туры килде. Д.Салиховның «Туй күлмәгем – соңгы бүләгем»дә, Т.Миңнуллинның «Гармун уйный беләсеңме?» комедиясендә, Ш.Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә»сендә, Н.Гаетбайның «Әстәгъфирулла»сында, Шекспирның «Гаугалы мәхәббәт»ендә, М.Галиевнең «Әлегә соң түгел» пьесасы буенча куелган спектакльдә без партнерлар идек. С.Шәкүровның «Саф күңелгә тап төшми» драмасында җитешмәгән якларыбызны күреп, бер-беребезгә киңәшләр биреп иҗат иттек. Иҗади хезмәттәшлегебез бүгенге көндә дә дәвам итә.

Бүген аның ныклы тылы – гаиләсе бар! Кызы аларга ике оньк алып кайткач, хатыны Резидә белән шуларны назлап-сөеп, гөрләшеп яшиләр. К.Тинчурин исемен йөрткән яраткан театры, хезмәттәшләре дә аның тормыш терәге. Һәм, әлбәттә, аны яраткан, төрле рольләрдә көтеп калган тамашачысы бар. Бу тулы бәхет түгелмени?! ■

Борынгы татар милли музыка уен кораллары

Ринат Гыйләҗев, «Сорнай» фольклор ансамбленең сәнгать җитәкчесе

«Сорнай» фольклор ансамбле торгызган уен кораллары

Кышкы салкын кич. Авыр кара болытлар арасыннан ара-тирә генә тулган ай һәм якты йолдызлар күренеп китә. Берничә йөз елларга сузылган шушындый салкын мәсхәрәле төннәрдә халкыбызның ачы язмышын курай, кубыз, гөслә, думбра һәм тагын бик күп музыка коралларыбыз да уртаклашты. Алар еладылар, чеңләделәр, сындылар, изелделәр. Әмма «үлмәделәр». Акрын гына ачы язмышларына буйсынып чорма-чоланнарда, халык хәтерендә озак еллар тынып тордылар. Музыка коралларыбызның моңлы кылларын сыйпап, эчләренә җан өреп, халкыбызның мәңге үлмәс Ялчыголлары, Габәшиләре, Исмәгыйльләре (галимнәр Таҗетдин Ялчыгол, Солтан Габәши, Исмәгыйль Мусин), Миңлегөлләре, Татыйлары (Субаш һәм Сәрдәбаш авылы гөсләчеләре), Фәйзуллалары, Ифратлары (гармунчы Фәйзулла Туишев, курай ясаучы Ифрат Хисамов) һәм тагын бик күп каһарман шәхесләребез кадерләп саклап калган аларны.

***

1983 елда Казанга күчеп, Республика фәнни-методик үзәгендә фольклор секторы мөдире булып эшли башлагач, мине татар дөньясында милли музыка уен

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2019) санында.

коралларының бик аз булуы аеруча борчый башлады. Татар фольклорында баян, тальян гармун, курай, кубыздан башка уен кораллары инде кулланылмыйлар иде. Берничә мең еллык тарихы булган татар халкы курай, кубызда гына уйнамагандыр бит инде?!

> «Татар халкының музыка кораллары әле бүген дә бик аз өйрәнелгән. Фәнни хезмәтләрдә дә, көндәлек матбугат битләрендә дә уен коралары турында гомум мәгълүмат кына бирелә яки исемнәре генә әйтеп кителә.

Татар халкының музыка кораллары әле бүген дә бик аз өйрәнелгән. Фәнни хезмәтләрдә дә, көндәлек матбугат битләрендә дә уен коралары турында гомум мәгълүмат кына бирелә яки исемнәре генә әйтеп кителә. Мәхмүт Нигъмәтҗанов, Рәгъде Халитов, Геннадий Макаров кебек галимнәребезнең фәнни хезмәтләрендә уен коралары күпмедер өйрәнелә, ләкин аларның татар халык уен коралары икәненә төгәл җавап юк. Гомумән, элек- электән уен коралларының торышы милләтпәрвәр музыкантларның эшчәнлегендә генә чагылыш тапкан һәм хәзер дә шулай дәвам итә. Әйтик, фольклорчы галимнәр – Таҗетдин Ялчыгол, Солтан Габәши, Рәгъде Халитов, данлыклы гармунчы осталар – бертуган Вараксиннар, Фәйзулла Туишев, Ринат Вәлиев, курайчы осталар – Солтан Габәши, Исмәгыйль Мусин, Ифрат Хисамов, Рафаил Гәйзетдинов һәм тагын шактый күп шәхесләребез дәүләттән бер тиен дә финанс ярдәме алмыйча иҗат иттеләр. Шулай да аларның хезмәтләре бүгенге һәм киләчәк галимнәр өчен әйтеп бетергесез зур нигез булып тора. Киләчәктә әле аларның иҗатларына дөрес бәя бирелер.

Тарихта музыка коралары көнкүрештән аерым рәвештә яши алмый. Алар – тормышыбызның аерылгысыз өлеше, рухыбыз. Никадәр җаннарны, буыннарны, халыкларны, гасырларны тоташтыра, берләштерә алар.

«Сорнай» ансамблен оештыруым аркасында, Аллага шөкер, мин бик бәхетле кеше булдым. Дөньяның төрки халыклар яшәгән барлык илләрендә дә диярлек булырга туры килде. Кайда гына булсам да – Себердәме, Кытай, Төркия, Тыва, Венгрия, Украина, Молдова, Казакъстан, Мәскәү яки башка җирләрдәме – шушындагы җирле халыкның борынгы чын тарихын аңларга тырыштым. Чөнки безне халыкара фестивальләргә, конкурсларга, шушы илләрнең милли бәйрәмнәренә чакыралар иде. Шуңа да биредә җирле халыкның иң дөрес, камил сәнгать үрнәкләрен бергә җыеп күрсәтергә тырышалар, безнең кебек кунак коллективлар да зурдан кубып әзерләнеп киләләр. Биредә, кием үрнәкләре, музыка уен коралары, гореф-гадәт, тел-лөгать, җыр-биюләр аша, никадәр белем алып, чагыштырып, сөйләшеп, аралашып, дуслашып була.

Татар милли музыка уен коралларын тирәнрәк өйрәнүне максат иткән яшь белгечләргә мин эшне беренче чиратта шушы сорауларга төгәл җавап табудан башларга тәкъдим итәр идем:

– Син кызыксынган уен коралы, дөрестән дә, татар музыка коралымы? Аны нинди чыганакларга таянып исбатларга?

– Татар халык авыз иҗаты әсәрләрендә (әкият, дастан, табышмак, җыр һ.б.) нинди уен коралларының исемнәре искә алына һәм аларны ничек күзалларга?

Фәнни һәм әдәби чыганаклардан да уен коралары, аларның исемнәре турында күп белешмә алып була. Әйтик, Х гасырга караган Әбу Насыйр әль-Фараби, 13 нче йөзгә нисбәтле «Кодекс Куманикус» («Коман Мәҗмугасы»), борынгы Болгарга

Уен коралларын ясау остасы Таһир Вәлиуллин

килеп киткән сәяхәтчеләр Ибн Фадлан, француз монахы Рубрухвис, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре, «Идегәй» дастаны һәм тагын күп кенә чыганакларда шул чорларга караган музыка уен коралларының исемнәре искә алына, нинди максатларда кулланылганнары да тасвирлана.

Ә инде иң зур байлыгыбыз ул – күренекле галимнәребезнең, этнограф-фольклорчыларыбызның төрле елларда берәмтекләп җыйнап, туплап чыгарган фәнни хезмәтләре.

Гомумән, татар тарихы ул – без күз алдына да китерә алмый торган зур, бай тарих. Халык тормышының нинди генә тармагына игътибар итсәң дә – дәлилләр белән булсын, тоемлау белән булсын – җиңел генә безнең эраның теге ягына чыгып китәсең. Аллага шөкер, никадәр рухи байлыгыбыз сакланып калган, күпме каһарман бабаларыбыз, олы йөрәкле галимнәребез фидакярләрчә эш алып барган бу өлкәдә.

Татар тарихында төрле чорлар булды. Илнең чәчәк аткан вакытлары да, дәүләтчелеген югалткан чоры да. Тын океаннан алып Дунай буйларына кадәрге җирләрдә сибелеп, бер урыннан икенче урынга күченеп яшәгән ул. Әлбәттә, яшәү урыны һәр халыкның мәдәниятенә, яшәү рәвешенә нык тәэсир итә. Шуңа да татар музыка уен коралларының исемнәрендә дә, формаларында да, ясау өчен материал сайлаганда да, уен алымнарында да гомумтөрки һәм төрки булмаган күрше халык уен кораллары белән дә зур охшашлыклар бар. Дөньяда бер генә халыкта да бу безнеке генә дигән уен коралы сирәктер. Шуңа күрә курай – башкорттан, думбра – казакътан, гармун – немецлардан, саз – фарсыдан, гөслә тагын кайдандыр килеп кергән дип борчылырга кирәкми. Халык

> «Борынгы чорларга караган күп кенә уен коралларыбыз халык тормышында аеруча әһәмиятле булган чараларны, йолаларны үтәү өчен барлыкка килгәннәр.

меңнәрчә ел инде бу музыка уен коралында уйнаган икән, димәк, ул шул милләтнең дә уен коралы булырга хаклы. Шулай ук бүгенгәчә сакланып калган иң изге ядкярьләребезнең кайсы керәшеннеке, башкортныкы, мишәрнеке, кайсы болгарныкы, Алтын Урданыкы икәнен бүлешә башласак, безне киләчәктә күңелсезлекләр көтә. Бөек Кубрат ханның балаларына әйтеп калдырган васыятен онытмасак иде.

Борынгы чорларга караган күп кенә уен коралларыбыз халык тормышында аеруча әһәмиятле булган чараларны, йолаларны үтәү өчен барлыкка килгәннәр. Ятаган, кыл-кубыз, таш сыбызгы, думбра, кубыз, дөңгер һәм башка уен коралларыбызның килеп чыгышы камлау, ияләр, Ходай белән сөйләшү кебек дини максатлардан булган. Төрки дөньяның кайбер илләрендә әле хәзер дә шаман дөңгерен – галәм яратылу, ә думбра, кыл-кубыз, ятаган уен коралларын кешелек ялалу символы, тере җан итеп күрүчеләр бар. Шулай ук быргы, мөгез, сорнай, җәя-кубыз, барабан, күптөрле бәрмә кораллар хуҗалык итү, яшәү өчен көрәш барышында барлыкка килгән. Соңга табарак әлеге уен кораллары, акрынлап, үз вазыйфаларын югалтканнар, тагын да камилләшкәннәр, күңел ачу коралларына әйләнгәннәр. Шуңа да әлеге уен коралларын тирәнтен өйрәнеп, олыласак иде. Алар – милләтнең символы булырга лаеклы уен кораллары.

Белгәнебезчә, думбра, гөслә, ятаган, кыл-кубыз кебек күләмле төп уен кораллары билгеле сәбәпләр аркасында кулланудан төшеп калганнар, ә менә камыл, камыш сорнай, быргы, төрле сыбызгылар, курай, кубыз кебек ясарга җиңел уен кораллары күбрәк сакланып калган. Чөнки аларны балалар һәм яшьләр көтү көткәндә, кыр эшләре вакытында, аулак өйләрдә качып-посып кына булса да һәрвакыт ясап уйнаганнар. Нәтиҗәдә, дәвамлылык сакланган. Моны фольклорчы Р.Халитов хезмәтләре дә раслый. Шуңа да әлеге уен коралларына бик гади, примитив кораллар дип кенә карарга кирәкмидер. Аларның нигезендә элек кулланылышта булган татарның төп, традицион уен кораллары ята. Күп кенә күрше халыклар да уен коралларын торгызу эшен шундый үтә гади кораллардан башладылар. ■

Милли уен коралларыбыз

Татар дәүләт филармониясе 100 еллык ТАССР тарихында

Г.Тукай исеме бирелүгә 70 ел тулуга багышланган тантанада Татар дәүләт филармониясе директоры Кадим Назыйр улы Нуруллинның чыгыш ясаган чагы. 2016 ел

2007-2017 еллар

■ **2007 елда** Татар дәүләт филармониясенең 70 еллык юбилеена багышланган китап чыга.

■ **2008 елда** беренче тапкыр Халыкара «Филармониада» сәнгать фестивале үтә. Әлеге фестивальне гамәлгә куярга Татарстанның 2013 елгы Универсиаданы Казанда үткәрү хокукын яулап алуы этәргеч була.

■ **2011 елда** Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахманов Татар дәүләт филармониясенең сәнгать җитәкчесе итеп билгеләнә.

■ **2013 елның 18 гыйнварында** филармониядә Әлфия Авзалованың 80 яшьлек юбилеена багышланган тантана була.

■ **2014 елдан** Халыкара «Джазлы Казан» фестивале уза башлый.

■ **2014 елның** ноябрендә Татар дәүләт филармониясе ветераннарының «Илһамият» клубы оеша.

■ **2015 елда** ун елдан артык тарихы булган «Халык көйләре» конкурсы шул ук исемдәге фестивальгә әверелә. Әлеге конкурс-фестивальнең идея авторы – Россиянең халык артисты, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан

Республикасы халык уен кораллары дәүләт оркестрының сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижеры Анатолий Шутиков.

■ **2015 елның** ноябрендә Татарстан Республикасы халык уен кораллары дәүләт оркестрының Көньяк Корея Республикасына зур гастроле оештырыла.

■ **2015 елның 28 гыйнварында** Филармония, Илһам Шакировның 80 яшьлек юбилеена багышлап, күренекле җырчының «Калеб» клубына тупланган яшь шагыйрьләр белән очрашуын оештыра.

■ **2015 елның 25 февралендә** Филармониядә Илһам Шакировның 80 яшьлек юбилеена багышланган тантаналы концерт уза.

■ **2015 елда** Филармония Рөстәм Яхин исемендәге классик музыка фестивален үткәрә башлый.

■ **2016 елның 4 декабрендә** Филармониянең әдәби-музыкаль лекторие, күренекле җырчы Гали Ильясовның тууына 80 ел тулуга багышлап, истәлекле әдәби-музыкаль кичә уздыра.

■ **2016 елда** Татар дәүләт филармониясенә Габдулла Тукай исеме бирелүгә 70 ел тула. Зур юбилей уңаеннан күп кенә тантаналы чаралар үтә. Филармония бакчасына Габдулла Тукай истәлегенә чыршы агачы утыртыла, аның тамырына безнең чор кешеләренең киләчәк чор кешеләренә мөрәҗәгатьләре тупланган капсула салына.

■ **2016 елда** Филармония беренче тапкыр «Джаз-Кроссовер-Фест-Казан» фестивален уздыра. **2017 елдан** башлап фестиваль ел саен октябрь-ноябрь айларында үтә.

■ **2017 елның 23 апрелендә** Татарстан Республикасы филармония джаз оркестры Мәскәүдә Асадуллаев йортында татарча концерт бирә.

■ **2017 елда** Татар дәүләт филармониясенең барлык концертлары 80 еллык юбилей кысаларында уза.

*Журналга **Зимфира Гыйльметдинова** әзерләде.* ■

Сәхнә ветераннары Филармониягә Тукай исеме бирелүгә 70 ел тулуга багышланган тантана вакытында. 2016 ел

Көлке куа килә...

Илдус Гыйләҗев
Н.Хаҗиәхмәт шаржы

Илдус Гыйләҗев

Отышлы хезмәт

Балда-майда йөзәр өчен,
Булу кирәк ил хуҗасы.
Ә Рәсәйдә бик тә ансат:
Булу житә... «юл хуҗасы».

Мәзәкләр

Гаҗәпләндергән

Артист Искәндәр Хәйруллинны өйләнүе уңаеннан котлап, Камал театрында плакат язып элгәннәр. Шул язу каршына артист Әзһәр Шакиров килеп туктаган да:

– Нәрсә бу? – дип сорый икән.

– Искәндәр өйләнгән бит, – дигәннәр аңа.

– Ничек инде өйләнсен?!. Кичә генә нормальный йөри иде ич, – дип гаҗәпләнгән Әзһәр Шакиров.



Марсель Галиев
Р.Нуриев шаржы

Сүз камчысы

Шаулатып илле яшьлеген уздырган Марсель Галиев Мөслимнән килгән Фоат Садриевны очрата.

– Юбилей кичәң ничек узды соң? – ди Фоат Садриев. – Театрда зал тулы идеме?

– Шыгрым! – ди Марсель Галиев. – Республиканың бөтен акыллы кешесе җыелган иде!

– Алайса берүзеңә генә кыен булгандыр инде... – ди Фоат Садриев.

Марсель Галиев аның тапкырлыгыннан шаркылдап көлә дә:

– Сине чакырсам, икәү буласы икәнбез... – ди.

Безнең мирас №8 август 2020

Марсель Галиев

Васыять

Шигърияттә җыйнак булыгыз,
Көнкүрештә тыйнак булыгыз!

Туфан Миңнуллин, *СССР Язучылар союзы әгъзасы, СССР халык депутаты, СССР Югары Советы әгъзасы, ТАССР Югары Советы депутаты, КПСС члены, СССР һәм РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре, КПСС Өлкә комитеты әгъзасы, Азия һәм Африка илләре комитеты әгъзасы,* **«***Иделне саклау***»** *җәмгыяте әгъзасы, «Современник» һәм «Татарстан» китап нәшриятларының редсовет әгъзасы, «Казан утлары» журналының редколлегия әгъзасы, «Идел» журналына фатиха бирүче, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының худсовет әгъзасы, ТАССР Культура фонды әгъзасы, Почет билгесе ордены кавалеры, РСФСРның К.Станиславский исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Республика комсомолының М.Җәлил исемендәге премиясе лауреаты, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССР Министрлар Советының Почет грамотасы иясе, элекке ДОСААФ члены, элекке пионер...*
(Язучыларның «Тынгысыз каләм» дигән дивар газетасыннан, 1989 ел)

Туфан Миңнуллин
Н.Хаҗиәхмәт шаржы

Илдар Юзеев

Иң кыска автограф

Язучы булып өлгергән һәм нәшриятта бер-бер артлы китаплар чыгара башлаган Туфан Миңнуллинның тәкъдиме миңа ошады.

– Әйдә, иң кыска язылган автографка икебез өчен генә конкурс игълан итәбез, – диде ул.

Һәм үрнәк тә күрсәтте. «Кеше бул!» исемле яңа гына чыккан китабына автограф язып бирде. Титул битендә: «Илдар, мә!» – дип язылган иде.

Минем дә китап чыкты. Мин дә аңа автограф чәпәдем: «Туфан, тот китабымны!». Озынрак килеп чыкты, кәнишне. Туфан җиңде. Мин рәхәтләнеп җиңелдем. ■

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.*

ИЮЛЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● Татарстанның халык язучысы Гәрәй Рәхимнең Татарстан китап нәшриятында «В родном доме» дигән проза китабы басылып чыкты.

● 15 июльдә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Казанның тарихи үзәгендәге әһәмиятле объектларны реконструкцияләү һәм реставрацияләү эшләре барышы белән танышкан вакытта, инде реставрацияләнгән «Әҗем» мәчетен һәм төзекләндерелгән Челышев йортын карады.

● 17 июльдә Казанның «Әл-Мәрҗани» мәчете карамагындагы мөселман зиратында (Самосырово бистәсе) Татарстанның халык артисткасы Тәслимә Хәләф кызы Фәйзуллинаның каберенә таш куелды.

Әлеге чарада К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры коллективы, Тәслимә ханымның туганнары һәм шәкертләре катнашты.

● Июль аенда «Мәдинә» нәшрият йортында мөфти шәех Равил Гайнетдиннның Ислам теологиясе һәм мәдәнияте өлкәсенә караган «Ислам: дин, гыйбадәт, әхлак, канун» дигән фундаменталь дини хезмәтенең икенче басмасы дөнья күрде. Беренче басма 2019 елның августында басылган иде.

● 19 июльдә Россия Гуманитар фәннәр академиясе академигы (1999), Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе (2000), 1982 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы, «Безнең мирас» журналы авторы Фәрит Миргалим улы Хатипов вафат булды.

● Азнакайда 88 яшьлек Флюра әби, самолетка (очучысы – Илдар Фазуллин) утырып, Чатыртау өстеннән очып узды. «Шәһәр өстеннән очкан самолетны күреп, бер очып карыйсы иде, дип кызыгып карап калган идем. Туган көнемә кызым, уйламаганда, шундый зур бүләк ясады. Очыш вакытында алган тәэсирләрне әйтеп-сөйләп кенә дә бетерерлек түгел. Без үзебез Чиләбе өлкәсендә яшибез. Азнакай – бик матур шәһәр, урамнарына, паркларына сокланып туймаслык, бар җир төзекләндерелгән, каралган, уңайлыклар тудырылган», – ди Флюра әби.

● 19 июльдә Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге әдәби бүләге иясе, шагыйрь, журналист, «Безнең мирас» журналының даими авторы Рөстәм Фәйзуллин (әдәби тәхәллүсе – Акъегет) вафат булды. Мәрхүмнең җәсәде 20 июльдә аның туган авылы Балтачта (Юлсубино, Балык Бистәсе) җирләнде.

● 24 июльдә Алексеевск районының Биләр авылында яңа мәчет ачылды. Истәлекле бәйрәм чарасында Татарстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашты һәм чыгыш ясады.

● 24 июльдә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Зөлфәт Зөфәр улы Хәкимхановка (Зөлфәт Хәким) Татарстанның халык язучысы исеме бирү турындагы Указга кул куйды.

● 25 июльдә быелгы ашлыкны төягән 15 «КамАЗ» машинасы Азнакайдан Ютазы элеваторына юл алды. Бу көнгә районда 2 мең гектардан артык мәйданда ашлык суктырылган. Гектардан уртача 45 центнер уңыш чыга. «Республика көненә, ягъни 30 августка икмәкне җыеп алу — төп бурыч. Уңыш мул, әмма басудагысы түгел, амбарга кайтарылганы гына икмәк санала. Шуңа күрә аяз көннәрнең һәр сәгате кадерле. Кыр эшләрен барлык халык белән башкарып чыгарга һәм матур итеп бәйрәм итәргә язсын», – диде муниципаль район башлыгы Марсель Шәйдуллин.

● 25 июльдә Арча районының Югары Курса авылында «Илдус» мәчете ачылды. Чарада әлеге затлы-зиннәтле мәчетне төзүдә башлап йөрүче, шушы авыл тумасы Илһам Хисамиев, Татарстан Диния нәзарәте рәисенең ярдәмчесе Равил хәзрәт Зөфәров, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел» исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон һ.б. катнашты һәм чыгыш ясады. ■

МИРАСВОРД

Станоклы пулеметның бер төре

Композитор ... Хәсәнов, шагыйрь ... Идиятуллин

Жырчы ... Рахманкулова

Очкыч

Дөньяның дүрт ягын билгеләүдә кулланылучы прибор

... Морозов (герой-пионер)

Хәсән Туфан поэмасы

...-төш коралы

Патша, монархларның махсус баш киеме

...-том

Сугышта зур батырлык күрсәтүчегә бирелгән бүләк (бор.)

Шагыйрь, язучы, «Муса» романы авторы

Бородино һ.б. сугышларда катнашкан рус генералы

Аллага якын, изге кеше (иск.)

Израиль автоматы

Легендар очучы, Советлар Союзы Герое

Борынгы Скандинавиядә диңгез сугышчысы

Грек мифологиясендә яшьлек Алиһәсе

Фатих Кәрим туган авыл

Матур, сөйкемле (иск.)

1966-2002 елларда Украинада чыккан җиңел автомобиль

«Елан ...» (Тәүфикъ Әйди)

Нигез, төп (иск.)

...-Кокушкино

Чүлдәге җәннәт

Яшь Штирлицның тормышы турында Россия сериалы

Фәүзия Бәйрәмова романы

... де Вега

Карасукызыл

Ярлы, фәкыйрь (иск.)

1939-1945 елларда Германиядә гестапо башлыгы

Мәктәп укучыларының хәрби-спорт уены

Феодаль Япониядәге крестьяннар фетнәсе

Дару (иск.)

Үпкә, хәтер калу

Мишәр абзые

Мәҗнүннең сөйгәне

Портта суднолар ремонтлау корылмасы

Шук, уенчак

... Урда

Тыгызлык берәмлеге

7 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: Җөри, куәс, фәрд, Рәми, ява, сәнә, Әмрә, Рәшит, Эко, скиф, «Фидая», тат, Тер, Рона, Дали, болеро, Риф, «Зар», шивә, Флүс, әшнә, сап, «Нократ», ау, чүлмәк, АИ.
Өстән аска: Тирсә, өшәләк, Али, Мостафин, Илдар, әнәчә, вәзир, Феба, Скала, торф, Руми, Сәяф, аел, көрәш, ирешү, тәкә, әни, Дорисс, Әхмәтҗанов, ая, Әюп.

***Рәис Габдулла** төзеде.*

«Безнең мирас»
елъязмасы / август

Кызыл Байрак авылында композитор Салих Сәйдәшев истәлегенә куелган таш

765 ел элек (1255)
Алтын Урдада Бату (Батый) хан вафат була.

195 ел элек (1825)
Шагыйрь вә мөгаллим Шәмсетдин Зәки (1825-1865) дөньяга килә.

170 ел элек (1850)
Казанда Таҗетдин Ялчыголның «Рисаләи Газизә» китабы дөнья күрә.

90 ел элек (1930)
12 августта язучы, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Шәһит Әхмәдиев (1888-1930) вафат була.

85 ел элек (1935)
25 августта Татарстанның халык язучысы Туфан Миңнуллин туган.

80 ел элек (1940)
СССР Халык Комиссарлары Советының Сәнгать эшләре комитеты 1941 елның ахырында Мәскәүдә татар сәнгате декадасын уздыру хакында карар чыгара.

25 ел элек (1995)
9-20 августта, Финляндиядәге «Ислам» татар җәмгыяте чакыруы белән, академик Миркасыйм Госманов Хельсинкида булып кайта. Анда ул татар җәмәгатьчелегенә милләтебез тарихы, язма мәдәни мирасыбыз турында атнаун көн дәвамында дәресләр уздыра.

20 ел элек (2000)
18 августта Югары Ослан районының Кызыл Байрак авылында мәшһүр композитор Салих Сәйдәшев истәлегенә таш кую тантанасы була.

*Журналга **Марат Закир** әзерләде.*■

Содержание. Август 2020

И останется в мире слово моё...: Туфан Миннуллин.

Татарский мир: Марсель Шайдуллин: «Азнакаево – край с богатой историей!»

Историческое наследие: «Семь фактов о музее в Азнакаево»; «Строить будущее, основываясь на истории». А.Бурганов; «Первый татарский фотограф». Л.Тябина; «Багбустан». М.Гарипов; «Газета «Җөмһүрият». Л.Губайдуллин, Р.Шарафиева; «Надгробный камень Зарифа Амирхана». А.Гайнутдинов.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

Литературное наследие: «Стихи Ахмада Гарая»; «Книги с автограф в библиотеке Мусы Джалиля». Н.Фаттахова, Л.Харасова; «Мать» (Поэма). Сирин; «Если любовь к родному селу истинна...». Л.Лерон; «Дед-сказочник». М.Ахматзянов.

В глубинах памяти: «Японский феномен». Ф.Нафиев; «Солдат бессмертного батальона». И.Нигмати; «В памяти, до сих пор в памяти!»

Художественное наследие: «Творческий почерк». Р.Сагди; «Древние национальные музыкальные инструменты». Р.Гилязев; «Татарская государственная филармония в истории 100-летней ТАССР». З.Гильмутдинова.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Алхәбәр:

Әгәр исән булсалар, бу әдипләрнең берсенә (Туфан Миңнуллинга) августта – 85 яшь, икенчесенә (Гариф Ахуновка) сентябрьдә 95 яшь тулган булыр иде.

- **«Җырланып бетмәгән җырым». Илзирә Вәлиуллина**
- **Курса мәдрәсәсе тарихы. Эльмира Сәлахова**
- **Гариф Ахунов көндәлекләреннән**
- **Мөхәммәт Мәһдиев музее**

Туфан Миңнуллин — фотоларда

(Әдип гаиләсе архивыннан)

Сулдан уңга утыралар: әтисе Абдулла Миңнуллин, сеңлесе Өммия, әнисе Халисә, әнисе алдында – энесе Риваль, артта – Кәбир абыйсы һәм Туфан үзе



Артист Шәүкәт Биктимеров белән

Мәшһүрләрнең гаярь ир-егет чаклары – Шәүкәт Галиев, Туфан Миңнуллин һәм Илдар Юзеев

Режиссер Марсель Сәлимҗанов белән

Күчмә театр. «Ак тәүбә, кара тәүбә» спектакленең премьерасыннан соң

СӨЕМБИКӘ УРАМЫ

Азнакайдагы Сөембикә урамының (элек Толстой) совет чорындагы күренеше

Сөембикә урамының хәзерге күренеше

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:

- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә электрон версия

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.